Безнең МИРАС

НАШЕ НАСЛЕДИЕ

08

август 2017

ISSN:2500-011X

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

РУШАНИЯ ЯКУПОВА. «ШӘРЫК МОТИВЫ»

САБАНТУЙЛЫ ӘЛӘЗӘН

21 июльдә Пенза өлкәсенең Городище районы Урта Әләзән авылында Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашында YIII Бөтенроссия авыл Сабан туе булып узды.

Фотолар president.tatarstan.ru сайтыннан алынды

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.

Дәрдемәнд

Безнең МИРАС

12 +

8 (284)

август 2017

1991 елның апреленнән башлап «Мирас»,
2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ
тарафыннан кабат гамәлгә куелып,
«Чын мирас» исемнәре белән чыкты.
2014 елның маеннан «Безнең мирас»
итеп үзгәртелде.

74 ҺАДИ ТАКТАШНЫҢ ФАТИХ ӘМИРХАНГА МӘРСИЯСЕ.
Рүзәл Мөхәммәтша



106 АМЕРИКА ГАЛИМЕ ҺӘМ ТАТАР ГАРМУНЫ.
Эльмира Каюмова

12

ЭЧТӘЛЕК

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 *Каюм Насыйри*

ТАРИХИ МИРАС

4 Куркыныч һәм хәвефле еллар. *И.Таһиров*

БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫНА 25 ЕЛ!

7 Милләтнең киләчәген кайгыртып. *Р.Закиров*
11 Милләтебезне барлаучы белешмә. *Б.Хәмидуллин*
12 Максатлар уртак — милли азатлык! *Ф.Бәйрәмова*
16 Бабаларыбызның ерак авазларын тыңлап... *К.Йосыпов*
25 Красноярск татарлары: тарих һәм хәзерге заман. *В.Фәйзуллин*
30 Онытырга хакыбыз юк. *Т.Биктимерова*
34 Максатыбыз — милләтебезне саклап калу. *Р.Сафин*
38 Конгресс — үзе бер дәвер ул. *Ф.Сафиуллина*
40 Кәшшаф Патии

МӨҺАҖИРЛӘР МИРАСЫ

42 Татарларны үтерү вә мөселманнарны бетерү сәясәте тарихы. *Л.Сәлим*
45 КАЙТАВАЗ. Мәрьямкәй бәете (*Барда варианты*)

ПЕДАГОГИК МИРАС

46 Остазлар. *М.Әхмәтҗанов*
51 Мәгарифкә багышланган гомер. *Р.Низамова*
54 Гомер озынлыгы дәрес. *С.Җәләева*

ТАТАР ГАМЕ

56 Дамир Исхаков: «Офыкларны ерагайтасы иде». *Р.Минһаҗ*

ДИНИ МИРАС

61 Ислам дөньясы. *Г.Ибраһимов*
67 Татар дин галимнәре Корбан турында

ӘДӘБИ МИРАС

70 Кутадгу билик. (Котайткыч белем). *Й.Баласагуни*
74 Һади Такташның Фатих Әмирханга мәрсиясе. *Р.Мөхәммәтша*
76 Ул безнең өчен үле иде инде. *Һ.Такташ*
78 «Күкрәк сөте берлән кушып шәфкать канын...» *З.Ярмәки*

82 Шагыйрьнең яшьлек утравында. *И.Нигъмәти*
88 Серле шагыйрь дустым истәлегенә. *Ф.Зыятдинов*

ОЧТЫ ДӨНЬЯ ЧИТЛЕГЕННӘН...

94 Камил Мотыйгый

СУГЫШ КАЙТАВАЗЫ

96 Татар хәрби разведчиклары. *Р.Зарипов*

ХӘТЕР САНДЫГЫ

102 Утлы кисәү. *Л.Гыйльфанов*

СӘНГАТИ МИРАС

106 Америка галиме һәм татар гармуны. *Э.Каюмова*

ТЕЛ КҮРКЕ – СҮЗ

108 Миллият сүзлеге. *А.Тимергалин*

ХӘТЕР САГЫНДА

110 Ядкәрләргә — бер гасыр
112 Иске Мәңгәр

100 ЕЛ ЭЛЕК...

114 «Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1917 елның август ае.

116 «Безнең мирас» хәбәрләре

118 «Безнең мирас» елъязмасы. *Август*

119 Мирасворд

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ (Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары
Марат Закиров
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Андрей Кузьмин
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Айрат Сибагатуллин
(ТР мәдәният министры)
Энгель Фәттахов
(ТР премьер-министры урынбасары – ТР мәгариф һәм фән министры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Ирада Әюпова
Альберт Борһанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Данил Салихов
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов
Ирек Шәрипов

Җаваплы мөхәррир
Фирдәвес Зарифуллин
(843) 222-09-83 (17-91)

Бүлек мөхәррирләре
Ленар Гобәйдуллин
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-90)

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-92)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-90)

Гомуми мәсьәләләр буенча мөхәррир
Рәдиф Сәгъдиев
(843) 222-09-83 (17-91)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

Заказ №А-1784. Тираж – 2873 данә. Формат 70 Х 108 1/16
Басарга кул куелды: 24.07.2017
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә
Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең
Татарстан Республикасы буенча идарәсендә
ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела. Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми.
Ул хакта техник контроль бүлегенә 519-44-61
телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторларның һәм Татарстан Милли музее архивларыннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан фотосурәтләр, җиде томлык «Татар тарихы»ннан рәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Тышлыкның 1 нче битендә – «Шәрык мотивы» (фрагмент). 2011 ел. Киндер, майлы буяу. *Р.Якупова.*

КАЮМ НАСЫЙРИ
(14.02.1825 – 02.09.1902)

***

Телең белән яхшылык кылганчы, эшең белән яхшылык кыл.

***

Малны саклау – малны табу һәм малны җыюдан авыррак.

***

Мунча ташы бик эре, йөге бер тәңкә; энҗе бик вак, мыскалы ун тәңкә.

***

Адәм сәламәтлекнең кадерен бер михнәткә дучар булгач беләдер.

***

Берәүгә яхшылыгың тисә – сөйләп йөрмә, берәүдән яхшылык күрсәң – онытма.

***

Агач башыннан егылган кеше хәлен агач башыннан егылган кеше генә белә.

***

Бер курыккан эт өч көн өрер.

***

Узган болытны тотып булмый.

***

Кирәк, үзең урла, кирәк, белә торып, урланган нәрсәне ал – икесе бер бәрабәрдер.

***

Ярлы кешенең акчасы торна булып кычкыра.

***

Тел җәрәхәте кылыч җәрәхәтеннән ачырактыр һәм яманрактыр.

***

Үзем дигән үзәксез калган.

*Текстны **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

КУРКЫНЫЧ
ҺӘМ ХӘВЕФЛЕ ЕЛЛАР

Индус Таһиров*

Каршылык күрсәтүләргә яңа хакимият эзәрлекләүләрне тагын да арттыру белән җавап бирә. Болар шундый дәрәҗәгә җитә ки, халык авыллардан кача башлый. Татарстанның Буа өязендә Чувашстанга китү хәрәкәте барлыкка килә.

Халыкны эзәрлекләүләр республикадан читтә яшәүче татарларны да читләтеп үтми. Менә тагын бер характерлы факт китерәм. 1929 елның маенда Пенза губернасындагы Зур һәм Кече Труево, Зур һәм Кече Чирекле, Татар Кынадысы һәм Курмай авылларында тантаналы рәвештә Корбан бәйрәме үткәрелә. Советлар аны 1 май бәйрәменә каршы үткәрелгән чара дип кабул итәләр. 36 кеше кулга алына. Шуларның тик берсе генә җәзага тартылмый кала. 9 кешене аталар, калганнарын гомерлеккә төрмәгә утырталар. Боларның да язмышлары ачыкланмаган.

***Индус Таһиров - Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының беренче рәисе (1992-2002 еллар).**

Эзәрлекләүләр халыкның барлык катламнарына барып җитә. Аларның барысын да сөйләп бетерерлек түгел. Шунлыктан, мин кайбер фактларга гына тукталам.

Галимҗан Ибраһимов



*Ахыры. Башы 7 нче санда.
[1] ЦГА ИПД, ф.292, оп. 2,д.467, 187-238 битләр.

1935-1937 елларны Сәламәтлек саклау Халык Комиссариаты шаулап торган умарта оясын хәтерләтә. Монда халык дошманнарын фаш итү кампаниясе киң колач ала. Ул партия контроле комиссиясенә килеп кергән карардан башланып китә. Анда: «Сәламәтлек саклау Халык Комиссариаты һәм аның карамагындагы республика медицина учреждениеләре явыздан-явыз халык дошманнары эшли торган мәйданга әверелде», – диелгән. Нарком Беганский, аның ярдәмчеләре Корбангалиев, Колбарисов, Бикбов һәммә җиргә үзләредәй халык дошманнарын урнаштырганнар икән. Нарком урынбасары Державин троцкийчылар белән бәйле, аларны фаш итергә тиешле Эпштейн бернәрсә дә эшләми. 1917 елдан бирле партия члены, Наркоматның партия оешмасы секретаре Гизнеса Таҗетдинова һәм янә дистәләгән кешеләр – алпавыт балалары, кулаклар, ялган акча сугучылар, поплар һәм элеккеге офицерлар». Гомумән, – дип яза шушы документның авторы, – бу – «контрреволюцион букет». Ул, документка өстәмә итеп, 140 кешедән торган «халык дошманнары»ның исемлеген дә теркәгән[1].

1937 елның июнендә туберкулез белән авыручы Галимҗан Ибраһимовны, Кырымнан Казанга алып кайтып, Пләтән төрмәсенә ыргыталар. Аның турында, 1913 елдан башлап, соңгы көннәренә кадәр җандарм һәм ГПУ органнары туплаган материаллардан торган досье булдыралар. Язучыга кузгатылган «эш» буенча Галимҗан Шәрәфне, Сәлах Атнагуловны кулга алалар. Аларны төрле рәвештә җәзалап, Галимҗан Ибраһимов турында үзләренә кирәкле мәгълүматларны алырга тырышалар. Кави Нәҗмине һәм Гомәр Галине, аның якын дуслары рәвешендә, җавапка тарталар. Тикшерү эшләре ярты елдан артык дәвам итә һәм ул төрмәдә үлгәч кенә туктатыла.

ОГПУ тарафыннан 1938 елның июнендә язылган 3389 номерлы белешмәдә: «РСФСР УКсының 17-38.58-2.58-11 статьялары буенча гаепләнүче Галимҗан Ибраһимовның, төрмәдә үлүе сәбәпле, «эшен» туктатырга», – диелгән.[2]

Белмим, дөрестерме, юкмы, үләр алдыннан ул төрмә диварына: «Юкка гына хезмәт иттем сез дуңгызларга», – дип язып калдырган. Мин үзем моңа ышанам, шундый нәтиҗәгә килү өчен тулы нигезе булган. Әдипнең Совет хакимиятенә кылган гамәлләре, республикабызны барлыкка китерүгә, аның фәнен, мәгарифен, мәдәниятен үстерүгә керткән өлеше бәяләп бетергесез!

1926 елда ук кулга алынган Һади Атласины, 1933 елда саулыгы какшау сәбәпле, иреккә чыгаралар. Ләкин 1936 елның 28 июлендә янә кулга алалар. Шул елның августыннан 1937 елның мае арасында аннан 16 мәртәбә сорау алалар, әллә кемнәр белән күзгә-күз очыраштыралар, газаплыйлар. «Атласовщина эше» барлыкка килә. Шуның нәтиҗәсендә, 26 кеше кулга алына. Аларның исемнәрен атап, боларны беләидегезме, дип сорагач, ул: «Минем коем тирән, болар аннан су эчәрдәй кешеләр түгел иде», – дигән. Шуларның тугызына, шул исәптән, Һади Атласиның үзенә дә үлем карары чыгарыла.

Тикшерү органнары бик күпләргә карата башланган «эшләрен» Мирсәет Солтангалиев исеменә бәйлиләр. Аны, «ата милләтче» рәвешендә, 1923 елда ук партиядән, җаваплы эшеннән чыгарып, кулга алалар. Ул, 1928 елда янә хөкем ителеп, сөргенгә җибәрелә. Шушы язмыш аның көрәштәшләре Кәшаф Мохтаров, Газыйм Мансуров, Рәүф Сабиров, Ариф Енбаев кебек, респубика төзүгә зур өлеш керткән шәхесләргә дә кагыла. Алар да сөрелә[3].

Сөргеннән кайткач, Солтангалиевне 1938 елны янә кулга алалар. Ул «конвейер» тибындагы допросларга тап була. Аңардан, кулларын каерып, булмаган «гөнаһларын» тануны таләп итәләр, шпионлыкта гаеплиләр. Танышлары, көрәштәшләре турында үзләренә кирәкле мәгълүмат бирдермәкче булалар. Солтангалиевтән Галимҗан Ибраһимовның «Идел-Урал штаты»на нинди караштa торганлыгы хакында да сораганнар булса кирәк. Чөнки бу авыру язучыны Кырым-

[2] ЦГА ИПД,ф. 8233, оп. д. 4957, л. 34
[3] Архив КГБ, ф.109, д. 400, т.1, л.213.

нан алып кайтып Пләтән төрмәсенә китереп ташлаган вакытка туры килә. Рәсми документларга караганда, Солтангалиев 1940 елның 8 декабрендә үлем җәзасына хөкем ителә[4].

Әлбәттә, репрессияләр турында бер язмада гына сөйләп бетереп булмый.

Ләкин мин бу юлы язмамны кыскартып, авылларыбыздан куылган милләттәшләребез турындагы кайбер мәгълүматларны бирүне кирәк саныйм.

Татарстаннан меңләгән кешене төрле урыннарга «спецпоселенецлар» рәвешендә сөрәләр. Күбесенең язмышлары билгесез...

Боларны ачыклау эшен дәвам итүчеләр дә бар. Шулар арасында милләтпәрвәр язучы Фәүзия Бәйрәмова бигрәк тә актив эшли. Ул Себергә генә түгел, Ерак Көчыгышка гына да түгел, хәтта Сахалинга кадәр барып җиткән. Сөрелгән, җәберләнгән милләттәшләребезнең язмышлары хакында бик күп материал туплаган. Бу эшне хәзер дә уңышлы дәвам итә, афәрин!

Күптән түгел генә Магнитогорск шәһәре татар яшьләренең иницитатив төркеме 20-30-нчы елларны Татарстаннан сөрелгән, шәһәр төзелешендә һәм башка сәнәгать оешмаларында эшләгән 100 мең спецпоселенецка багышланган энциклопедия төзү эшен башлап җибәрде. Бу изге гамәлнең яхшы гына барып чыгуына ышанам. Әлеге эшкә Пермь тарихчылары да, моңарчы мәгълум булмаган фактларны табып, үз өлешләрен кертте. Аларның берсе 1937 елның декабре – 1938 елның гыйнварына туры килә.

Пермь шәһәренең НКВД бүлеге Краснокамск шәһәрендә татарларга каршы җентекләп әзерләнгән махсус операция планын төзи. Шуның нигезендә 802 татарны «диверсант» һәм «шпион» дип гаепләп кулга алалар. Аларның барысын да яшьләре буенча төрле төркемнәргә бүләләр һәм кәгазьдә генә «чын»контрреволюцион оешма «булдыралар». Анда «катнашучыларны» бүлекләргә, взводларга аерып, һәрбер кешегә «признательный допрос» әзерлиләр. 20-30 яшьлек егетләрне 20 нче елдагы сәнәкчеләр хәрәкәтендә катнашучылар итеп билгелиләр. Алар әлеге баш күтәрүдә 2-3 яшьлек чакларында ук катнашкан булып чыга! Күрәсең, монысы шушы операцияне әзерләгән чекистлар өчен әллә ни әһәмиятле булмагандыр. Алар өчен иң мөһиме – боларны кулак гаиләләреннән чыккан Совет власте дошманнары итеп күрсәтергә тырышу...

Нинди гаепләр ташлыйлар соң шушы Совет «дошманнарына»? Алар, имештер, нефть промыселларында һәм электр станцияләрендә шартлаулар оештыру белән шөгыльләнгәннәр. Башкортстанда мөселман дәүләте булдыруны максат иткән япон разведкасы җитәкчелегендәге зур контрреволюцион оешма эшендә катнашканнар...

Аларны 1937 елның декабре – 1938 елның 1 гыйнварында посёлокта яшәүчеләрнең күз алдында ук кулга алалар. Йөк машиналарына 50-60 кеше төяп, тимер юл вокзалына китерәләр. Аннары махсус вагоннар белән Пермьга озаталар...

Көненә 10-15 кешедән «гаебен таныту» планы бирелә. Бу планны үти алмаган тикшерүчеләргә эштән чыгару һәм хәтта «тройка» судлары белән яныйлар. Нәтиҗәдә, тикшерүчеләр, бернигә дә карамастан, «план»ны үтәп чыга.

Ә инде, татарлар дөрес кулга алынмаган, дип әйтүче кайбер «либераль» следовательләрне, «планны» үтәмәгәннәре өчен атып та үтерәләр. Шулай итеп, алар да репрессия корбаннарына әверелә[5].

Хөрмәтле укучым, язмамдагы әлеге дәлилләр – шушы кабахәт сәясәтнең бер күренеше генә. Алар исә ил күләмендә иксез-чиксез ләбаса. Боларны барлау, тикшерү, нәтиҗәләрен халыкка җиткерү – киләчәктәге бурычларыбызның берсе. ■

---

[4] Шунда ук, оп.5, д. 55, 212 бит.
[5] Вестник архивиста – 2011, № 1, сс.150-163.

МИЛЛӘТНЕҢ КИЛӘЧӘГЕН КАЙГЫРТЫП

Ринат Закиров,
Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе, тарих фәннәре докторы

Бөтендөнья татар конгрессы буш җирлектә оешмады, аның нигезен киң милли хәрәкәт тәшкил итте.Татарстанның дәүләт суверенитеты турындагы декларация киң татар дөньясы белән хезмәттәшлек итүгә, ерак җирләрдә яшәүче татарлар белән мәдәни багланышларга юл ачты. Шуның нәтиҗәсе булып Бөтендөнья татар конгрессы оешты. Аның I съезды 1992 елның 19 июнендә Казанда ачылды. Ул җыенда Русиянең төрле төбәкләреннән һәм дөньяның төрле илләреннән килгән меңнән артык делегат катнашты. Шушы олы корылтайда Бөтендөнья татар конгрессын булдыру турында карар кабул ителде, Башкарма комитет һәм Аның җитәкчесе итеп танылган галим, тарих фәннәре докторы, академик Индус Таһиров сайланды. Съездда катнашучылар Казанны халкыбызның рухи мәркәзе, татар дөньясының башкаласы итеп таныды. Ә бу – берләшү өчен бик мөһим фактор. Әлеге җыенда кабул ителгән документлар бик зур тарихи әһәмияткә ия, алар татар халкы дәүләтчелеген торгызу, татарның телен, мәдәниятен, мәгарифен, гореф-гадәтләрен, йолаларын саклау мәсьәләләрен күтәрә, татар халкын бердәмлеккә чакыра.

Нишлисең, татар язмышы Русиядәге сәяси вазгыятькә бик тыгыз бәйләнгән.Илдә демократия урнашканда, татар тормышы да гөрләп чәчәк ата, халык иркенрәк сулый башлый, хәрәкәткә килә. Бөтендөнья татар конгрессының да илдәге демократик үзгәрешләр җимеше икәнен танырга кирәк. Әгәр ул 25 ел дәвамында эшләп килә икән, бу инде халкыбызның зур уңышы.

III съезддан соң Татар конгрессы, илдәге катлаулы вазгыятьне истә тотып, яңа стратегия алып баруга күчте: милли хәрәкәтне конкрет эшчәнлек, конкрет проектларны тормышка ашыру белән тулыландыруны максат итеп куйды. БТКның яңа эш стратегиясе татар халкының барлык катламнары белән эш алып баруны күздә тотты. Бөтендөнья татар яшьләре форумын, Бөтенрусия татар теле укытучылары һәм милли мәгариф хезмәткәрләре җыенын үткәрү – моның ачык дәлиле.

Ислам дине инде мең елдан артык халкыбызның иң ышанычлы терәге, рухи ныгытмасы булып тора. Туган телебез белән Ислам дине – татар кешесенең төп билгесе. Совет чорында дин зур югалтуларга дучар булды. Шөкер, инде өч дистә елга якын вакыт халкыбыз рухи яңарыш кичерә, иманга кайта. Татарстанда һәм башка төбәкләрдә йөзләгән мәчетләр, дистәләгән мәдрәсәләр ачылды, инде менә 20 ел Казанда Русия Ислам университеты уңышлы гына эшләп килә, Болгар ислам академиясе төзелеп бетеп, быел көзен укулар башланып китәчәк. Бу мөселман руханиларының гыйлемлелек дәрәҗәсен тагын да югарырак күтәрү мөмкинлеген бирәчәк.

Барыбыз да күреп торабыз, Татарстан җитәкчелеге дини мәсьәләләргә игътибарны бик нык арттырды.Һәр елны Изге Болгар җыены үткәрелеп килә. Халыкара дин әһелләре форумын уздыру да инде традициягә әверелде. Мондый очрашулар таркаулыкны киметә, рухи бердәмлеккә хезмәт итә.

2008 елда БТК Башкарма комитеты каршында Бөтенрусия татар авыллары ассоциациясе оешкан иде. Уйлап карагыз, бүген Россиядә зур көче һәм милләтнең таянычы булган 4 меңнән артык татар авылы бар. Татар авылларында халкыбызның теле дә, дине дә, гореф-гадәтләре дә саклана. Алар арасында диндар, иманлы,

Сулдан уңга - Ринат Садриев (Свердловск өскәсе), Ринат Закиров, Марс Тукаев, Марат Юнысов (Курган), Данис Шакиров

эш сөючән халкы белән милләтебезгә үрнәк булырлыклары да байтак. Шундый бөтен илдә дан тоткан татар авыллары исемлегендә Пенза өлкәсенең Урта Әләзән, Самара өлкәсенең Гали, Түбән Новгород өлкәсенең Рбишча, Сафаҗәй, Мордовиянең Әзюркә, Чуашстанның Шыгырдан, Урмай һәм халкы мәхәллә булып яшәве белән бөтен татар дөньясына үрнәк күрсәткән Тукай, Киров өлкәсенең Иске Йөрек, Оренбург өлкәсенең Алабай тал авылларын атар идем. Шушы авыллар тәҗрибәсе киләчәктә татар авылын эшмәкәрлек яшәтәчәген раслый. Аларның һәрберсе Русия базарында үз урынын тапкан, арада үзләре җитештергәнне чит илгә чыгаручылары да бар. Авылларда хәләл ризык җитештерүче ширкәтләр эшли, аларның продукцясен шәһәрләрдә бик теләп алалар. Бөтенрусия авыл Сабан туен үткәрү дә, милләтебезне туплаудан тыш, үзара тәҗрибә уртаклашуга да хезмәт итә.

Гомумән, бүген татар тормышында зур җанлану күзәтелә. Русиянең 70тән артык төбәгендә, дөньяның 24 илендә уза торган Сабан туе бәйрәме, татарча

Ринат Закиров «Ак калфак» Бөтендөнья татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасы әгъзалары белән

Кардәшлеккә чикләр юк

көрәш турнирлары, махсус оештырылган ат чабышлары, Бөтенрусия татар фольклоры фестивальләре, «Татар кызы», «Татар егете» бәйгеләре – мондый чаралар милли мәдәният өлкәсендә, төбәкләрдәге татарлар тормышында яңа күренешләр буларак бәяләнергә хаклы. Иң мөһиме – халкыбызның иманы чиста, рухы нык, киләчәккә өмет белән карый.

Безнең 2 миллионнан артык милләттәшебез чит илләрдә яши. Милли республикалар арасында башка бер халыкта да мондый зур күләмле һәм көчле диаспора юк. Бу Татарстанга халыкара мәйданда киң колачлы эшчәнлек алып барырга зур мөмкинлек ача һәм җөмһүриятебез әлеге мөмкинлекләрдән даими файдалана. Татарстанның чит илләрдәге ватандашлар белән тыгыз элемәтәләре һәм күпкырлы хезмәттәшлеге илнең башка төбәкләренә үрнәк булып тора.

Әле күптән түгел генә Русия Тышкы эшләр министрлыгында Татарстанның чит илләрдәге ватандашлар белән эшләү тәҗрибәсенә багышланган махсус конференция узды, анда республиканың әлеге тәҗрибәсе югары бәяләнде һәм башка төбәкләргә үрнәк итеп күрсәтелде. Әйтергә кирәк, бүген дөньяның 41 илендә татар оешмалары эшли һәм алар барысы да Бөтендөнья татар конгрессына керә. Татарстан Президенты чит илләргә һәм Русия төбәкләренә сәфәр кылганда, андагы милләттәшләр белән очрашмыйча калмый. Мондый очрашулар ике якка да бик файдалы! Бер яктан, алар илдә һәм дөньяда Татарстанның йогынтысын арттыра, икенче яктан, чит илләрдәге милләттәшләр арасында танылган халыкара ширкәтләрдә җитәкче урыннарда эшләүчеләр байтак. Алар еш кына Татарстанга файдалы икътисади элемтәләр урнаштырырга ярдәм итә. Татарстанның читтәге татарлар белән хезмәттәшлеген бүген татар факторы дип атый башладылар. Читтәге татарларның Татарстанга һәрвакыт теләктәштә булулары – бу, һичшиксез, җөмһүриятебезнең көчен-куәтен арттыра, аның төрле юнәлешләрдәге йогынтысын үстерә.

Дөнья татарлары үзләренең чираттагы җыенына – Бөтендөнья татар конгрессының VI корылтаена зур күтәренкелек белән килә. Шигем юк, бу зур чара милләтебез тарихына яңа бер якты сәхифә булып кереп калачак. Халкыбыз ерак гасырлардан бирле телен, иманын, күркәм йолаларын һәм гореф-гадәтләрен, моңын саклап яши, аның киләчәге дә үзебездән тора. Моның өчен бердәмлек, тырышлык – милләт файдасына иҗтиһад итү кирәк!.. ■

МИЛЛӘТЕБЕЗНЕ БАРЛАУЧЫ БЕЛЕШМӘ

Булат Хәмидуллин

Мәгълүм булганча, халкыбыз Россиягә генә түгел, бөтен дөньяга таралып яши. ТР Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты галимнәре һәм хезмәткәрләре милләттәшләребезне барлауга үзләреннән зур өлеш кертте – «Регионы компактного проживания татар в Российской Федерации» дигән фәнни белешмә китап әзерләп бастырды. Ул РФ республикалары, өлкәләре һәм крайлары хакимиятләре, РФ төбәкләре галимнәре һәм крайны өйрәнүчеләре биргән материалларны исәпкә алып язылды.

Бу белешмәгә 380 фәнни мәкалә керде: РФ төбәкләре турында 43 гомумиләштерүче мәкалә (29 өлкә, 9 республика һәм 5 край хакында), 2 автономияле округ, 273 район, 4 шәһәр округы һәм 58 шәһәр (шул исәптән 2 федераль әһәмияттәге шәһәр – Мәскәү һәм Санкт-Петербург) турында.

Әлеге мәкаләләр халык санын рәсми исәпкә алуның РФ төбәкләрендә яшәүче татарлар санының еллар буенча үсешен күрсәткән мәгълүматны, татарларның бу биләмәләргә килеп урнашу вакытын чагылдырган тарихи хәбәрләрне, милләттәшләребезнең 1917 елга хәтле (мәктәпләр, мәчетләр, мәдрәсәләр, мәдәни агарту оешмалары, матбугат басмалары, сәнәгать һәм сәүдә предприятиеләре, хуҗалык эшчәнлеге һ.б.) һәм совет чорындагы, бүгенге этаптагы тормышы (татар мәктәпләренең һәм татар теле предмет буларак укытыла торган мәктәпләрнең саны; милли мәдәни үзәкләрнең, татар халкы белән эш алып баручы башка учреждение һәм оешмаларның булуы, татар үзешчән коллективлары, иҗат берлекләре һ.б.), төбәкләрнең Татарстан белән бәйләнешләре, татарлар белән бәйле тарихи-мәдәни һәйкәлләр, татар халкының тормышлары яки эшчәнлекләре әлеге төбәк белән бәйле мәшһүр вәкилләре турында һ.б.ш.

Басма ТР ФА Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты хезмәткәрләре төзегән «Расселение татар в Российской Федерации» дигән оригиналь карта белән тәэмин ителгән.

Бүгенге көндә бу белешмә Россия Федерациясендә татарлар тупланып яшәгән урыннар турында мөмкин кадәр тулы мәгълүмат биргән бердәнбер уникаль басма булып тора. ■

Бөтендөнья татар конгрессы 1992 елның маенда Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиевнең фәрманы белән төзелде. Шул ук елның 19 июнендә Казанда аның оештыру корылтае да үтте. Соңыннан Минтимер Шәймиев Татар конгрессы төзелүне иң уңышлы проектларның берсе дип атады.

Сахалин. 2012 ел

МАКСАТЛАР УРТАК – МИЛЛИ АЗАТЛЫК!

Фәүзия Бәйрәмова

Татар конгрессы һәм Татарстанда, һәм Россиядә вазгыять бик катлаулы вакытта, СССР дигән дәүләт җимерелеп, илләр һәм милләтләр юллар чатында басып калган чорда төзелде. СССР юкка чыгу белән татар халкының зур бер өлеше читтә аерылып калды, аларны Казан белән тоташтырып торган структуралар җимерелде, күперләр яндырылды... Икенчедән, Татарстанның үзендә дә хәлләр катлауланды, татар милли хәрәкәте республикага тулы бәйсезлек таләп итсә, җитәкчелек Мәскәү белән араны өзәргә ашыкмады. Шунысын да онытмыйк: 1992 ел – Референдум һәм яңа Конституция елы, февральдә Милли Мәҗлес оешып, бөтен көченә эшли башлаган вакыт. Милли Мәҗлес тә Татарстанга тулы бәйсезлек таләп итә, республика җитәкчелеген Декларациягә һәм Референдум нәтиҗәләренә тугры булырга чакыра, аларны шушы юнәлештә эшләргә этәрә.

Бөтендөнья татар конгрессы Милли Мәҗлесне алыштырырга тиеш иде, әмма алар шактый озак еллар янәшә эшләде, максатлар уртак булса да, аңа ирешү юллары төрле иде. Милли Мәҗлес беренче урынга Татарстанның дәүләт бәйсезлеген һәм татар халкының азатлыгын куйса һәм бу максатына ирешүне сәяси юллар белән дә хәл итәргә алынса, Бөтендөнья татар конгрессы иҗтимагый оешма буларак теркәлде һәм милли-мәдәни юнәлештә эш итте. Татар конгрессы башта ук сәясәт белән шөгыльләнмәячәген игълан итте. Иҗтимагый оешма булса да, ул хөкүмәт җитәкчелегендә эшләде, аның ярдәме белән яшәде. Шушы 25 ел вакыт эчендә күпчелек милли оешмалар юкка чыгарылды, мәхкәмәләр белән ябылды, теркәлүдән төшереп калдырылды, булганнары да бик авырлык белән эш итә. Татар милли азатлык хәрәкәте милләт кичергән бөтен авырлыкларны үз башыннан кичерде, бөтен югалтулар аның язмышы аша да үтте. Татар конгрессы бүгенге көнгә кадәр эшләп тора, хөкүмәт яклавында булу аны милли хәрәкәт күргән авырлыклардан саклап килә, әмма милләт үзе юкка чыгып барганда, бу җил-давыллар барысына да кагылырга мөмкин...

Татар конгрессы бүгенге көндә милләткә кирәкме? Әлбәттә, кирәк: Татар конгрессы – иҗтимагый оешмаларның берләшмәсе, ягъни урыннарда милләтнең актив өлеше катнашында төзелгән оешмалар тупланмасы. Һәм Бөтендөнья татар конгрссының шушы чирек гасырда башкарган иң зур эше – ул урыннарда милли оешмаларның структурасын төзи алды, ягъни татар дөньяның кайсы гына почмагында яшәсә дә, аның үз оешмасы бар, ул оешмаларның үз лидерлары бар. Дөрес, бу оешмаларның күпчелегенә заманында татар милли хәрәкәте нигез салган иде, җитәкчеләрнең һәм әгъзаларның да кайберләре элеккечә калды, әмма шул ук вакытта яңа лидерлар да үсеп чыкты. Милли Мәҗлес, Татар иҗтимагый үзәге заманында урыннарда милли зыялыларга таянган булса, Бөтендөнья татар конгрессы эшмәкәрләргә һәм хакимият түрәләренә таянуны хуп күрде, алар белән төрле проблемаларны хәл итәргә җиңелрәк иде. Әмма милләт авыр хәлдә калганда, бу татар байлары һәм түрәләр качып бетәчәк, татарны яклап мәйданда барыбер шул зыялылар калачак, моны да белеп торырга кирәк.

Билгеле булганча, милләтебезнең 75 проценты Татарстаннан читтә яши, ә республикада шулар белән эшләрлек бер структура, министрлык юк. Читтәге татарлар белән эшләү тулысынча диярлек Татар конгрессы җилкәсенә салынды, һәрхәлдә, Татарстан казнасыннан финансланмаса да. Бөтендөнья татар конгрессы бүгенге көндә милләт белән хакимият арасында күпер, арадашчы ролен башкара. Бу нисбәттән аны «Милли эшләр министрлыгы» дип тә атарга була. Кайбер вакытта Бөтендөнья татар конгрессының бөтен эшен читтә Сабантуйлар уздырып йөрүгә генә кайтарып калдыралар, әмма бу дөреслеккә туры килеп бетми. Сабантуйларны Татарстанның Мәдәният министрлыгы үз планы һәм программасы белән уздыра, ул финанслый, ә Татар конгрессы анда арадашчы буларак катнаша һәм ярдәм итә. Милләт тормышыннан Сабантуйларны да сызып ташларга кирәкми, ул татарлыкны күрсәтергә бер мәдәни мәйдан булып тора. Шул ук вакытта урыннарда Татар конгрессы бүлекчәләренең бөтен эшен Сабантуйлар белән генә дә чикләргә ярамый. Бөтен җирдә татар мәктәпләре бетеп атканда, милләтнең яртысы катнаш никахлардан юкка чыкканда, балалар татарча укый-яза белмәгәндә, хәтта сөйләшә алмаганда Татар конгрессы урыннарда шушы фаҗигаи афәтне туктату юлларын эзләргә тиеш.

Әйе, татарлар милләт буларак, нигездә, Идел-Уралда сакланып калачак. Анысы да бик нык тырышканда гына булырга мөмкин. Идел-Урал, дигәндә, мин Татарстанны һәм Башкорстанны

күздә тотам. Бу – милләтебез иң күп һәм иң укмашып яшәгән төбәк, тарихи татар җирләре. Кызганычка каршы, бу ике республикада да татар мәктәпләренең хәле аяныч, Бөтендөнья татар конгрессы Башкортстанда яшәүче миллионнан артык татарның телен һәм үзен саклап калу буенча аерым программа кабул итәргә һәм шул юнәлештә максатчан эш алып барырга тиеш иде. Узган корылтайда минем тәкъдим буенча Бөтендөнья татар конгрессы рәисенең Башкортстан буенча урынбасары сайланды, бер бүлекчә булдырылды, әмма ул тулы көченә эшләп китә алмады. Бу корылтайда ул мәсьәләгә яңадан әйләнеп кайтырга туры киләчәк. Уйдырма дуслык бәрабәренә без карап торып миллионнан артык татарның язмышын суга сала алмыйбыз, моңа хакыбыз да юк.

Урыннарда структуралар төзү белән бергә, бу елларда Бөтендөнья татар конгрессы зур проектлар өстендә дә эшләде. Нәтиҗәдә, төрле юнәлештә эшләүче җыен-форумнар барлыкка килде. Әйтик, моннан ун ел элек оештырылган «Татар авыллары» оешмасы «Татар эшмәкәрләре» форумы дәрәҗәсенә кадәр үсеп җитте. Мин үзем дә бу эшнең башында торганлыктан, дөньядагы татар авылларын барлау, аларның проблемаларын өйрәнү, тарихларын язу, бу авылларга ярдәм итү буенча күпме эш башкарылганын яхшы беләм. Шулай ук Конгресс каршында заманында без башлап җибәргән Ислам дине һәм милләт комитеты да даими җыелучы «Татар дин әһелләре» форумына әйләнеп китте. Татар конгрессының уңышлы эшләреннән шулай ук төбәк тарихын өйрәнүчеләрне барлап, аларны бер оешмага туплый алуын да әйтергә кирәк. Шулай ук Конгресс каршында эшләп килгән «Ак калфак» оешмасы да дөньяга сибелгән татар хатын-кызларын туплауга һәм аларны милли тамырларга кайтаруга зур өлеш кертә.

Әмма шул ук вакытта Татар конгрессының башлап ташлаган зур проектлары да булды. Әйтик, 2007 елның 20-21 сентябрендә Казанда татар галимнәренең Беренче Бөтендөнья форумы булып узды. Бу мәртәбәле җыенга дөньяның бөтен илләрендә яшәүче татар галимнәре җыелды, аларга, нинди өлкәдә эшләсәләр дә, милләтебезгә хезмәт итәргә, Татарстанга ярдәм итәргә, дигән бурыч куелды. Әмма бу форум алга таба эшләп китмәде, югыйсә, нинди зур потенциаль, халкыбызга ярдәм итәргә нинди зур мөмкинлекләр иде бит! Алга таба бу форумны яңадан эшләтеп җибәрергә, татар галимнәрен яңадан Казанга җыеп, максатларны билгеләргә кирәк, дип уйлыйм. Шулай ук зур өметләр баглап оештырылган Хокук яклау комитеты да бар көченә эшләп китә алмады. Югыйсә, бүгенге көндә безгә иң кирәге – милләтнең хокукларын яклаучы оешмалар булдыру, адым саен хокуклары бозылган татар халкы аңа бик мохтаҗ! Мордовиядә яшәүче мөслимә татар хатын-кызларының яулык проблемалары моны ачык күрсәтте, шул вакытта Бөтендөнья татар конгрессы аларны яклап мөрәҗәгать кабул итте, бу милләтебезгә зур ярдәм булды! Бәлки алга таба хокук яклаучыларның һәм шушы юнәлештә эшләгән татар юристларының, адвокатларының да бер форумын җыярга кирәктер. Европа татарлары берлеге оештырылганда, мин аларны шушы юнәлештә эшләрләр, аннан торып, Татарстанның, татар халкының хокукларын якларлар, дип уйлаган идем. Әмма алар милли пәрәмәч һәм Сабантуйдан ары китә алмады, татарны яклыйм, дип, Россия белән араларын бозасылары килмәде ахыры...

Татар конгрессы сәясәттә катнашмаса да, бу елларда милләт алдында торган кайбер социаль проблемаларны да хәл итәргә алынды. Әйтик, Чиләбе өлкәсенең Кунашак районында радиацияле зонада яшәүче татарларга ярдәм – шундый мөһим проектларның берсе, дияр идем. 2003 елның маенда Бөтендөнья татар конгрессы бирегә махсус делегация җибәрде, алар, мон-

Сабан туе. Владивосток, 2012 ел

дагы аянычлы хәлләрне өйрәнеп, атом калдыклары арасында яшәргә мәҗбүр булган татарларның проблемаларын тиешле урыннарга җиткерде. Мин үзем дә Татар конгрессы юлламасы белән биредә күп тапкырлар булдым, авыру милләттәшләребезгә Казаннан дарулар һәм китаплар илттек, татарларны яклап, судларда катнаштык. Соңыннан бу темага өч китап язып, татар, рус, немец телләрендә бастырдым, роман яздым. Нәтиҗәдә, ярты гасыр буе радиацияле зонада яшәгән Мөслим авылын башка урынга күчерделәр, монда Бөтендөнья татар конгрессының да роле зур булды.

Минем өчен Бөтендөнья татар конгрессы милләт белән эшләргә зур мөмкинлек, мәйдан булып тора. Әйе, заманында милли хәрәкәткә алмаш рәвешендә төзелсә дә, без уртак эшләрне бергә эшли алдык, чөнки милләтебез бер иде. Татар конгрессы юлламасы белән мин Сахалинда, Ерак Көнчыгышта, Себердә күп тапкырлар булып, анда яшәүче милләттәшләрем турында дистәләгән китап яздым. Шулай ук Кыргызстанга сәяхәтем дә Татар конгрессы тәкъдиме һәм ярдәме белән оештырылды, аннан мин Чыңгыз Айтматовның татар анасы турында документаль китап язып кайттым. Шулай ук башка татар зыялылары да Конгресс мәйданын милләт өчен эшләргә файдалана, әмма аларны Конгресс эшенә ныграк тартырга иде, кайберәүләр аның ишеге кай якка ачылганны да белми әле... Татар зыялылары белән бергә эшләгәндә генә ул чын мәгънәсендә «Милләт конгрессы»на әйләнәчәк. Инде егерме беренче гасырның да чиреген узып барабыз, хәзер дөнья башка, вазгыять башка, кешеләр дә башка, димәк, Татар конгрессына да алга куйган максатларны үтәү өчен үзгәрергә, заманның артыннан түгел, алдыннан барырга туры киләчәк. Ә моның өчен алдынгы карашлы яшьләргә, милләтнең акыл иясләренә, зыялыларга, иманлы татарларга, ярдәмчел милләттәшләребезгә таянырга кирәк булачак. Ә алар татар халкында бар, алдагы Конгресс та шундый милләт җанлы татарларның җыены булсын иде!

*Тулысынча **beznenmiras.ru** сайтыннан укырга мөмкин.* ■



БАБАЛАРЫБЫЗНЫҢ ЕРАК АВАЗЛАРЫН ТЫҢЛАП...

Касыйм Йосыпов*

Мин – төбем-тамырым белән авыл баласы. Сугыш елларында ач-ялангач булсак та, без тулысынча тел диңгезендә тирбәлә идек. Радио-телевизор, телефон юк, килгән газеталар – татарча. Сөйләшсәк – бары тик туган телебездә. Сак-Сок бәетен елый-елый, Әбугалисина китабын көлә-көлә укый идек. Ә менә Йосыф-Зөләйха китабын, гарәп графикасында булгач, үзебез укый алмыйбыз. Әбиләрнең укыганнарын тыңлап, хисләнеп, Йосыфны үз туганнары коега салганны тасвирлаганда чарасызлыктан ни кылырга белми утырабыз. Тагын әле кичке уен җырлары һәм, әлбәттә инде, туган телле мәктәбебез... Җидееллык мәктәпкә алмашка – Кушнарен татар педагогика училищесы. Шулай итеп, миңа унбер ел буена туган телемдә уку насыйп булды. Шушы мохит безгә дөньяны тулысынча туган телебез аша танып белүгә ярдәм иткәндер. Бездә туган тел иммунитеты көчле. Без башка барлык телләргә карата ачыкбыз. Аралашырга дисәң, безне куй. Әмма башка телләр туган телебез тышчасы аша үтеп керә алмый. Шуңа да туган телебезне кысрыклап чыгару безгә янамый. Бу яктан без хәзерге татар балаларыннан күпкә аерылабыз. Ул бахырлар, мәктәп бусагасын атлап кергәнче үк, димәк, туган телне юньле-башлы үзләштергәнче үк, радио-телевизор-компьютерлар аша чит, көчлерәк телләрнең басымы астында кала. Нәтиҗәдә, авылча әйтсәк, «ни ултара-ни пултара» халәтенә керәләр. Ул гынамы, хәзерге вакытта «дәүләт теле», яисә көчләп тагылган «туган тел» сыйфатында соңгы бер-ике дистә елда укытыла башлаган башкорт теле хәлне тагы да катлауландырды. Хәзерге мәктәпләрне тәмамлаган балаларның татарчага да, урысчага да белемнәре ифрат

сай. Татар баласы башкорт дәресе тәмамланып, кыңгырау шылтырауга ук кабат туган теленә күчә. Тик республика эчендә кая барса да, рәсми рәвештә туган теле кулланышта булмагач, мәктәпне тәмамлап, авылыннан чыгып китүгә, урысчасы алга чыга.

Туган телдә язу ихтыяҗы миндә кинәт кенә 1975 елда башланды. Сугышта җиңүнең 30 еллыгын бәйрәм иткән көннәрдә үзем эшләгән Фәннәр академиясендә конкурс игълан ителеп, аның шарты буенча Җиңү көненә багышланган материалны өч телдә язу мөмкин иде. Менә шунда инде башымны сызып бер фикер узды: «Мин дә язмасам, туган татар телемдә кем язар соң?!» Ул вакытлардан бирле байтак кына эшләр аткардым. Шуларның иң саллысы – туган авылым Сыерышбаштагы 55 нәселне (300 ел арасында) өйрәнү, тикшерү. Абруйлы белгечләрнең әйтүе буенча, дөньяда бер татар авылы да әлегә бу киселештә тикшерелмәгән. Хөрмәтле укучыларны шушы материалларга күз салырга чакырам.

Бабаларыбызның фаҗигале юллар үтеп Сыерышбашны (хәзерге Башкортстан Республикасының Чакмагыш районына керә) нигезләү вакыйгасын шул гасырларда Русиядә барган тарихи вазгыятькә күз салмыйча аңлап һәм аңлатып булмыйдыр. Чөнки халкыбыз инде мөстәкыйльлеген югалткан. Ул баскынчылар сәясәтенә буйсынган. Гәрчә рухы белән моңа каршы булса да. Шушы сәясәт аны ташкынга эләккән йомычка рәвешендә йә бер ярдан икенчесенә куалый, йә тарлавыкларга-упкыннарга ташлый. Риваятьләргә һәм рәсми документларга таянып күзалланган ул юл схемада шушылай күренер иде: 1552 елда Казан яуланып һәм аның тирәсен 40 чакрым җирләрдә татарлардан «чистарту» башлангач, Ия дип аталган зур татар авылы, сакланып калу максатыннан 5-6 ваграк авылларга бүленеп, якын-тирәдәге кара урманнарга кереп урнаша. Шул авылларның икесе Әҗәк исемле була. Әмма тиздән бабаларыбыз барыбер туган җирләреннән куыла. Алар көч-хәл белән хәзерге Актаныш районы җирләрендә Әҗәк күле дигән авылны нигезли. Ләкин бер гасырдан соң Ык-Сөн, Нократ-Чулман буйларында вәхшиләрчә чукындыру сәясәте башлангач, беренче мәртәбә көчләп чукындырылуга дучар булалар. Әмма мөселманлык рухы шулкадәр көчле була ки, бабаларыбыз, бу хурлыкны күтәрә алмыйча, янә бер Әҗәк авылын (хәзерге Башкортстан Республикасының Борай районына карый) нигезли. Әмма монда да аларны йомышлы татарларның нәсрани (православ) булуларын таләп иткән Петр I указы куып җитә. Шуннан инде хәзерге Сыерышбаш урынында янә бер авыл нигезлиләр.

* Касыйм Йосыпов – Русиянең, Башкортстанның һәм Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, икътисад фәннәре докторы, профессор, Русия табигый фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы (академигы).

Мәгълүм булганча, Русиядә 1719-1859 еллар арасында җәмгысе 10 ревизия уздырылган. Шуларның безнең якларга караган соңгыраклары белән Башкортстан Республикасы Үзәк дәүләт тарихи

архивында танышырга, ә беренчеләрен исә Русиянең Дәүләт борынгы актлар архивында табарга мөмкин. Үзебездәге архивка кергәч, табигый инде, иң башлап Йосыпов фамилиясен эзлим. (Без фамилиябезне, никтер, өлкәнрәк булган ике буын бабайларыбыздан түгел, ә тугызынчы буын бабам Йосыфтан алганбыз. Аны XIX гасыр азагында үз туганнары белән бергә минем картәтәм эшләгән. Мөгаен, бередә Йосыфның авылны нигезләүче факты өскә чыккандыр). Бер актарам, ике... Юк бит миңа кирәк фамилия. Ниһаять, өченче актаруымда күзем, ничектер, «Зиганша» исеменә төште. Тукта, безнең нәселдә Җиһанша бабай булган бит! Һәм шулай булып чыкты да. Аның янында гына миңа турыдан-туры мөнәсәбәтле бабамның бабасы (картәтәмнең картәтәсе – пра-прадед) Шиһабетдин язылып куелган. Урыс писаре, үзенчә кыландырып, «Шагибитдин» дисә дә, ул барыбер минеке! Чөнки икесенең дә фамилияләре – Әбүшахмин.

Әбүшахманың исә Җиһанша, Шиһабетдин һәм Мифтахетдинның әтисе булганлыгы бабаларыбыздан мирас булып калган «Әткәй дәфтәре»ннән үк безгә билгеле. Анда язылганча Шиһабетдин бабай өлкәнрәк түгел, киресенчә, Җиһаншадан 10 яшькә кечерәк булып чыкты. Җиһанша – походной сотник (Башкорт – Мишәр гаскәрендәге хәрби чин) булса, Шиһабетдин исә – мөтдәриз-мөхтәсип, ягъни күзәтүче, инспектор, мулладан югары дин галиме. Шул ерак бабамны кәгазем битләренә язганда ул гүя миңа рәхмәтле сүзләрен әйтә иде сыман: «Балакаем, күпме көттек без сине!» Юк, «гүя» түгел. Үз колакларым белән ишеттем бит мин ул сүзләрне. Менә шунда аткарган эшләремнең мәгънәсе арткандай булды. Ниндидер илаһи бер көч, вакытны артка кудырып, еракта калган, мин яшәмәгән елларның шаһитына әйләндерде. Шәҗәрә мәгънәсен шулчак бөтен барлыгы белән тоя, аңлый башладым шикелле. Баксаң, шәҗәрә ул – туганлыкка мәдхия. Ә кешенең иң асыл сыйфатлары туганлык, дуслык хисләренә барып тоташа. Шәҗәрә ул – хәтер саклау методикасы.

Минем әлеге уйларыма хыял канаты кую бер Шиһабетдин бабай исемен язу белән генә бәйле түгелдер. Ул ниндидер хәлиткеч, этәргеч көчкә генә ия булды. Башкортстан Республикасы Үзәк дәүләт тарихи архивын күпмедер дәрәҗәдә «үзләштергәч», Мәскәүгә китәргә киңәш иттеләр. 1719-1722 еллардагы беренче ревизия материалларын – тегесеннән дә көчлерәген – кулыма алгач, янә бер тетрәнү кичердем. Аның сәбәбе – борынгылыктан гына түгел, көчсезлектән дә. Борынгы урыс-славян графикасында язылган кулъязма материалларны уку өчен белгеч булу кирәк икән. Мин ярты көн әллә ни майтара, үземнең Сыерышбашымны таба алмыйча сәер бер халәттә утырдым. Ярый әле, архивның мәрхәмәтле кешеләре күреп-сизеп алган:

– Сезгә, бәлки, фәнни тема ачарга кирәктер?

Ул, әлбәттә, тыләүле. Шулай да бу тәкъдим мине коткарды. Икенче баруымда ниндидер алга китеш булды. Мине Ырымбур һәм Казан губерналарының картасы белән танышырга лабораториягә алып керделәр. Шул картадан Уфаны таптым, Агыйдел буйлап Чәрмәсән елгасына кадәр төшеп җиттем, аннан инде Чәрмәсән буйлап өскә таба күтәрелә башладым. Сыерыш елгасы да төшерелгән бу картага. Аның башланган җирендә минем туган авылым. Тик бу картага авыл хәзергечә Сыерышбаш дип түгел, ә «Азякъ» дип язылган булган. Нәкъ мәкальдәгечә «Юкәдә икән чикләвек, ә без имәннән эзләдек» булып килеп чыкты. Хәзерге авыл исемен эзләүдән туктап, Әҗәккә күчкәч, эшләр җайланып китте. Ярым керәшен, ярым мөселман исемнәрдәге бабаларым ят урыс-славян хәрефләре арасыннан, ниһаять, телгә килеп сыкраналар сыман:

– Арала, балакаем, безне шушы ятьмәләрдән!

Акрынлап кына Осиплардан – Йосыфлар, Адельләрдән – Годәвәлләр, Яферлардан – Ягъфәрләр, Ишмәннәрдән – Ишмөхәммәтләр, Бимәннәрдән – Бикмөхәммәтләр баш калкыта башлады.Тик үзәкләрне өзеп, инде бабайларга әйләнгән Мосейлар, Невай-Парайлар, бер генә яшьлек Тимкалар ятьмә эчендә калды. Ничәмә имгәнгән язмыш, үз иркеннән мәхрүм ителгән буын. Олы бөтен бер халык...

1722 һәм 1748 елларда уздырылган I һәм II ревизия язмаларында «Сыерышбаш» атамасы телгә алынмый әле. Баксаң, бабайлар,үҗәтләнеп, бу авылны да янә Әҗәк дип исемләгәннәр. Кызыгы һәм гыйбрәтлесе шунда ки, ревизия вакытларында бабайлар Усы юлының Әҗәк авылында теркәлеш тапканнар. Менә шул материаллардан мин үземнең Йосыф бабамны эзлим. Ә 1722 елдагы I ревизия язмасында Усы юлындагы Әҗәктә өч Йосыф теркәлгән. Шуларның кайсысы, Сыерышбашны нигезләүче 4 кешенең әйдәүче һәм ышанычлы кешесе сыйфатында, авылны нигезләүне оештырган? Куелган сорауга җавап биргәнче мин беренче ике ревизия язмаларын, анда теркәлгән кешеләрне энә күзлегеннән дип әйтерлек тикшердем. Борай Әҗәгенең шул еллардагы нәсел агачларын ясадым, Сыерышбашта хәтерләнгән риваятьләргә янә бер тәнкыйти анализ үткәрдем. Нәтиҗәдә, миңа кирәк Йосыф бабабыз авырлык белән «табылды». Ул 1722 елдагы ревизия уздырылганчы дөнья куйган булып чыкты. Әмма исеме ревизиядә күренә – Йосыф-Осип булып. Мәрхүмкәем, мөселманлыгы бик тирәндә булса да, рәсми кәгазьдә керәшен булып теркәлгән. Үзе үлгәч калган ике улы – Ишмән белән Бимәннең (бу исемнәрдә әле артык еракта калмаган керәшенлек авазлары яңгырый сыман – алар Ишмөхәммәт һәм Бикмөхәммәт мөселман исемнәренең көчләп чукындыручылар тарафыннан тагылган керәшен формасын йөртә), беренчедән, Йосыф (Осип) уллары икәне әйтелсә, икенчедән, шул ук документта аларның Йосыфның энесе Юныс карамагында булулары рәсми рәвештә әйтелгән. Ә Йосыф белән Юнысның бертуганнар булуы безгә ата-бабалардан килә торган риваятьләрдән үк билгеле. Ризаэтдин Фәхреддин язмаларында да башка авылдашлары белән бергә Юнысның һәм Йосыфның шушы ике улының исемнәре 1739 елда Сыерышбашта җир алу кәгазендә аталган. Димәк, Йосыф бабайның үзенең 3 кордашы белән Сыерышбашны нигезләү факты бәхәссез икән, бу инде безнең өчен гаять әһәмияте зур булган икенче исбатламага китереп чыгара: Сыерышбашның нигезләнүе чынлап та 1722 елдан алдарак булган.

Сорау артыннан сорау туа. Инде нигезләнгән авыл ни өчен ревизия язмаларында теркәлмәгән? Шулай килеп чыга, XVIII гасырның беренче өч чирегендә Уфа провинциясенең Усы юлында да (Борай), Казан юлында да (Чакмагыш) Әҗәк исемле авыллар булган. Уңайлык өченме, әллә башка сәбәп беләнме, күченеп утырган Казан юлы Әҗәгенең халкын төп Әҗәктә яза килгәннәр. Болай язуның сәбәбе турында мин күп уйландым. Мәсьәләне бер яклап кына аңлатып та булмыйдыр. Бер версия түбәндәгечә булырга мөмкин: Әҗәк авылларының кешеләре мишәр булып йөргән, ә мишәрләр Петр I әмере белән Усы юлында язылган һәм алар, башкорт белән беррәттән, ярымхәрби хезмәттә, ягъни империянең көньяк-көнчыгыш чикләрен саклаган. Бу – чагыштырмача җайлырак хезмәт. Лашман тартуга караганда җиңелрәк. Шуның өстенә, алар салымнардан да азат ителгәннәр. Ә менә Казан юлындагы йомышлы татарларга (шул ук Петр I указы белән) салымны да мулдан түләргә, лашман да тартырга туры килгән. Юл уңаеннан аңлатып үтим: лашман тартучы (куучы, кисүче) – хезмәт армиясе солдаты, кораблар төзү өчен урман кисүче.

1722 елда уздырылган 1нче реви-

зия язмасының фрагментын һәм аның Русиянең дәүләт тарихи архивының хәзерге язылышына тәрҗемәсендә китерәм:

1722 һәм 1748 елларда уздырылган ревизия язмаларын Р.Фәхреддиновның «Болгар вә Казан төрекләре» кулъязмасы, 23 бүлек белән чагыштырып карыйк, Р.Фәхреддиновта менә ничек язылган: *«Югарыда язылган җирләрне, урманнарны, имәнлекне, печәнлекне бирдек, шул ук Уфа өязенең Уса юлының Ачек авылының чирүмә мишәрләргә ул старшина Сөләйман Деванай углына, Смагил Тувай углына ике өлеш, вә янә Мөслим Дувай углына вә янә Мөхәммәд Кулай углына, вә янә Мөэмин Кулай углына вә янә Мөслим Мостафа углына вә янә Макай Мостафа углына вә янә Ибрай Мөхәммәт Әли углына вә янә Мансур Мөхәммәдәмин углына вә янә Юныс Әлбик углына, вә янә Мортаза Годәвәл углына, вә янә Мәхмүт Калмау углына вә янә Ишмән Йосыф углына вә янә Бимән Йосыф углына, шул ук югарыда язылган кешеләргә бирелде. Бу запись юлдашлары белән һәр елда бер түләнергә бирдек бу җирне, ун сум акча алдык»*. Телгә алынган шушы кешеләрнең һәммәсе диярлек I ревизия язмасында исәпкә алынганнар.

Чагыштыруларны уңайлаштыру өчен 1722 елдагы I ревизия язмасының Әҗәк авылына караган өлешен тулысы белән китерәм. Р.Фәхреддиновның кулъязмасында һәм I ревизиядә бирелгән түбәндәге кешеләрне бер үк кешеләр дип әйтергә тулы нигез бар, дип уйлыйм. Менә алар:

Р.Фәхреддиндә	I ревизиядә
1. Сөләйман Деванай углы	у Девая (Невай Параев улы – К.Й.) дети Сюлеман году
2. Смагил Тувай углына	Невай Параев штидесят шти, у него дети Исмаил тритцати
3. Мөслим Дувай углына	у Девая (Невай Параев улы – К.Й.) дети Муслюм одного месяца
4. Мөхәммәд Кулай углына	Кулей Исаев семидесят у него сын Махомет тритцати
5. Мөслим Мостафа углына	Муслюм Мастафин дватцати осми
6. Макай Мостафа углына	у него брат Манай (Мастафин) десяти
7. Ибрай Мөхәммәт Әли углына	–
8. Мансур Мөхәммәдәмин углына	–

9. Юныс Әлбик углына	выборной Юнус Албяков сорока шти
10. Мортаза Годәвәл углына	у Адиля сын Муртаза полутора год
11. Мәхмүт Калмау углына	Кильмет... у него дети Махмет семи
12. Ишмән Йосыф углына	выборной Юнус Албяков... у него ж племянники... Ишмень двухлет Осиповы дети
13. Бимән Йосыф углына	выборной Юнус Албяков... у него ж племянники Бимет дватцати... Осиповы дети

Ревизия язмалары арасында Сыерышбашны иң тулы тасвирлаган икесен – VI һәм X ревизияләрне аерып күрсәтмичә калып булмый. Шул ук вакытта X ревизия (1859) белән бүгенге көннәргә кадәр гасыр ярым диярлек ара бар. Димәк, бу – 4-5 буын арасы. Менә шул соңгы ревизиядән бүгенге көннәргә «күпер»не ничек салырга? БР ҮДТА хезмәткәрләре киңәше белән мөселман метрика язмалары һәм 1917 елның җәендә Вакытлы хөкүмәт үткәрергә өлгергән ихата һәм авыл хуҗалыгы исәбен алу мәгълүматлары кулланылды.

Башта – мөселман метрика язмалары турында. Мәсьәлә 1827 елда күтәрелә башлый. Сәбәбе – мөселман динендәге кешеләрнең гамәлдә тууы, никахка керү, аерылышу, үлеме турындагы информациянең бөтенләй диярлек булмавы. Исәп төгәл булмагач, салымнарны каезлау мөмкинчелеге дә кими – патша галиҗәнәпләрен иң башта менә нәрсә борчыган. 1828 елның 21 сентябрендә Сенат указы чыга. Анда мөселман метрика китапларын кертү турында сүз бара. Шулай итеп, 1829 елдан 1937 елга кадәр мөселманнар арасында туганнар, никахка кергәннәр, аерылышканнар һәм үлгәннәр турындагыларны теркәү мәчетләрдә дин әһелләре тарафыннан алып барыла. Бу хезмәтнең иҗтимагыйсәяси, милли, икътисади, фәнни өлкәләр өчен әһәмияте бәяләп бетерә алмаслык зур. Ләкин Октябрь инкыйлабыннан соң РСФСР НКВДсы шунда ук һөҗүмгә күчә башлый. Янәсе, моннан ары алар юридик көчкә ия түгел. Шуңа күрә 1924 елдан метрика китаплары «Гаилә дәфтәре»нә алыштырылалар. Ә инде 1937 елның 11 мартыннан бу эш ЗАГС бүлекләренә тапшырыла. Шулай итеп, мөселман метрика язмалары тарих киштәләрендә генә торып кала.

1860-1912 еллар араларындагы мөселман метрика язмаларын эшкәрттем. (1912 елдан соңгылары хәзерге вакытта сер булып саклана). Аннан соң мәсьәләнең башка четрекле яклары да күп. Ни кызганыч, бу язуларның татар телендә булса да гарәп графикасының иске имля белән язылуы аркасында аны укый белүчеләр ифрат сирәк. Бу безне элгәрге буыннардан аера. Аларның рухи дөньясыннан без ниндидер пәрдә белән бүленгәнбез.




дрвне нашей мужескаго полу душъ прописныхъ и утаен-
ныхъ и отлучившихся никого нет. Присемъ
вышеписанные староста и выборные тамги свои
приложили, а именно старосты Юсупа тамга ɣ
выборныхъ Мосеева тамга Ц Янаева тамга ɣ
Юнусова тамга У тое же дрвни мужа Юнус татар-
скимъ писмомъ руку приложилъ. Л

1860-1912 еллар арасына мөселман метрика язмалары гына да җитми. Эш шунда ки, еш кына кешенең бабасы күренми, ә этисе нәкъ син таба алмаган елда туарга мөмкин булган. Аннан соң, исемнәргә мода ул безнең замандагы Илдар-Рөстәмнәргә, Гүзәл-Ләйсәннәргә генә карамый. X ревизия материалларында авылда бер исем йөрткән һәм яшь аралары бик аз булган берничә ир-ат булган. Менә кызыклы бер мисал: Имаев Разетдинның (Рай абзыйның) әтисе Имаметдин (1873 елда туган), ә аның әтисе Хәйретдин икәне билгеле. Ә Сыерышбашта ике Хәйретдин булган. Мөхәммәтьяр улы булган Хәйретдин 1837-1892 еллар арасында яшәгән, ә Хөсәен улы Хәйретдин 1839-1873 еллар арасында яшәгән. Дөнья куюлары төрле вакытка туры килсә дә, дөньяга аваз салулары, яшәүләре бер тирәдә булган бит. 1873 елда ике Хәйретдиннең икесеннән дә Имаметдин туарга мөмкин булган. Бу мәсьәләне чишәргә Мәмдух абыем ярдәмгә килде: «Флүрә (Разетдин абзыйның олы кызы – К.Й.) – исле. Бәлки, ул берәр нәрсә әйтә алыр?» Һәм ул шушы сорау белән Сыерышбашка кайтып килде. Флүрә апа,чынлап та, «исле» булып чыккан. Аның әтисенә картәтәсе сөйләп калдырган булган: ике Хәйретдиннең озаграк яшәгәне, ягъни 1892 елда үлгән Мөхәммәтьяр улы Хәйретдин

аларныкы икән. Хәйретдинне әтисе (ягъни Мөхәммәтьяр) 16 яшендә көчләп 12 яшьлек Мәгърифә исемле кызга өйләндергән. Нинди максат белән булгандыр, хәзер ачыклавы мөмкин эш түгел. Хәйретдин дә, өйләнгәч, байтак кына тай-тулак булып йөргән, ә Мәгърифә су буена самаур агартырга төшкән җиреннән еш кына бала-чага уеннарына кушылып киткән. Йөрсәләр ни, китсәләр ни... Үз вакыты белән Йосыф (Осип)-Юныс нәселендәге дәрт-дәрманлы бер канатның лаек вәкиле Имаметдин туган лабаса. Ә аңардан – Разетдин – минем «Көеш эчендә сөеш» исемдәге хикәямнең төп герое Нуранбәк. Имаметдинга өстәп тагын 6 малайны да дөньяга китергәннәр Хәйретдин белән Мәгърифә.

1917 елгы ихата һәм авыл хуҗалыгы язмаларындагы һәр хуҗалыкка бер бит бирелгән. Анда чәчү җирләре, иккән игеннәр, мал-туар турында мәгълүмат күп. Әмма иң зур җитешсезлек – гаилә хуҗасыннан башка барлык шәхесләр дә – исемсез. Ярый әле яшьләре бирелгән. Шуларга карап әз-мәз хәрәкәт итеп була.

Йомгаклап әйтәсе сүз шул: Русиядә уздырылган 10 ревизиянең алтысы (I, II, VI, VII, IX, X,) Сыерышбаш турында нindидер дәрәҗәдә мәгълүмат бирә. Бу материалларга мөселман метрика язмаларын, 1917 елда уздырылган ихата һәм авыл хуҗалыгы язмаларын һәм XX гасыр җанисәпләрен кушып авылның нәсел агачлары эшләнде. Әйткәнемчә, миңа мөселман метрика язмалары буенча 1860-1870, 1871, 1873-1878, 1880-1892, 1894-1895, 1897-1899, 1900-1912 елларда (җәмгысе 53 ел) Сыерышбаш авылында туган ир җенесеннән булган кешеләрнең һәм җирләнгәннәрнең статистикасын анализларга мөмкинлек булды. Туган кеше булса, исеме, әтисенең һәм бабасының, әнисенең исемнәре һәм датасы куелган. Үлгән кеше булса, кайда җирләнүе, нинди авырудан үлүе, мәетнең яше, исеме, кайсы айда вафат булуы, ата-бабасының исеме күрсәтелгән. Бу вазифаны башкаручылар – мәхәлләнең мәчеттәге дин әһелләре. Мәгълүм булганча, Сыерышбашта 1884 елдан башлап ике мәчеттә, 1910 елдан өч мәчеттә башкарылган. Алар ел буена теркәлгән кәгазьләрнең соңында кулларын куйганнар. Атап үтелгән метрика язмаларыннан гомум саннар китерик. 1860-1899 елларда барлыгы 1028 ир бала туган һәм 384 кеше үлгән. Димәк, 36 ел эчендә авыл ир балалар хисабына гына да 644 кешегә арткан.Чөнки гамәлдә шәһәр җиренә китү булмаган да диярлек. Солдаткамы, укыргамы китсә, кире әйләнеп кайткан. Үлем-китем дә үзенең табигый кысаларында барган. Шушы еллар арасыннан мин 1892 елны сайлап алдым. Чөнки ул елны авылда ике җенестән бергә 62 кеше үлгән. Мөгаен, бу ел берәр афәт елы булгандыр. Алай дисәң дә авырулар төрле-төрле ич: эч авырудан 23 кеше үлгән, мәгълүм булмаган авырулардан 20, баш авыртудан 7, картлыктан 2, җен зәхмәтеннән 2, аяк рәнҗүеннән 2, озак сырхаудан 2, бума ютәленнән 1, ютәлдән 1, кызамыктан 1 һәм мәгъдә буларак 1 кеше үлгән. Авыру төрләренең хәтта сүзләре аңлашылып та бетмәгән бер заманында мәгълүм булмаган авырулардан ике дистә кешенең үлүе бер караганда мескенлек булып тоелса, икенче караганда исереклектән, наркоманиядән, ачлыктан, симезлектән, тапалып-имгәнеп үлүләрнең бөтенләй булмавы бер гасырдан артык элек яшәгән бабаларыбызның кешелек горурлыгын дәлилли. Аннан соң, телнең бәйсезлеге, байлыгы хәйран калдыра. Сүзлекчәбездә чит телләргә урын булмаган ул заманнарда. Афәрин, әбибабайлар!

Шулай булмый ни. Халык көр яшәгән. Эчкечелек булмагач, генофонд та көчле булган. Килешер булса, берике мисал китерим әле: Фәррухшат нәселеннән булган Габделфатыйх атлы ирнең 1883 елның 8 июлендә Әминә

исемле хатыныннан Нигъмәтҗан исемле улы туса, 11 августта исә Бәдерниса исемле хатыныннан Мөхәммәтхан туа. Йосыф (Осип) – Юныс нәселенең Баһауетдин дигән бер варисы (бая гына исемен атап үткән дәртле-дәрманлы Хәйретдиннең бертуганы) 9 улның атасы була. Шулар арасында икесе 1884 елда нибары 5 көн аермасы белән туалар: Мөхәммәтсадыйк (анасы Мәймүнә) 10 февральдә, Шаһидулла (анасы Миңлебәдәр) 15 февральдә.

Өстә язылганнарга нәтиҗә ясыйк. Ревизия язмаларын, мөселман метрика язмаларын, Вакытлы хөкүмәтнең ихата җанисәбен, XX гасырда уздырылган җанисәп материалларын анализлау аркасында хәзерге Башкортстан Республикасы Чакмагыш районы Сиерышбаш авылының 55 нәселе 300 еллык арада тикшерелде; нәселләрдәге ир җенесеннән булган һәрбер шәхеснең идентификацион номеры эшләнде (мәсәлән, ошбу мәкаләнең авторы Касыйм Йосыф (Осип)-Юныс нәселендә 1.1.1.1.5.2.1.1.1.4 саны белән йөри, ягъни мин әткәемнең дүртенче улы, ә ул үз әтитсенең беренче улы һ.б.). Йосыф (Осип) – Юныс нәселенә кагылышлы «Кем – кемгә кем» ябык матрицасы исәпләде. Бу нәселдә ир җенесеннән булган 500 зат катнашкан икән, алар матрицаның иясенә дә, хәбәренә дә кертелде. Димәк, матрицадагы күзәнәкләрнең саны 500х500=250000 тәшкил итте. Мәсәлән, Йосыф бабасы шул ук Касыймга карата картәтәсенең картәтәсенең картәтәсенең әтисе була. Аны мин шәҗәрә схемасына «кккә» символы белән урнаштырдым. Шулай итеп, безнең нәселнең затлары элеккегечә «без – туганнар инде...» дип мескенләнеп түгел, ә горурланып «без – өчтуганнар», «без – сигезтуганнар» дип сөйләшә ала. Мөселман кешесенә үзенең җиде буынын белү фарыз икән, шәҗәрәләр төзегәннән соң авылдашларның күпчелеге җидедән артык буынын белә. Мисал итеп Йосыф (Осип) – Юныс нәселендәге 14 буынлы бер канатны китерәм:

Нәселләрнең шәҗәрәләрен тәңгәлләштереп анализлау нигезендә Йосыф бабай белән Сиерышбашны нигезләргә кемнәр килгәнлеген ачыклап булды. Аларның берсе Юныс – Йосыфның энесе. Калган икесе Вәлит-Хуҗа һәм Дибай-Смәгыйль нәселләренең гыйззәтле затлары Ивакай улы Мосей һәм Парай улы Невай дип фаразлыйбыз. ■

КРАСНОЯРСК ТАТАРЛАРЫ: ТАРИХ ҺӘМ ХӘЗЕРГЕ ЗАМАН

Вәгыйзь Фәйзуллин,
Красноярск «Яр» төбәк татар милли-мәдәни автономиясе рәисе

Енисей елгасы буена килеп төпләнгән йомышлы татарлар турындагы иң әүвәлге мәгълүмат XVII гасыр башына карый. Елъязмада бояр углы Яков Тухачевскийның хәрби отряды составында йөз татар казагы да хезмәт иткәнлеге турында әйтелә. XIX гасырның урталарындагы язма чыганакларда Шулдат һәм Серебряково исемле беренче татар авыллары теркәлгән. 1861 елда Енисейск губернасында 1,5 меңнән артык татар яшәгәнлеге, ә инде 1897 елда Бөтенрусия халык санын алган вакытта 6 мең татар булганлыгы күрсәтелгән. Шулай итеп, XIX гасыр азагына татарлар губернада яшәүче халыкның 1,1 процентын тәшкил иткән.

Әби-бабаларыбыз Енисей буена Казан һәм Уфа губерналарыннан күченгән. Себергә килүчеләрнең күбесе гади крестьян булып, биредә алар игенчелек, сәүдә һәм атлы хезмәт күрсәтү белән шөгыльләнүләрен дәвам иткән.

XX гасыр башында Енисей губернасында яшәүче татарлар этник җәһәттән өч төркемгә бүленә: казан татарлары, мишәрләр һәм тугыз авылга керәшеннәр нигез сала.

Казан һәм Уфа губерналарыннан татарларның күпләп Енисей буена күченүенә Транссебер тимер юл төзелеше һәм П.Столыпинның аграр реформалары этәргән. Һиҗрәтнең икенче дулкынына – милләттәшләремнең 1920 елда туган җирләрен ташлап ерак Себергә чыгып китүенә Идел буендагы коточкыч ачлык сәбәпче. Татарлар 1960-1980 еллардагы эре сәнәгать һәм энергетика оешмалары төзелеше вакытында да бирегә шактый күченде.

XX гасырның 20 нче елларына Краснорякс краенда татарлар гына яши торган 71 авыл барлыкка килә. Нәкъ менә татар авыллары крайда тел, милли гореф-гадәт һәм мәдәниятне саклаучы учак булып тора. Бүген биредә «столыпинчы»ларның дүртенче һәм бишенче буыны яши.

Татарлар крайда, урыс һәм украиннардан кала, сан ягыннан өченче урынны алып тора. Кызганыч, халкымның саны елдан-ел кими: 1989 елда 48,3 мең татар яшәгән булса, 2002 елгы халык санын исәпкә алу вакытында 40,1 мең, 2010 елда 34 мең татар (ягъни крайда яшәүчеләрнең 1,4 проценты) теркәлгән. Кимүнең сәбәбе татар авылларының юкка чыгуы, ә шәһәргә күченгәннәрнең, туган тел һәм гореф-гадәтләрне онытып, урыслашуы белән аңлатыла. Красноярск краенда татарларның 60 проценттан артыгы шәһәрләрдә һәм шәһәр тибындагы поселокларда яши.

Крайда алты татар милли-мәдәни берләшмәсе теркәлгән. Шуның Красноярск, Лесосибирск, Норильск һәм Ша-

рып калаларындагылары мохтарият буларак эшли. «Яр» татар милли-мәдәни мохтарияте һәм «Кызыл яр» край татар яшьләре оешмасы да милләткә уңышлы гына хезмәт итә.

Крайның шәһәр һәм районнарында татарларның 14 үзешчән сәнгать коллективы бар. Губернатор карары нигезендә Красноярскидагы «Йолдыз» иҗат төркеме һәм Шарып районының «Бәхет кошы» ансамбле «халык коллективы» дигән мәртәбәле исемгә лаек булды. Алар елына 120ләп концерт программасында катнаша, шулар арасыннан бөек шагыйребез Габдулла Тукайның тууына 125 ел тулу уңаеннан узган бәйрәмне,

Куренная Ошма авылы оешуга йөз ел тулган елны Бөек Ватан сугышы батырларына һәйкәл ачу

Елга авылында татар теле укытучылары семинары

татар авыллары барлыкка килүнең йөз еллыгына оештырылган мәдәни чараларны, Сабан туйларын әйтергә мөмкин. Мохтарият тарафыннан, татар авылларындагы мәдәният хезмәткәрләре, үзешчән сәнгать төркемнәре артистларының белем һәм осталыкларын камилләштерү өчен, Казаннан килгән белгечләр катнашында махсус семинарлар оештырылды.

Сабан туе 2012-2017 елларда Красноярск краеның 20-25ләп урынында милләттәшләребезне берләштерде. Әлеге күркәм бәйрәм крайдагы җиде иң зур шәһәрдә гөрләп узды. Шулай ук аның кечкенә, 50-100 кеше генә яши торган Долгово, Шагирислам, Куренная Ошма һәм Кызыл Күл авылларында оештырылуы да шатлыклы күренеш. Гадәттә бәйрәм көннәрендә бу авылларга җыелучы милләттәшләребезнең саны 500-600 кешедән артып китә. 2015 елда исә Красноярск шәһәренең үзәгендәге, исеме үк татарча аталган Татыш утравында XV Федераль Сабан туе уздырылып, мәйдан Россиянең 36 төбәгеннән килгән 40 меңнән артык кешене берләштерде.

Кызганыч, татар теле 2 класстан 11 класска кадәр Казак районының Отношка авылы мәктәбендә генә укытыла. Пиров районының Солоуха һәм Икшермә, Олы Морта районының Югары Казанка, Олы Улуй районының Елга, Ужур районының Березовый Лог авылларындагы татар балалары туган телне факультатив рәвештә өйрәнә. Красноярск һәм Шарып шәһәрләрендә якшәмбе мәктәпләре уңышлы гына эшләп килә. 2016 елда крайның Мәгариф министрлыгы татар авылларында урнашкан барлык мәктәпләрне дә туган тел дәреслекләре һәм методик әсбаплар белән тәэмин итте, Казаннан килгән белгечләр ярдәмендә мах-

сус семинарлар оештырылды. Татар балалары ел саен Татарстанның сәламәтләндерү үзәкләрендә бик теләп ял итеп кайта.

Заманында Столыпин аграр реформалары нәтиҗәсендә оешкан авылларның йөз еллык бәйрәмнәрен үткәрү күркәм традициягә әйләнде. Бәйрәм кысаларында һәр авылда Бөек Ватан сугышы ветераннары истәлегенә һәйкәлләр ачылды. Тайга эчендәге Солоуха авылы халкына исә, янгыннан саклану өчен, ЗИЛ-131 автомобиле дә бүләк итеп бирелде.

Соңгы елларда край һәм җирле татар җәмәгатьчелеге, эшкуарлар ярдәме белән Красноярск, Лесосибирск, Норильск шәһәрләрендә һәм тагын дүрт авылда яңа мәчет төзелде. Йөзьеллык дүрт мәчет төзекләндерелде. Алар арасында гүзәл архитектура ядкәрләре – Олы Морта районының Казанка авылындагы ике катлы агач һәм Енисейск шәһәрендәге крайда бердәнбер борынгы таш мәчет тә бар.

2016 елда Красноярск краенда беренче мәртәбә Ужур районының Социалистик Хезмәт Геройлары Ногман Сәгъдиев һәм Николай Динмөхәммәтов истәлегенә көрәш буенча турнир үткәрелү дә татар егетләре арасында спортның бу төренә булган кызыксынуны үстерде.

Шулай итеп, биредәге милләттәшләребез, гореф-гадәтләрен онытмыйча, киләчәккә өмет белән яши. ■

Красноярскида Сабан туе. 2011 ел

ОНЫТЫРГА ХАКЫБЫЗ ЮК

Тәэминә Биктимерова[1]

Искиткеч тыйнак табигатьле, күркәм холыклы, туганнары, дуслары арасында гына түгел, якыннанрак аралашкан кешеләрнең дә олы хөрмәтләренә ирешеп яшәгән, нәсел архивын кадерләп саклый алган Нәҗия апа Ильясованың вафатына да унөч ел тулган икән.

Исән вакытында миңа әлеге зыялы ханым белән аралашып яшәргә насыйп булды. Олуг галимебез, якташыбыз Шиһабетдин Мәрҗанинең оныгы, мине үз якыннарының берсе санап, куандыра иде. Радиодан ясаган чыгышларымны мактап: «Әтием Таһир Ильяси хакында да сөйләсәң иде, онытылырга тиешле кеше түгел ул», – дип үтенгәне хәтеремдә уелып калган.

Әйе, гарәп теле һәм әдәбияты белгече, математик һәм галим Таһир Әхмәтҗан улы Ильясины онытырга һич хакыбыз юк. Ул 1881 елда Сарытау губернасының Кузнецки өязендәге Сүзүм волосте Индерка авылында (хәзер Пенза өлкәсенә керә) игенче гаиләсендә туган. Бабалары Казан губернасы Буа өязенең Каенлы авылында яшәгән.

Бәләкәй Таһир гыйлем эстәүне туган авылы мәдрәсәсендә башлый. Аннан соң 1893-1897 елларда Хвалынь өязендәге бер мәдрәсәдә (исеме төгәл билгеле түгел), 1897-1903 елларда Казанның атаклы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә дәвам итә. «Мөхәммәдия»дә бу елларда Фатих Әмирхан да белем ала (1895-1906). Фатих үзеннән ике елга соңрак укый башлаган Таһирны бик үз итә, якын дусларыннан саный башлый һәм бу дуслык мөнәсәбәтләре гомер буена кала. Мәдрәсәне тәмамлагач, гарәп телен һәм әдәбиятын тирәнрәк өйрәнү нияте белән, Таһир Мисырга китә һәм «Әл-Әзһәр» университетына укырга керә. Гарәп теленең тарихын, диалектларын, яңа әдәби телен җентекләп өйрәнә һәм бу өлкәдә күп кенә материал туплый. Алар нигезендә күп томлы «Гарәпчә-татарча», «Татарча-гарәпчә» сүзлекләр төзи. Аның зур «Әлмөфид» сүзлеге, Т.К. псевдонимы белән, гарәп әдәбияты хрестоматиясе сыйфатында чыгарылган. «Әдәби кагыйдәләр китабы» татар укучыларын гарәп теле, мәдәнияте, әдәбияты, фольклоры белән таныштыру үрнәге булып тора.

Моның өстенә, математиканы тирәнтен өйрәнеп, алгебра буенча татар укучылары өчен дәреслек төзи. Аның бу хезмәте «Гыйльме җәбер» исеме белән 1910, 1915 елларда нәшер ителә.

1907 елда университет тәмамлап кайткан яшь белгечне «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә эшкә чакыралар һәм ул монда 1916 елга кадәр гарәп теле, әдәбияты һәм гарәп математикасы фәннәрен укыта. Һәм шушы елларда ул олуг галимебез Шиһабетдин Мәрҗанинең оныгы Нәгыймә туташ белән никахлаша. Тиз арада шәкертләре, хезмәттәшләре арасында абруй казанган мөгаллимнең даны еракларга тарала. 1916 елда Таһир Ильясины Оренбургның атаклы «Хөсәения» мәдрәсәсенә директор вазифасына эшкә чакыралар, аңа хезмәт хакын да югары билгелиләр. (Мәгърифәтче Хөсәеновларның үз мәдрәсәләренә гел талантлы белгечләрне генә чакырып торулары мәгълүм).

---

[1] Тәэминә Биктимерова – тарих фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, 1992-1997 елларда Бөтендөнья Татар конгрессы Башкарма комитетының чит өлкәләр белән эшләү бүлеге җитәкчесе, «Ак калфак» бөтентатар хатын-кызлары ассоциациясе җитәкчесе урынбасары.

Таһир хәзрәт Ильяси хатыны Нәгыймә ханым белән

Бөтендөнья мөселманнар корылтаеннан кайтканда (уңнан сулга): Муса Бигиев, Хаҗи Мөслих, Кәшшаф Тәрҗемани, Мәһди Маһкалый, Таһир Ильяси. Истанбул, 1926 ел


برنچی قسم.

علم جبر

مرتبی: قازانده مدرسهٔ محمدیه معلملرندن

طاهر الیاس.

ناشری: معارف کتبخانه‌سی

Лито-Типографія И. Н. Харитонова. Казань.

«Гыйльме җәбер» дәреслегенең тышлыгы. Гыйльми җәбер. Төз. Т.Ильяси. – Казан, 1910. – 139 б.

Бу чорда үз эшләренә ихлас күңелдән бирелгән, укыту белән бергә фәнни эшчәнлек алып барган мөгаллимнәрдән Габдулла Ибраһимов (Шенаси), Галимҗан Идриси, Хәбибрахман Зәбиров, Закир Кадыйри, Фатих Кәрими, Шакирҗан Фәйруллин, Ризаэддин Фәхреддин һәм Таһир Ильяси энциклопедик галим буларак таныла.

Директор вазифаларын башкару белән бергә, Таһир Ильяси мәдрәсәдә гарәп теле дәресләрен дә алып бара, Оренбургның алтынчы мәхәлләсе мәчетендә имамлык итә. Биредә ул 1921 елның көзенә кадәр эшли.

1915 елда Мәрҗанинең тууына 100 ел тулуга багышлап чыгарылган хезмәттә Таһир абый да «Мәрҗанинең фикһ даирәсендәге хезмәтләре» исемле фәнни мәкалә белән катнаша. Бөек галимнең вафатыннан соң, мирас буенча үзләренә тигән китапханәсен Казан университетының Лобачевский исемендәге китапханәсенә тапшыра.

Таһир Ильяси да, хатыны Нәгыймә апа да шигырьләр язган икән. Аларны Наҗия апа кадерләп саклый иде.

1921 елда Таһир Ильясины Казанга берьюлы ике урынга – Көнчыгыш академиясенә гарәп теле укытырга һәм Мәрҗани мәчетенә муллалык вазифасын башкарырга чакыралар. Ул бу урыннарның икесендә дә эшләргә ризалыгын бирә. Ләкин Көнчыгыш академиясе торак белән тәэмин итә алмаганга күрә, өч ай эшләгәч, аннан китәргә мәҗбүр була. Чөнки мәчет янында яшәп торырлык йорты бар, ә гаиләдә бу вакытта өч бала үсеп килә... Татарстанда коточкыч ачлык хөкем сөргән заман бу. Ачлыкның сәбәпләре инде мәгълүм. Мәскәү өч тапкыр салган продразверстка, ягъни икмәк белән түләнә торган салымнарны үти-үти бер валчык икмәксез калган халык ачтан кырыла башлый.

Ачтан үлүчеләр саны бер Татарстанда гына да йөз меңнәрдән артып киткәч, Үзәк хөкүмәт «Ачларга ярдәм комитеты» оештырырга һәм чит илләрдән ярдәм сорап мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр була. (Искитәрлек хәл бит. Нәкъ шушы вакытта Халык Комиссарлары Советының беренче рәисе Сәхибгәрәй Сәетгалиев, Мәскәүдән җибәрелгән планнарны 175 процентка үтәп, бүләккә алтын сәгать ала. Казан урамнарында ачтан шешенгән, үлгән гәүдәләр аунап яткан вакытта, «Совет» кунакханәсендә, запастагы армия оркестрын чакырып, телеграфистка марҗага өйләнеп туй ясый. Мәскәү газеталары бу хәлгә бәя биреп, «Пир во время чумы» дип язып та чыга).

Ярдәм комитетына күренекле дин әһелләре дә чакырыла. Ниһаять, чит илләрдән ярдәм килә башлый, тик бу ярдәмне бүлүчеләрнең гаделсезлекләре сәбәпле, нәкъ менә татар халкына өлеш аз чыга. Бу хакта Фатих Әмирхан да ачынып: «Мәркәз рус мөхәррирләрен яхшы тәэмин итә», – дип яза.

Әлеге хәлләргә түзеп тора алмас дәрәҗәгә җиткәч, Октябрь афәте, аннан соңгы сугышлар, гаделсезлекләрнең шаһите булып, йөрәгенә якын алудан каты авырый башлаган мөфти Галимҗан Баруди Уфадан Казанга килә. Фикердәшләре, якыннары белән

киңәшләшеп алгач, ул, Татарстан халкы өчен ярдәм сорап, мөселман илләренә, ягъни Төркиягә, Мисырга барырга кирәк, дигән карарга килә. Бу гаять дәрәҗәдә мәшәкатьле бурычны ул үзенең элекке шәкерте, фикердәше Таһир Ильясига тапшыра. Таһир абый күренекле мөгаллим Гобәйдулла Буби белән юлга чыга. Галимҗан Баруди белән Кашшафетдин хәзрәт Тәрҗемани аларны Мәскәүгә кадәр озата бара.

Юлчылар Истамбулда туктап, Төркиянең абруйлы динчеләре белән очрашып, йомышларын аңлаталар. Бу вакытта сугыш алдында торган Төркиянең үз хәле дә җиңел булмагандыр дип уйлыйм. Шулай да Төркиядә чыккан газеталар: «Россиядән килгән диндәшебез Анкарага китә. Ачлыктан кырылган шималь төрекләре өчен Анталия мөселманнарының шәфкатенә өметләнеп мөрәҗәгать итәчәкләр», – дип язып чыга һәм халыкны ярдәм күрсәтергә чакыра. Төркия халкы хәйрия җыя. Иң беренче нәүбәттә азык-төлектән җыелган 125 посылка Татарстанның ач мөгаллимнәренә җибәреләә. Посылкаларның барып җитүен ишетеп, Таһир абый куана һәм көндәлегенә бу куанычын теркәп куя. Бер посылкада 5 кило кукуруз ярмасы һәм шулкадәр үк күләмдә шикәр, 2 пот ярым ак он һәм 20 банка куертылган сөт, чәй була.

Төркия акча да җыя. Җыелган акчаларны Таһир абый Америка банкларына җибәрә һәм: «Татарстандагы ач татарлар өчен азык алырга», – дип, махсус күрсәтә. Америка бу акчаларга Татарстанга азык-төлек җибәрә башлый. Кире кайтканда, алар пароходка тагын 10000 пот ак он, 1752 тартма консерва (бу консерва банкалары зур күләмле, берсеннән 200 кешегә аш әзерләп булган), ит һәм җиләк-җимеш, яшелчәләр төйиләр.

Милләт дигән изге сүзнең мәгънәсен белеп, гомерен аңа хезмәткә багышлаган Таһир Ильяси Галимҗан Баруди йөкләгән мактаулы миссияне әнә шулай намус белән башкарып чыга. Тик кайтуына хөрмәтле остазының вафатын белеп, бик кайгыра.

Сәяхәтендәниләр күргәне тәфсилләп язылган сәяхәтнамәсе милләтебезнең олы шәхесләрен һәрчак барлап, тормыш юлларын язып торган күренекле галимебез Марсель Әхмәтҗановта саклана. (Бер сөйләшүебездә Марсель бу язмаларны журналларга тәкъдим итеп караганын, әмма, ни кызганыч, журналларның аларны басып, укучыларга җиткерергә теләкләре булмаганын белдерде.)

1926 елда Таһир Ильяси Бөтендөнья мөселманнар корылтаенда катнашу өчен вәкил булып сайлана һәм Согуд Гарәбстанына бара.

1930 елда милләтебезнең олы йөрәкле, талантлы зыялысы кулга алына. Мулла булу – аның бердәнбер гаебе. Балалары мәктәпләрдән чыгарыла, гаилә ятим кала. Төрмәдән язган хатында ул, хәле бик авыр булуын әйтеп: «Мөмкин булса, сөт китерсәгез иде», – дип үтенә. Язган хаты сакланган. Пләтән төрмәсендә утырган вакытында, 11 яшьлек кызы Наҗия аның ишек алдында йөргәнен күрә, әмма сөйләшә алмый. Рәшит һәм Әмин исемле уллары көн саен төрмә ишеге янында басып торсалар да, күрә алмыйлар. Җылы киемнәр әзерләп барган көннәрендә Таһир абый этап белән озатылган була инде. Салкын Себергә ул шулай җылы киемнәрсез китә. Беломорканал төзелешендә эшли, әмма бик нык авырый башлый. Авыр хезмәттән, авырулардан хәлсезләнгән галимне Вологда өлкәсенә мәңгелек сөргенгә озаталар. 1933 елның маенда меңнәрчә милләттәшләрен ачлыктан коткарган мәгърифәтче Таһир хәзрәт Ильяси шулай ачлыктан җәфаланып, фани дөнья белән хушлаша.

«Әтиемнең исеме энциклопедиягә дә кертелмәде, шунда язарлык та бәһасе булмады микәнни?!» – дип, Наҗия апа бервакыт үзәге өзелеп елаган иде. Ни кызганыч, милләтебезнең иң асыл зыялыларына бәһа бирергә әле дә өйрәнеп җитмәдек шул. Алар һаман ерактарак, тирәндәрәк кала бирә. Ә шулай да, аларның игелекле хезмәтләре чын тарихыбыз битләреннән киләчәк буыннарга мәгълүм булыр дигән өметтә калыйк. ■

Безнең мирас №8 август 2017

МАКСАТЫБЫЗ – МИЛЛӘТЕБЕЗНЕ САКЛАП КАЛУ

Рамис Сафин,
Ульяновск өлкә татар милли-мәдәни автономиясенең Башкарма комитеты рәисе, Ульяновск шәһәре Иҗтимагый палатасы әгъзасы

Ульяновск өлкәсе – Россиядә иң күп милләттәшләребез яшәгән төбәкләрнең берсе. Соңгы тапкыр халык санын исәпкә алу нәтиҗәләре буенча, безнең Ульяновск өлкәсендә 150 меңнән артык татар кешесе гомер кичерә. Бүген татарлар барлык халыкның 12 процентын алып тора. Өлкәбезнең 67 торак пунктында милләттәшләребез күмәкләп гомер кичерә. 1997 елда, Россиядә беренчеләрдән булып, татар милли-мәдәни автономиясе төзелде. Бүгенге көндә Өлкә законнар чыгару җыелышына һәм шәһәр Думасына 9 кеше депутат булып сайланды. Төрле тармак буенча 14 милләттәшебез профессор, 105е фән кандидаты гыйльми дәрәҗәсенә ия.

Хакимият, мәгариф һәм мәдәният органнарында татар халкының мәнфәгатьләрен Ульяновск өлкә татар милли-мәдәни автономиясе яклый. Бүген безнең башкарма комитет составына 5 профессор һәм фән кандидаты, Россиянең һәм Татарстанның 15 атказанган фән һәм сәнгать эшлеклесе, 9 мәгариф хезмәткәре, 12 эшмәкәр – барлыгы 105 кеше керә. Соңгы елларда бөтен муниципаль берәмлекләрдә дә милли-мәдәни автономиянең район Советлары булдырылды. Һәм алар, җирле район хакимияте белән уртак тел табып, нәтиҗәле эш алып бара.

Быел декабрь аенда безнең автономия оешканга 20 ел була. Шуңа күрә

бүген ниндидер нәтиҗәләр ясарга да мөмкин, алга таба нинди эшләр башкарырга кирәклеге турында да уйланабыз. Мәгариф буенча горурланып сөйләрлек уңышларыбыз бар. 2004 елда Димитровград шәһәрендә татар мәктәбе ачылды, аңа Г.Тукай исеме бирелде. Бүген бу мәктәпкә укырга теләүчеләрне конкурс нигезендә кабул итәргә кирәклеге турында уйланабыз. Мәктәптә урын җитмәгәнлектән, балаларның күбесе кире башка мәктәпләргә китә. Шунысы сөендерә: әлеге мәктәпне тәмамлаган укучыларның 100 проценты да Казанда, Самарада,Ульяновскида һәм башка шәһәрләрдәге югары уку йортларына керә.

Гомумән алганда, 10 ел элек татар теле өлкә мәктәпләренең 25-30 процентында гына өйрәнелсә, соңгы елларда ул мәгариф системасының яртысына диярлек үтеп керде. Бүген Ульяновск өлкәсе мәктәпләрендә белем алучы балаларның 50 проценттан артыгы (10 ел элек 32 процент иде) ана телен фән буларак яки факультативларда һәм түгәрәкләрдә өйрәнә.

Милли мәгариф системасындагы проблемалар һәм югалтулар турында сөйләгәндә, Ульяновск дәүләт педагогия университетындагы милли төркем турында да әйтми мөмкин түгел. Узган гасырның 90нчы елларында ачылган һәм бюджет хисабына укытыла торган татар һәм чуаш төркемнәре, укырга килүчеләр булмаганлыктан, бүген ябылу алдында тора.

Шулай итеп, Россиянең һәр төбәгендәге кебек, милли тормышта кыенлыклар бездә дә җитәрлек. Гомумән, Татарстаннан читтә яшәүче татарларга бу илдә яшәү, милли мәгариф системасын җайга салу элек тә авыр булган, хәзер дә җиңел түгел, алга таба тагын да катлаулырак булачак. Федераль мәгариф министрлыгы тарафыннан, милли телләрне укытмас өчен, елдан-ел кыргый карарлар һәм законнар кабул ителә. Төбәкләрдәге татар авылларында мәктәпләр ябылу безгә икеләтә авырлык тудыра, чөнки татар авылында мәктәп ябылгач, андагы балаларны күршедәге рус яисә чуаш авылындагы мәктәпкә автобуслар белән йөртеп укыта башладылар. Ә анда мохит та, тәрбия дә безнеке түгел инде. Татар теле укыту турында бары тик хыялланырга гына кала.

Моннан берничә ел элек, федераль стандарт укыту программасына сылтау итеп, татар авылларында беренче классларда «Әлифба»ны укытмый башлаганнар иде. Безнең өлкәдә Бөтендөнья татар конгрессының күчмә утырышы вакытында без бу хакта, кем әйтмешли, түкми-чәчми губернаторга җиткердек. Ул моны акылсызлык дип атады һәм мәгариф чиновникларына яңа уку елыннан бу хатаны төзәтергә күрсәтмә бирде. Татарстан мәгариф һәм фән министрлыгыннан 500 данә һәм Бөтендөнья татар конгрессынанн 300дән артык «Әлифба» алып кайттык һәм татар авылларына тараттык.

Мәдәният өлкәсенә килгәндә, сер түгел, соңгы 20 елда татарлар яши торган авылларга Казан артистлары килми башлады. Хәзер бу бушлыкны тутыру максатыннан, татар автономиясе планлы рәвештә һәр ай саен, Татар мәдәният үзәге артистлары белән бергәләп, «Татар теле һәм сәнгате көннәре» уздыра. Без концерт куеп, күңел ачып кына кайтмыйбыз, ә андагы милли тормышны җанландыру, проблемалар хакында да сөйләшәбез, чөнки бу чараларга без район башлыкларын, мәдәният һәм мәгариф бүлеге җитәкчеләрен дә чакырабыз.

Шәһәребезнең 17нче милли китапханәсе дә безнең мәдәни тормышыбызда аерым бер урын алып тора. Ул халкыбыз өчен китап алу яисә китап уку урыны гына түгел, ә төрле бәйрәмнәр, очрашу һәм кичәләр үткәрү үзәгенә дә әйләнде. Китапханәче Гөлфия Сәмигуллина һәрчак кызыклы һәм бер-берсен кабатламый торган чаралар уйлап таба һәм мавыктыргыч итеп уздыра. Әле соңгы вакытта гына танылган шагыйрьләр Роберт Миңнуллин, Разил Вәлиев, Ренат Харис, Газинур Морат, Ркаил Зәйдулла булып китте. Анда һәр атна саен нинди

дә булса чара уздырыла. Өлкәбездә яшәп иҗат итүче каләм осталары, иҗат кешеләре – китапханәнең даими кунаклары. Шунысы игътибарга лаек: бирегә әби-бабалары белән бергә сабыйлар да җыела.

Халкыбызның гореф-гадәтләрен саклауга һәм үстерүгә исә моннан 9 ел элек өлкәбездә Татар мәдәният үзәге ачылу зур этәргеч ясады. Хәзер биредә Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Рамилә Сафина җитәкчелегендәге 22 кеше (иҗади һәм техник хезмәткәрләр белән), өлкә бюджеты хисабына, татар сәнгатенә хезмәт итә. Үзәктәге иҗат коллективларына 5 яшьтән алып 75 яшькә кадәрле үзешчәннәр йөри, аның үзешчән сәнгать коллективларына йөрүчеләрнең саны 200дән артып китте. Татарстанның атказанган артисты, Ульяновск өлкәсенең атказанган мәдәният хезмәткәре Әлфия Рамазанова җитәкли торган төркемнәр өлкәбезнең татарлар яши торган барлык районнарында гына түгел, якын-тирәдәге төбәкләрдә уза торган фестиваль-конкурсларда да катнашып, призлы урыннар алып кайта. Әлфия ханым рухи тәрбия биреп, сәнгать юлына басарга мөмкинлек ачкан балалар бүген Казан дәүләт консерваториясендә һәм сәнгать академиясендә белем ала. Мәдәният үзәгендә балалар иҗатына аеруча зур игътибар бирелә. Үз эшенең осталары, тәҗрибәле музыкаль җитәкчеләр Гөлнара Вафина һәм Алсу Әлмәтова төркемнәренә дә сабыйлар яратып йөри. Алар шәһәребездә һәм өлкәбездә уза торган һәр чарада да актив катнаша. Ә узган елда Гөлнараның «Кыңгыраулар» дип аталган балалар төркеме, көнбатыш илләрендә уздырыла торган фестивальдә катнашып, дипломант исеменә лаек булып кайтты. Күпсанлы семберлеләр үтенече буенча, Мәдәният үзәгендә татар театр төркеме ачылу да безнең мәдәни тормышта зур вакыйга булды.

Мәдәният үзәгендә халкыбыз мәгарифенә һәм мәдәниятенә багышланган даими эшләүче һәм яңартылып торучы күргәзмә ачылу да бирегә килүчеләрдә зур кызыксыну уята. Ә узган ел, Мәдәният үзәге җитәкчесе Рамилә Сафина инициативасы белән, беренче тапкыр «Сембер сөлгесе» дигән гаҗәеп кызыклы күргәзмә эшләде. Анда авыллардан 80 гә якын чигешле сөлге китерделәр. Алар арасында XIX гасырда эшләнгәннәре дә бар иде.

Монда шулай ук һәрдаим өлкәбездә яшәп иҗат итүче рәссамнарыбызның эшләреннән торган күргәзмәләр дә оештырыла. Өлкәбездә тагын бер яңа проектка нигез салынды – беренче тапкыр Яңа Малыклы районында татар гармунчыларының «Уйна, Сембер гармуны!» дигән фестивале уздырылды. Анда 30 дан артык гармунчы катнашты. Шунысы сөенечле – бу чарада балалар һәм яшүсмерләр дә зур активлык күрсәтте.

Өлкәбездә Иске Кулаткы дип аталучы, халкының 96 проценты татарлар булган уникаль район бар. Бирелә 1932 елдан бирле татар телендә «Күмәк көч» исемле газета чыга, үзләренең «Яңа дулкын» дип аталучы телеканаллары бар. Авыл мәктәпләрендә балалар программа нигезендә татар теле һәм әдәбияты укыйлар. Сирәк кенә булса да районга Казаннан язучылар да килә, район мәдәният йортында Татарстан сәнгать осталары чыгыш ясый. Авылларда мәчетләр, алар каршында мәдрәсәләр эшләп килә. Тагын бер игътибарга лаек нәрсә бар: кайбер авылларда балалар туу санының артуы күзәтелә. Шунлыктан, хәзер 90 нчы елларда ябылган балалар бакчалары яңадан ачыла башлады. Бу як турында сөйләгәндә, шушы районда туган, хәзер Саратовта яшәүче **Эдуард Ганиев** хакында сүз әйтмичә булмый. Аның бу районга ярдәмен һәм игелекле гамәлләрен санап бетерерлек түгел. Кайчакта мин, һәр татар авылында шундый кешеләр булса иде, дип тә уйлап куям. Ул һәрдаим мәдәни һәм дини чараларны уздыруда үзеннән лаеклы өлеш кертә. Узган елны Бөтенроссия авыл Сабан

туен үткәргәндә дә байтак чыгымнарны Э.Ганиев күтәрде, аны әзерләү һәм уздыруда да зур тырышлык куйды. Район башлыгының беренче урынбасары **Венера Деникаева** исә, монда узучы чараларны кызыклы итеп оештыручы, аларга яңа заманча сулыш өрүчеләрнең берсе. Быел Идел буе төбәкләрендә чыгучы татар басмаларының беренче Төбәкара фестивале дә аның тырышлыгы белән үтте.

2014 елда безнең Ульяновск өлкә татар автономиясен Федераль милли-мәдәни автономия Советы «Россиянең иң яхшы татар автономиясе» дип игълан итте һәм акчалата сертификат бүләк итте. Билгеле, бу безне тагын да тырышыбрак эшләргә, яңа башлангычларга этәрә.

Бүген шундый заман җитте: яшел флаглар күтәреп, яисә ачлык игълан итеп һәм урамнарны томалап кына нәрсәгәдер ирешеп булмый. Бөтен нәрсә дә җирле хакимият органнары белән уртак тел табып, өстәл артында сөйләшеп уртак фикергә килүдән тора. Безнең өлкә губернаторы каршында биш елдан бирле Милләтләр Советы эшләп килә. Анда өлкәдә эшләүче һәр милли оешма җитәкчесе әгъза булып тора. Советның рәисе дә – губернатор үзе. Өч айга бер тапкыр уза торган бу киңәшмәдә без – автономия җитәкчеләре үзебезне борчыган барлык проблемалар турында да әйтәбез. Барысы да булмаса да, байтак хәл ителмәгән мәсьәләләр иртәме-соңракмы чишелеш таба. Әлбәттә, ярдәм ике яклы булырга тиеш. Үзебез дә хакимият алдында бурычлы булып калмыйбыз. Һәртөрле сайлауларда, хөкүмәт уздыра торган социаль акцияләрдә, мәдәни чараларда актив катнашабыз. Мисал өчен, узган ел гына булып узган губернатор сайлауларында төбәгебездәге татар авыллары аны яклап 85-90 процент тавыш бирде. Бу коры саннар булса да, безнең Сембер татарларының сәяси активлыгы һәм «кунак ашының» кара-каршы булуы хакында сөйли.

Гомумән, соңгы елларда Ульяновск өлкә хөкүмәте милли мәсьәләләрне җайга салу һәм камилләштерү буенча шактый гына эш башкарды. Узган ел гына «Милли автономияләргә дәүләт ярдәме турында»гы Закон кабул ителде, милли концепция эшләнде.

Алда язылганнардан чыгып, Бөтендөнья татар конгрессының VI корылтаена түбәндәге тәкъдимнәрне җиткерәсе килә:

1. Тәҗрибә шуны күрсәтә, соңгы елларда татар телен өйрәнергә теләүчеләр артты. Шуңа күрә татар мәдәният үзәгендә һәм мәктәпләрдә татар теле өйрәнү курслары ачыла. Ләкин проблема туды: кемдер татарчаны ипитозлык,чәй-шикәрлек белә, ә кайсылары бөтенләй белми. Аларны ике төркемгә бүлеп өйрәтер өчен, ике төрле укыту программасы һәм дәреслекләр кирәк.

2. Татарстан хөкүмәте читтәге татарларга Конституциянең 14 нче маддәсенә нигезләнеп һәрдаим ярдәм итеп тора. Кызганыч ки, төбәкләрдәге автономия эшчәнлеген алып барыр өчен финанс чыгымнары да таләп ителә. Алдагы елларда Татарстан хөкүмәте алар өчен грантлар системасын тәкъдим итсен иде.

3. «ТЯГ» каналыннан күреп белдек, Чиләбе өлкәсендә бик матур «Татар кызы» конкурсы узды. Чибәр татар кызлары бөтен Россиядә дә бик күп. Аларны бергә җыйнап, йә Казанда, яисә Мәскәүдә Бөтенроссия конкурсы оештырасы иде. Чуаш кардәшләребез моны инде 10 елдан бирле Мәскәүдә уздыра.

4. Төбәкләрдә татар телендә иҗат итүче бик күп язучыларыбыз һәм шагыйрьләребез бар. Аларның иҗаты белән бөтен татар дөньясын таныштыру максатыннан, Татарстан китап нәшриятында елга 1-2 язучының китабын бастырып чыгаруны да җайга саласы иде.

Язмамны йомгаклап, корылтайга һәм яңа сайланган Башкарма комитетка нәтиҗәле эш теләп калам. ■

Безнең мирас №8 август 2017

КОНГРЕСС – ҮЗЕ БЕР ДӘВЕР УЛ

Фәвия Сафиуллина,
«Урал татарлары» конгрессы идарә рәисе урынбасары

Бөтендөнья татар конгрессы оешу – татар милләте тормышындагы иң әһәмиятле вакыйга, дип саныйм. Кайчандыр, сиксәненче еллар башында, язмыш җилләре туган-үскән җиреннән аерып, читкә ыргыткан татар баласы буларак әйтәм мин моны. Татарча теле ачылып, татар мәктәбен бетереп, рус теленә югары уку йортында гына кереп киткән баланы башта, кеше арасында татарча сөйләшә күрмә, татар дип көләрләр, дип өйрәттеләр. Татарча сүз ишетергә, татарча җыр тыңларга, авыз тутырып үз телеңдә сөйләшергә тилмереп яшәгән чаклар иде.

Туксанынчы еллар башында милли яңарыш чоры башлану безнең өчен бик зур үзгәреш, яңалык булды. Татар концертлары, әдәби кичәләр, Сабан туйлары, татар телендә беренче радиотапшырулар, беренче телевизион тапшырулар, беренче газеталар, дини яңарыш чоры, мәчетләр төзелү – бу үзгәрешләр Казанда Бөтендөнья татар конгрессы төзелгән чорда башланды. Конгресс татарны уятты! Бар төбәкләрдә дә татар милли тормышы җанланып китте.

Безнең Свердловск өлкәсендә, рәсми мәгълүматларга караганда, хәзерге көндә 150 меңгә якын татар кешесе яши. Узган гомер белән чагыштырып карасак, хәзерге милли тормышыбыз сыйфаты ягыннан бик нык үзгәрде. Элеккеге милли тормыш башлыча энтузиастлар кулында булса, хәзер без хөкүмәт органнары белән тыгыз элемтәдә эш алып барабыз. Әйтик, 2005 елдан башлап, Свердловск өлкә Сабан туйларын, өлкә хөкүмәте карары нигезендә, хөкүмәт ресурсларын кулланып уздырабыз. Быелгы өлкә Сабан туена кадерле кунак булып Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов килгән иде.

Гадәттә, өлкәбездә ким дигәндә 37 Сабан туе уздырыла. Кайбер белгечләр әйтүенчә, Россиядә, Татарстан белән Башкортстаннан кала, иң күп Сабан туе уздыручы төбәк без булып чыгабыз. Урындагы Сабан туйлары җирле хакимият органнары белән бергә оештырыла.

«Урал татарлары» конгрессы, Татарстанның Уралдагы даими вәкиллеге белән бәйләнештә, ел саен зур күләмле чаралар уздыра.

Гадәттә ел «Ак Барс» хоккей клубы призына Төбәкара хоккей турниры белән башланып китә. Анда катнашырга дип, Свердловск, Чиләбе, Төмән өлкәләреннән, Пермь краеннан, Башкортстан Республикасыннан җыелалар. Февраль аенда күренекле кулинар Юныс Әхмәтҗанов истәлегенә багышланган

Татар ашлары фестивале оештырыла. Фестивальдә махсус белем бирү уку йортлары, көллиятләр студентлары актив катнаша, бу татар милли кухнясын профессионаллар арасында популярлаштыруга зур йогынты ясый. Шулай ук татар әдәбияты һәм сәнгате көннәре, театр һәм җыр сәнгатен үстерүгә юнәлтелгән конкурслар, семинарлар да уздырыла.

Татар китапларын, татар әдәби мирасын саклау, популярлаштыру йөзеннән, «Тере классика» дип аталган Төбәкара бәйге оештырыла. Быел, мәсәлән, чарабызның төп кунагы булып Чулпан Муса кызы Җәлилова килде. Чарада катнашкан йөзләгән татар балаларына бөек шагыйребезнең кызы белән очрашу нинди тәэсир ясаганын сөйләп аңлатырлык түгел.

Ел саен киң колач белән «Урал сандугачы» фестивале уздырыла. Фестивальгә Россиянең төрле почмакларыннан катнашучылар җыела. Ул Свердловск өлкә Мәдәният министрлыгының еллык эш планына кертелгән, шулай ук аны уздыруда Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы да берникадәр ярдәм күрсәтә. Фестиваль «Татар моңы» Халыкара җыр бәйгесенең сайлап алу туры буларак та билгеле.

Өлкәбездә инде унбиш елдан артык «Саф чишмә» исемле татар газетасы чыгып килә.

Милләтне, телне, мәдәниятны концертлар, Сабан туйларын оештыру белән генә саклап калып булмый. Иң борчыган мәсьәлә – милли мәгариф.

Свердловск өлкәсендә туган телне белүчеләр саны, 1989 елгы җанисәп мәгълүматлары буенча, 73 процент булган. 2010 елда исә – 44 процент. Телне белүчеләр 30 процентка диярлек кимегән! Кызганыч ки, татар теле һәм әдәбиятын укытучы мәктәпләр саны елдан-ел кими бара. Әйтик, Свердловск өлкәсендә моннан ун ел элек татар телен фән буларак 23 мәктәптә укытсалар, хәзер 19 мәктәптә генә, дәресләр саны да атнага 1-2 сәгатькә калып бара.

Милли мәгариф системасы, гомумән, бер урында таптана. Моңа милли оешмалар гына гаепле түгел, билгеле, күп кенә объектив сәбәпләр дә бар. Еш кына татар телен укыту кимүне ата-аналарның балаларны туган телгә өйрәтергә теләмәгәнлекләренә сылтыйбыз. Укучы балалар саны кимү аркасында оптимизация уздыру кайбер татар авылларында мәктәпләр ябылуга китерде.

2012 елдан 2017 елга кадәр «Урал татарлары» конгрессы барысы унике грант отты. Милли мәгарифне үстерү буенча отылган грантлар барлык этномәдәни компонентлы мәктәпләргә уку-укыту әсбаплары алуга, эшләп килгән якшәмбе мәктәпләрен оргтехника белән заманча җиһазландыруга, балалар коллективлары һәм башка коллективлар өчен милли костюмнар тегүгә тотылды. Мәдәният министрлыгы игълан иткән грантлар исә – төрле зур чаралар уздыруга һәм милли китапханәләрне китаплар белән тәэмин итүгә китә.

Милли китапханәләрдә китап фондларын яңарту – аерым бер актуаль мәсьәлә. Күптән түгел без өлкәдә китапханәләр арасында татар мәдәниятын үстерүгә кем күпме өлеш кертә дигән темага бәйге үткәрдек, бәйге барышында китапханәләр эшчәнлегендәге күп кенә проблемалар ачыкланды. Эшлисе эшләребез биниһая күп әле!

Сүземне йомгаклап, шуны әйтәсем килә: татар кешесе, кая гына барса да, татар булып кала. Күңелләрдә милли горурлыкны саклаучы, читтә туып үскәннәрнең милли үзаңын үстерү өчен җанын-тәнен биреп янып яшәүче милләттәшләребезне бер казанга туплаучы Татар конгрессы бар. Конгресс – үзе бер дәвер ул. Татарны – татар, мин – татар, дип горурланып әйтерлек иткән дәвер.

Чирек гасыр эчендә бик күп эшләр эшләнгән, бик зур тәҗрибә тупланган. Үткәннәрдән сабак алып, алга таба атлыйсы да атлыйсы. Без үткәннән начаррак эшләргә тиеш түгел. Камиллекнең чиге юк. Өлкәннәрнең тормыш тәҗрибәсен яшьләрнең бетмәс-төкәнмәс энергиясе белән кушып, АЛГА, ТАТАРЛАР! ■

Безнең мирас №8 август 2017

ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ

КӘШШАФ ПАТИИ
(XIX йөз азагы-XX йөз башы)

Кәшшаф Патии-Зимәнчәви элеккеге Хвалын өязе, хәзерге Ульяновск өлкәсенең Иске Кулатки районында Зимәнчә авылында туа. Аның шигъри әсәрләре Г.Тукай һәм К.Мотыйгинның Уральскидагы матбугат басмаларында ук дөнья күрә. 1902-1905 елларда Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә Ф.Әмирхан җитәкчелегендәге әдәби түгәрәк эшендә актив катнаша.

К.Патии, мәдрәсә тәмамлагач, берара мулла булып тора, соңрак балалар укыта. 1906 һәм 1912 елларда шагыйрьнең «Тугыз чәчәк», 1910 елда «К.Патии шигырьләре», 1915 елда К.Зимәнчәви шигырьләре» һәм «Эшгар» исемле шигырь китаплары басылып чыга.

Мандалин

Кайчагында кулга алам, –
Мандалинны тарткалыйм,
Һәр нидән үлгән күңелгә
Төрле сер аңлаткалыйм.

Таш күңелне шундый пакь
Тавыш белән йомшаткалыйм, –
Яртылаш сүнгән рухымны
Тергезәм, нурлаткалыйм.
Һәрбер эч пошкан чагында
Уйныймын мин мандалин:
Шул галәмнән мәгънәви дәрт,
Мәгънәви тәм алгалыйм.

Яңа Зимница (Зимәнчә) авылы күренеше

Илләрдә

Бар, рәхәтлән, егет, чык илләргә,
Урман-суы бай, мул җирләргә;
Хәсрәтеңне сөйләп таратырсың
Ил кызлары – нәзкәй билләргә.

Бар син, мәәюс[1] егет, бар илләргә,
Күңелле, ак көнле җирләргә;
Илләрдә ил дәрте, җан рәхәте –
Ауру күңелләргә, чирләргә.

Барсаң, егет, йөрсәң ул илләргә,
Гомрең әрәм китмәс җилләргә;
Анда ил кызлары каршы алыр
«Лилләр-лилләр» җырлап илләрдә.

Бүтән җирдә түгел, тик илләрдә
Тап килерсең матур, тиңнәргә;
Чапкай итеп гармун каршысында
Җыр җырларсың «лилләр-лилләр»гә.

Тукайга

Тукай, син бриллиант халкың күзендә,
Һаман ялт-йолт итәр «Ялт-йолт»
йөзендә.

Бәлəнд[2] рухың, бәләнд аң диңгезендә,
Тирән эз калды ул узган эзендә.

Гали максатка юл ачкач сүзеңдә,
Барыр мәңге, калыр үз телемездә.

Шүрәлең көлдерә кич, көндезендә,
Хыяллар чәнчелә үткен безеңдә.

Тыныч тор, акланып тор акбүзеңдә,
Чәчәк атты гөлең дә һәм гүрең дә.

Югалды, үлде, дип гамь чиксәләр дә,
Көләсең, җырлыйсың син йир түрендә.

Эдуард Әнвәр улы Ганиев,
Ульяновск өлкәсенең Иске Кулаткы районы хакимияте башлыгы, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының бюро әгъзасы:

«Әгәр без борынгы бабаларыбыз мирасына игътибарлы булсак һәм аны сакласак, телебезне белсәк, Сабантуйларыбызда очрашып торсак – ышанам, татар милләтен зур киләчәк көтә!»

[1] Мәәюс – өмидсез.
[2] Бәләнд – биек.



ТАТАРЛАРНЫ ҮТЕРҮ ВӘ МӨСЕЛМАННАРНЫ БЕТЕРҮ СӘЯСӘТЕ ТАРИХЫ

Ләбиб Сәлим

***Мәкалә Фәүзия Бәйрәмова Татарстан Республикасы Милли китапханәсенә бүләк иткән, Г.Исхакый тарафыннан Берлинда нәшер кылынган «Яңа милли юл» журналыннан алынды.**

Казанда бу көнгәчә җимерелми калган вә бердәнбер татар төсе булган Сөембикә манарасын белмәгән кеше юк. Менә шул сөекле Сөембикә үзе Кырымнан килеп Казанга хан булган Сафагәрәй ханның[1] хатыны иде. Сафагәрәй хан үлгәндә бишектә Үтәмешгәрәй исемле углы калган иде. Казанлылар шул баланы ике яшендә хан итеп куйдылар. Аның ханлыгын анасы Сөембикә итә иде. Ләкин ул вакытларда Казанда көч калмаган, үзара талаш вә ызгышлар берлә кырымлы,

**Дәвамы. Башы журналның 7 нче санында.

[1] Сафагәрәй хан Нурсолтан бикәнең Кырым ханы Миңлегәрәйдән казанлы туган углыдыр. Нурсолтан бикәнең Казан ханы Ибраһимнан туган углы Мөхәммәдәмин хан үлгәч, бу Сафагәрәй Казанга хан булган иде. – *Автор иск.*





казанлы татар вә нугай мирзалары бер-берсе берлә тартышалар иде. Шул чакларда урыслар татарларга бер уен уйнап, сәясәт ясап, аларның кулыннан Сөембикә берлә Үтәмешгәрәйне дә кулларына төшерделәр. 1551 нче елның 11 нче августында Сөембикә берлә Үтәмешгәрәй тоткын ителеп Казаннан алынды вә Мәскәүгә озатылды. Ике ел соңра 6 яшендәге Үтәмешгәрәйне көчләп анасы кочагыннан аерып алдылар да 1553 нче елның 8 нче гыйнварында чукындырып, Александр исеме берлә дүртенче Иванның сараена куйдылар. Анда урысча өйрәтеп, укытып, чын урыс итәргә тотындылар. Анасы Сөембикәне дә Иван Грозный шул мәлгунь, татар дошманы булган Шаһгалигә хатын итеп бирде. Менә шулай итеп урыслар кулына тоткын төшкән һичбер татар үзенең татарлыгында вә ислам динендә кала алмый иде, йә камакларга салынып ачка үтерелә, яисә куркытып, көчләп, кызыктырып чукындырыла вә урыс ителә иде.

Хәлбуки Казанның иң соңгы гомерендә, 1552 нче елда шул мәлгунь Шаһгалинең өченче мәртәбә Казанга урыслар тарафыннан көчләп хан ителгән заманында татарлар кулында 60 мең исән-сау урыс тоткыны бар иде. Шаһгали шуларны азат иттерде. Татарларда урыс тоткыннарының диненә вә җанына касд итү кебек вәхшилекләр юк иде. Алар кулында коралы булмаган вә сугышу нияте берлә каршыларына чыкмаган урысны үтерүне акылларына да китермиләр иде. *«Иелгән башны кылыч кисмәс!»* – дигән бабайлар сүзе татарлар өчен бер канун иде. Шулай да булса, урыслар һәрвакыт татарларның вәхшилегеннән зарланып, урысларны татар җәбер вә золымыннан коткару өчен, дип, Казан өстенә сугыш ачалар вә дөньяда охшашы күренмәгән вәхшилекләрне ясыйлар иде. Шуны ясау гына түгел, шул төсле ялганнарны, үзләре эшләгән коточкыч вәхшилекләрне китапларына *«татарлар эшләде»*, дип язып вә

шуңа тарих, дип, бер фән вә белем исеменнән дөньяны да алдаталар иде. Менә Казанны сугышып алган вакытта дүртенче Иванның эшләгән вәхшилекләрен тарихларда эзләп табарга да бик читен.

1552 нче елның 30 сентябрендә Казан тышында, урманнарда посып калган татар чәриләре берлә булган канлы сугышта тоткын ителгән 340 татарны Иван Грозный ике ут арасына казыкларга бәйләп куеп, Казан эченнән атылган татар укларына каршы, урысларга ышыклангыч итеп кулланды.

1552 нче елның 2 нче октяберндә урыслар Казанны ватып-җимереп эченә кергәч тә, татарлар соң өмет берлә Казан урамнарында бик каты сугышып карадылар. Ахырында, җиңеләчәкләрен белгәч, берничә минутка урыслардан сугышны туктатуны сорадылар. Шул тукталуда Казанның соң ханы булган Ядегәр Мөхәммәдне урысларга тапшырып: *«Без сөекле йортымыз вә ханнарыбызның утрагы булган олуг Казан шәһәре булып торганда соң чиккә чаклы сугыштык, инде Казан калмагач, менә ханыбызны исән-сау көегә тоткынлыкка тапшырабыз. Сез аны үзегезнең патшагыз янына илтегез. Калганнарыбыз сезнең берлә актык савыт үлемне эчәр өчен киң яланга чыгабыз»*, – диделәр.

Менә шул төсле егетчә сүзләр сөйләп, арысланнар кебек сугышкан шанлы татар чәриләреннән бик күбесе, сугышырга коралы вә угы калмаганлыктан, тоткын булдылар. Вәхши Иван шул тоткыннарның һәммәсен дә үтертте. Казанда тоткын ителгән әллә ничә мең хатын-кыз вә бала-чаганы урыс чәриләренә сугыш бүләге итеп таратты вә һәммәсен дә чукындырды.

Иң соңында Иван, бер ел камакта яткырганнан соң, Ядегәр Мөхәммәд ханны да 1553 нче елның 26 нчы февралендә чукындырып, Мария Кутозова дигән бер марҗага өйләндерде вә бик зур туй ясады.

Иван Грозный Казанны алып, шул ук көндә Казан эченә кергәч, аның беренче эше хан сараеның башына тәре (хач) тагу, мәчетләрне ваттырып, алар урынына чиркәү торгызу вә Казан әйләнәсендәге коймаларны йөреп, өсләренә чиркәү суын сибеп чыгу булды. Күккә карап: *«Әй, хөрмәтле Гайсә! Мөхәммәд һәм аның аздыручылары урынына үзеңнең тергезүче тәреңне вә сыныңны китергәнлегең өчен сиңа шөкерана кылабыз!»* – диде.

Мәскәүдәге митрополит Макарийга язган хатында Казанны сугышып алганын вә андагы мәчетләрне туздырып, алар урынына чиркәүләр салдырганын белдерде. 1552 нче елның 29 нчы октябрендә Мәскәүгә кайткан Иван Грозный үзен Мәскәү тышында каршылаган халык алдында митрополит Макарийга карап сөйләгән сүзләреннән кайберләрен алабыз: *«Күкнең югарысыннан мәрхәмәтле Алла безне күрде. Үзенең җумартлыгын безгә багышлап, ханлык урыны вә күп кешеле булган Казан каласын, анда торучы бөтен кешеләре илә безнең кулыбызга бирде. Мөхәммәднең билгесен (мәдрәсә вә мәчетләрен) бетереп, аның урынына вә Казанның әшәке яланына тергезүче тәресен утыртты. Анда торучы мөселманнар Алланың хөкеме буенча бөтенләй һәлак булды. Казанның патшасы Ядкяр Мөхәммәд үзе генә тере булып, безнең янга килде. Электә пычрак булган Казан каласын Ата, Угыл, Изге җан – бүленми торган Аллалык исеменә тәкъдис иттек. Пакь булган Алла атамыз исеменә чиркәү торгыздык, Алланың башка изгеләре исеменә дә ничәләп чиркәү салдык... Гайсә үзенең ару каны бәрабәренә гөнаһтан йолып алган вә безгә тапшырылган христианнарны дошманлардан сакласа иде. Үзенең изге теләве берлә безгә бирелгән вә яңа гына яктыртылган Казан каласын үзенең изге исеменә саклап, аңарда христианлыкның чын булган хөкемен урынлаштырса иде. Ялган диниләрне чын булган христианлыкка авыштырса иде. Алар да безнең илә бергәләп «Изге өчлек» – Ата, Угыл, Изге җанның исемен олугласа иде...»* Менә болар Казан ханлыгының бетерелүендә вә бөтен татарларны кулга алуның нәрсә мөкаддәс булганлыгын бик нык ачып бирәләр.

Яңа милли юл. – 1930. – №5. ■

Безнең мирас №8 август 2017

КАЙТАВАЗ

МӘРЬЯМКӘЙ БӘЕТЕ
(Барда варианты)

Язучы Индус Фатыйх улы Сирматовның мөрәҗәгатенә җавап итеп (Безнең мирас. – №6. – Б.23), «Мәрьямкәй» бәетенең **Пермь өлкәсендәге Барда районының Кодаш авылында** *сакланган вариантын җибәрәм. Күп сәламнәр белән, журналны яратып укучыгыз* **Фәймә Мөбәрәк кызы Газизова**.

Кичен фабрикадан кайтканда
Каты аурыды Мәрьямкәй.
Агуланган Мәрьямкәйне
Салдылар больницага.

«Коткармагыз, коткармагыз,
Мин барыбер үләрмен;
Рәхәтемне, михнәтемне
Каберемдә күрермен».

Беренче көн килде аның
Әткәсе хәл белергә.
Доктор аңа җавап бирде:
«Шул көенчә ята», – дип.

Икенче көн килде аның
Әнкәсе хәл белергә.
Доктор аңа җавап бирде:
«Авыр хәлдә ята», – дип.

Өченче көн килде аның
Сөйгәне хәл белергә.
Доктор аңа җавап бирде:
«Ул подвалда ята», – дип.

Подвалларга төштеләр,
Кара гроб күрделәр.
Кара гроб эчләрендә
Мәрьямкәйне күрделәр.

«Ач, Мәрьямкәй, ач, Мәрьямкәй,
Ач, Мәрьямкәй, күзеңне.
Ачмасаң, Мәрьямкәй, күзеңне,
Харап итәм үземне». ■

ОСТАЗЛАР

Мөҗәһит Әхмәтҗанов,
Татарстанның атказанган укытучысы, шагыйрь

ДИРЕКТОР

Адәм баласы үзенең үткән тормыш юлына әледән-әле әйләнеп карый. Әйләнеп карый да нәтиҗә ясый, күз алдыннан кичерә. Инде илленең теге ягына атлап чыккан кешенең баштан кичергәннәре турында әйтер сүзе дә, бәясе дә булмыйча калмыйдыр. Мин сөйләргә теләгән кеше дустым да, авылдашым да, сабакташым да түгел. Ул – гап-гади, ләкин шул ук вакытта без укыган Күбәк урта мәктәбе укучыларының күпләре өчен бик тә хөрмәтле, кадерле һәм яраткан укытучыбыз, директорыбыз Диктат Галиевич Галиев (1934-2017).

Мин аны 5 нче сыйныфта укыган чагымнан ук беләм. Без кечкенә Түреш авы-

лыннан Күбәк урта мәктәбенә килеп укыган вакытта директорлык эшен күптән түгел генә кабул итеп алган һәм шул ук вакытта байтак тәҗрибә дә туплап өлгергән педагог иде ул. Минем күңелемдә Диктат Галиевич тирән белемле дә, таләпчән дә, бераз гына усал да, шуның белән бергә эчкерсез һәм хәлеңә керә белүче өлкән иптәш тә булып калган. Унынчы сыйныфны тәмамлаганчы, директорыбыз алышынмады. Безгә аның эш стилен дә, характерын да, педагогик осталыгын да, укучыларга булган карашын да башка директорлар белән чагыштыру мөмкинлеге булмады. Без бер Диктат Галиевичне белдек. Иң яхшы директор да, укытучы да шулай була торгандыр, дип тәрбияләндек. Моңа ныклы нигез дә бар иде. Узган гасырның 60 нчы елларында Күбәк урта мәктәбенең чәчкә аткан чоры булгандыр, мөгаен. Укуда да, спортта да, сәнгать өлкәсендә дә безнең мәктәп алдынгылар рәтендә булды. Анда эшләүче кадрлар да саллылар иде шул. Җырчы, курайчы, спортчы Карл Әхмәтов, төрле музыка коралларында уйнаучы, оркестр, хор белән җитәкчелек итүче, җырчы, көйләр язучы Спартак Әхмәтов, атаклы җыр укытучысы, үзешчән композитор Васыйл Әхмәтҗановлар үзләре генә дә ни тора иде!

Диктат Галиевичнең күп кенә уңай сыйфатларын мин бүгенге җитәкче кадрларга күчереп куяр идем. Ул үз укучысы белән ихластан горурланды, аны күрсәтергә тырышты, хөрмәтләде, данлады; аны исем-фамилияләп белде, кул биреп күреште, хәл-әхвәлләрен сорашты. Безнең директорыбыз кайбер кешеләргә хас булган начар гадәтләрдән бөтенләй азат иде: качып-посып та тәмәке тартмады, спиртлы эчемлекләрне якын да китермәде, сүгенмәде, җикеренмәде, кул күтәрмәде. Өлкәннәр белән дә, балалар белән дә мөгамәләсе һәрвакыт яхшы булды. Анда балаларны алдау гадәте дә юк иде. Ул һәрвакыт сүзендә торды. Бервакытта да, соңга калып, кемнәрнедер көттереп торганын хәтерләмим. Эш урынына беренчеләрдән булып килә, иң соңыннан кайтып китә иде.

Югары белем алып, армия сафларында хезмәт итткәннән соң, үзебезнең районга укытучы булып кайттым. Бу вакытта безнең директорыбыз район партия комитетында идеология секретаре булып эшли иде. Миңа район комсомол комитетында һәм мәктәптә Диктат Галиевич белән байтак гомерләр бергә эшләргә насыйп булды.

Диктат Галиевичнең район партия комитетында эшләгән чорына бәяне һәркем үзенчә бирәдер. Гадәттә җитәкче кешене күпләр сөйми бит. Тәнкыйтьләнгән, утлы табага бастырылган мизгелләр макталуга караганда күбрәк була торгандыр ул. Берәүне дә эштә бәпләп кенә тормыйлар. Бүген аны хәтерләүчеләр, аның кул астында эшләүчеләр байтак. Ләкин мин 7-8 ел аннан аерылып торсам да, элекке директорыбызның әллә ни үзгәргәнен сизмәдем. Ул тагын да таләпчәнрәккә әйләнгән, көч-куәте ташып тора, җитдиләнгән кебек кенә күренде. Райком секретаре вазифалары мәктәп директорыныкы кебек кенә булмагандыр шул.

Бүлмәсендәге өстәлдә һаман шул газета-журнал өелеп торыр, телефон өзлексез шылтырар, читкә-миткә кагылышлы бер генә сүз дә булмас. Бары тик эш, эш, эш... Фикерең булса, әйт тә чыгып кит. Ишек төбендә аның янына керү өчен таң белән бер төркем кеше чиратта. Кемдер үз теләге белән килгән, кемдер чакырылган... Райком бинасы иртән иртүк умарта күчедәй гөжләп тора.

Төрле өмәләр оештырганда, инициатива, җитәкчелек күп вакыт Диктат Галиевич кулында була иде. Узган гасырның 70 нче еллары башында хәзер Сабантуй үтә торган паркка нигез салу дисеңме, Калинин исемендәге ял паркындагы картайган америка чаганнарын кистереп, яңа агачлар утырту, аларны һәр оешмага, һәр кешегә беркетеп тәрбияләп үстерүме – һәрберсе Диктат Галиевичнең тынгысызлыгы арка-

сында тормышка ашырылды. Бүген Мөслим урамнары яшеллекккә күмелеп утыра, кунакка килгән кешеләр район үзәгенең чисталыгына сокланып китәләр икән, монда Диктат Галиевичнең дә шактый өлеше барлыгын онытмыйк.

Без бу чорда «Коммунистик җәмгыять»не ихлас күңелебездән төзедек. Мөслим районының комсомол һәм партия пропагандистлары республика күләмендә һәрвакыт мактауга лаек булды. Алар төрле Мактау такталарында, китапларда урын алды. Узган гасырның 80 нче еллары башында комсомол политмәгарифе системасындагы эшнең оештырылышы бөтен республика күләмендә мактауга лаек булды. Район, партия һәм комсомол комитетларының эш тәҗрибәсе, өйрәнелеп, барлык районнарга таратылды. 70 нче елларда колхоз производствосында, төзелеш яисә башка оешмаларда эшләүче алдынгылар төрле чит илләргә бушлай туристик походларга бару бәхетенә иреште. Хәтта районыбыздан дистәгә якын кеше дөньякүләм олимпия уеннарында тамашачы буларак катнашты. Районда оештырылган академик хорның Мәскәү Кремлендәге Съездлар сараенда чыгыш ясавы, Гаяз Авзалов, Халидә Спиридонова-Уразаева, Асия Галиева башкарган җырларның әледән-әле республика радиосыннан яңгырап торуы беркемне дә битараф калдырмагандыр. Без әле бүген дә шул уңышларыбыз белән горурланабыз. Диктат Галиевич мәгариф, мәдәният өлкәсендәге эшләрдән бик хәбәрдар булып, аларны җаны-тәне белән яратып башкарды. Ул мәдәният йортында үткән бер генә концертны да калдырмады. Укучы балаларның үзешчән сәнгатенә бигрәкләр дә игътибарлы булды. Мәктәп дирекцияләренең эшчәнлегенә ул җиңел генә, бер концертта утырып та бәя бирә торган иде.

Диктат Галиевичнең соңгы еллардагы эшчәнлеге Чаллы һәм Казан шәһәрләре белән бәйле. Ул һәрвакыт үзенең төп профессиясенә тугрылыклы булып калды. Чаллы шәһәрендә иң зур мәктәпләрнең берсе белән үрнәк төстә җитәкчелек итте. Аңа шул хезмәтләре өчен «Татарстанның атказанган мәктәп укытучысы» дигән мактаулы исем бирелде. Казан шәһәренә күчеп киткәч тә, ул укытучыларның белемен күтәрү институтында бик актив эшләде. Республика мәгариф бүлекләренең эшенә ярдәм итте, алдынгы тәҗрибәләр тарату өлкәсендә җиң сызганып шөгыльләнде.

Диктат Галиевичнең гаиләсе һәркемгә үрнәк булды. Аның тормыш иптәше Зөһрә ханымны райондашлар гади, кешелекле, һәрвакыт ярдәмгә килергә әзер торучы шәфкать туташы буларак белә. Кызлары Гүзәлия белән Лилия дә этиләре юлын сайлады – педагоглар булды. Диктат Галиевичләр нәселләре белән педагоглар дисәк тә ялгыш булмас. Аның туганнары Зәнфирә апа белән Гөлсинә апа – олы хөкүмәт бүләкләренә ия булып, лаеклы ялга чыккан укытучылар. Гөлсинә апаның кызы Зөлфия дә Мөслим лицеенда алдынгы укытучы.

Диктат Галиевич утырткан агачлар аны бүген дә онытмаганнардыр, юксыналардыр сыман тоела. Районыбыз үсешенә байтак хезмәт гомерен багышлаган укытучының эзе аның белән бергә эшләгән хезмәттәшләрендә, укучыларында саклана. Бу эз әле озак еллар буыннар эстафетасы булып дәвам итәр, дигән ышаныч яши.

АБЫЙ

Гомеребез буе аны хөрмәт итеп, авылыбызның аксакалына тиңләп яшәгән барлык Түреш халкының иң кадерле кешесе – беренче укытучыбыз Хәсән абый Салиховка без, исеме белән дә, фамилиясе белән дә мөрәҗәгать итмичә, бары зурлап һәм ихтирам белән «абый» дип кенә эндәшә идек. Безгә генә түгел, бездән өлкәнрәк авыл кешеләре өчен дә ул «абый» иде. Абый безгә белем бирде, тәрбияләде, еласак – юатучыбыз, өшесәк, җылытучыбыз булды. Олы кешеләрнең сүзләре әле һаман

Хәсән абый Салихов хатыны Марьям апа белән

да колак төбендә яңгырап тора кебек: «Менә абыйны күргән идем, ул шулай дип әйтте, болай дип әйтте... Әгәр тәртип бозсагыз, абый кирәгегезне бирер...» Абыйның «кирәкне бирүе» бастырып сүгү дә, колакны бору да түгел иде. Аның җикеренеп кычкырганын, өстәл сукканын мин бөтенләй хәтерләмим. Әгәр син дәресеңә әзерлексез килеп яисә тәртип бозып, үзеңә генә класс бүлмәсендә калырга насыйп булдымы, шул җитте инде: аннан да каты җәзаның булуы мөмкин түгел.

Абыйның өйгә килүе безнең өчен олы бер вакыйгага була торган иде. Ул киткәннән соң да аның «уңай энергиясе» атналарга, айларга җиткәндер. Абыйның өйдән чыгып киткәнен ындыр, сарай капкаларының ярыкларыннан тилмереп күзәтә идек. Урам капкасы ябылып, әтиең яисә әниең өйгә кереп киткәч, карак мәче кебек, йомшак кына басып, өйгә үтәсең. Анда сине абый тарафыннан бирелгән бәя көтә. Аның инде тискәре ягы арттырылган булыр, ә яхшысын сиңа җиткерергә ашыгып тормыйлар, чөнки бозылып китүең бар. Шуннан соң син атналар буена әти-әни сүзенә тулысынча буйсынып яши башлыйсың: ялкаулык юкка чыга, дәресләргә әзерләнү беренче көн тәртибенә килеп баса иде. Күпмедер вакыт үткәннән соң гына, әкренләп, тормышның үз буразнасына төшәсең.

Хәсән абый – төп Мөслим кешесе. Бөек Ватан сугышыннан әйләнеп кайтканнан соң, аларны хатыны Мәрьям апа белән (ул да укытучы) район үзәгеннән 25 чакрым ераклыктагы Түреш авылына укытырга билгелиләр. Шул урнашудан алар Түрешне үз итә. 1972 елга кадәр Хәсән абый белән Мәрьям апа авыл халкына аң-белем тарату эше белән шөгыльләнде. Алар авызыннан беркайчан да «сезнең авыл», «сезнең балалар», «надан», «аңгыра» кебек сүзләр ишетелмәде. Безнең өчен алар гомерлеккә Түрешнең төп кешеләре булып калды. Хәсән абый авылыбызның табигате, кешеләре белән горурланырга ярата иде. Шул гадәтен ул үзенең укучыларына онытылмаслык итеп сеңдергән ахры. Без, авылыбыздан күптән чыгып киткән укучылары, һәрвакыт Түрешебезне, аның гаҗәеп кешеләрен сагынып яшибез. Җәйләрен булса да кайтып, су буйларында, ындыр артларында, печәнлекләрендә йөреп, күңелебезне юатабыз. Яшь чакларны искә төшерәбез. Мәрхүм эшмәкәр авылдашыбыз Хәерзаман Идиятуллин инициативасы белән Түрештә үткәрелгән Сабантуйда абый белән апаны очратып, озак кына сөйләшеп торган идек. Сабантуйны Хәсән абый ачып җибәрде. Аның белән сөйләшергә, күрешергә теләүчеләр бихисап иде. Бик күпләрнең

күңелендә онытылмаслык вакыйга булып калды ул мизгелләр. Бүген авылыбызда абыебыз да, апабыз да юк инде. Язмыш җилләре аларны Түбән Камага, уллары янына күчәргә мәҗбүр итте. Алар белән бергә диярлек Түрештә балалар да, мәктәп тә, клуб та, кибет тә бетте. 70 йортлы Түреш авылында кышын 15 ләп кенә йортта җылылык саклана хәзер.

Түрешкә килеп керү белән, абыйларның аркылы такта кадакланган тәрәзәле өйләренә күзем төшә. Күңел нидер көтә сыман. Үзем дә аңламыйм. Авылыбызга абый җитми кебек. Бүген укытучысыз калган авылым бердәнбер көнне тернәкләнеп, терелеп китәр төсле. Урам буйлап бала-чагалар чабышыр, дим. Хәсән абыебызны, Мәрьям апабызны алыштырыр мөгаллимнәр дә килеп чыгар әле, Алла боерса. Хәсән абый безгә коммунизм дигән җәмгыятьнең кайчан да булса бер килеп җитәчәге турында үзе дә ышанып, безне дә ышандырып сөйли иде. Шуңа күрә дә түрешлеләр бик тырышып укыды. Әгәр белемгә битараф булмасалар, бер бәләкәй генә авылдан 80ләп югары белемле кеше, очучылар, табиблар, артистлар, язучылар (алары гына да өчәү) чыгар идеме икән? Түреш халкының газ ягып җылыначагы, чишмә суының өйләргә кадәр керәчәге, гомер буе юньле юл күрмәгән авылдашларымның асфальт түшәлгән юллардан гына йөриячәге күз алдына да килмәгәндер. Кадерле абыебыз бакыйлыктан авылыбызга кайтып керсә, үз күзләренә үзе ышанмас иде. Ни кызганыч, безнең Түрештә генә түгел, башка авылларда да мөгаллим абыйлар, хәтта апалар да кимеп, югалып бара.

Ә безнең абый сөйләгән матур тормышка һаман да булса ышанычыбыз югалмый. Күренекле артист Хәлим Җәләй әйтмешли, сандугач оясыдай Түреш кебек матур авыллар югалырга, бетәргә тиеш түгел. Матурлык барыбер үзенекен итәр әле. Без шуңа өметләнәбез.

....

ХАРРАС ӘЮП

АБЫЙ

Беренче укытучым
Хәсән ага Салиховка

Бала күңеле – язылмаган кәгазь,
Кәгазьләрегезне җил тараткан...
Гомер буе язганнарыгызның
Мин бер генә бите бер тарафтан.

Кемне кая илтеп ташламыйдыр:
Җил генәме – давыл бит бу, абый!
Югалырлык түгел язганыгыз –
Сезнең кулны күзсезләр дә таный.

Нинди кара белән язгансыздыр:
Бозып карадылар туксан тугыз –
Бозалмыйлар,
Безгә язган чакта
Йөрәк булган кара савытыгыз...

Кәгазьләрегезне җил тараткан...
Ут аркылы чыгасы бит, абый!
Утка төшеп, көлгә әйләнгәнче
Укып биреп бетералсам ярый!..

1992

МӘГАРИФКӘ БАГЫШЛАНГАН ГОМЕР

Роза Низамова,
Татарстанның атказанган укытучысы

Мин укытучылар гаиләсендә туып үстем. Әнием – Мөнәздәһә Тимерхан кызы Тимерханова 37 ел буе башлангыч сыйныф балаларына белем бирде. Әтием Нәгыйм Гали улы Гайсин тарихчы иде. Ул 17 – яшеннән фронтка китеп, сугышның бөтен авырлыкларын үз җилкәсендә кичергән шәхес. Каты яраланып, сугыштан кайткач та, ул үзенең яраткан эшенә – мәктәпкә укытырга килә. 43 ел туган авылы Мөслим районы Әмәкәй авылында балаларга тарих фәненнән белем бирә, шуның 16 елын шул ук мәктәптә директор булып эшли.

Әнием гаҗәеп төгәл, бик матур җырлый, әдәбиятны, балаларны ярата иде. Гаиләдә без 5 бала үстек. Әти-әниебез, үрнәк тәрбия биреп, һәрберебезне югары белем алуга ирештерде.

Әтием безнең өчен тәрбиялелек, яшәеш эталоны булды. Карап торуга кырыс күренсә дә, бик киң һәм нечкә күңелле, ярдәмчел, табигатьнең һәр матурлыгын күңел аша үткәрә белүче шәфкать иясе иде. Мәктәп баласының һәрберсен изге зат итеп карап, укытучыларга: «Кеше балаларын рәнҗетмәгез, икеле куярга ашыкмагыз, хулиганнар һәм җәмгыятькә үчле кешеләр тәрбияләмәгез», – дип әйтә торган булган.

Әтием көчле оештыручы да иде. Искиткеч сәләтле, тырыш, бердәм укытучылар коллективын туплый алган. Ул эшләгән чорларда укучылар белән системалы рәвештә өстәмә эшлиләр иде. Авыл баласына эстетик тәрбия бирү максатыннан «Нәфис сүз», «Фото», «Театр», «Тегү-чигү», хәтта музыка уен коралларыда уйнау түгәрәге дә оештырыла. Түгәрәк белән музыка укытучысы Спартак Әхмәтов җитәкчелек итә. «Һәр бала нота белән нинди дә булса уен коралында уйный белергә тиеш!» дигән девиз үзен аклый, мәктәпне тәмамлаучылар арасында профессиональ музыкантларның үсеп чыгуы, һәр баланың диярлек аерым музыка коралында уйный белүе моның ачык дәлиле булып тора. Бу елларда районда үткәрелгән һәр чарада мәктәп бары тик алдынгы урыннарны гына яулый иде. **Мәктәбебездә газета-журналлар һәм китап укуга зур игътибар бирелде.** Укучылар мәктәп һәм авыл китапханәсендәге китапларны гына

Нәгыйм белән Мөнәздәһә

Роза Нәгыйм кызы Низамова төсле җепләр белән чигелгән картиналары янында

түгел, район китапханәсендәге китапларны да укып бетереп бара иде.

Мәктәптә төрле кызыклы чаралар үткәрелә иде (диспут, әдәби кичә, бию кичәләре һ.б.). Төрле елларда Әмәкәй мәктәбеннән бик күп күренекле шәхесләр үсеп чыкты. Озак еллар мәктәп директоры булып эшләгән РСФСРның мәгариф отличнигы Хөснулла Хәмидуллин да, күренекле шагыйрь һәм язучы Факил Сафин да, филология фәннәре докторы Дания Заһидуллина да – әтиемнең укучылары.

Әтием белән бергә эшләгән, районыбызның ихтирамга лаек укытучысы Гөлфия Мөхәммәтгәрәева үзенең бер мәкаләсендә әтием турында болай дип язып чыкты: «Нәгыйм Галиевич белән бергә эшләү, шул чорда алган «тормыш дәресләре» минем гомеремә җитәрлек педагогик мирас булды». Каты авырый башлагач та, әтием түшәнкелеккә бирелмәде. Үзенең фикерләрен, яшәү, тормыш турында уйлануларын көндәлеккә теркәп барырга көч тапты. Көндәлекнең соңгы бите мондый юллар белән тәмамалана: «Бу дөньяга килгәнемә, яшәвемә үкенмим. Тормышның ачысын-төчесен, бәхетсезлеген, кайгы-хәсрәтләрен – барысын да татып карадым. 17 яшемдә сугышка киттем, күпме сугышчан дусларымны югалттым... Каты яралар алдым, ләкин исән калдым. Минем яшәвем кирәк булган... Тормышым мәгънәсез үтмәде, шуңа сөенәм. Минем эшемне дәвам итүче кызым бар. Мин дөньядан канәгать китәм».

Әдәбиятны, туган телебезне, балаларны ярату мине дә мәктәпкә тартып китерде. Гомеремнең иң матур мизгелләре Мөслим лицеенда татар теле һәм әдәбияты укыткан еллар булгандыр.

Укучыларыма сүзнең тәмен, шатлыгын аңларга, әдәби сүзгә сокланып, аны саклап, дөрес, матур итеп куллана белергә өйрәттем. Халык авыз иҗаты әсәрләрен, татар халкының гореф-гадәтләрен, тарихыбыз һәм мәдәниятебез үсешенә багышланган материалларны төрле алымнар белән балаларга җиткерүгә зур әһәмият бирдем.

Дәресләремнең төп үзенчәлеге – җирле материаллардан, якташ язучыларыбызның иҗат җимешләреннән киң файдаланып, аларны бөтен тулылыгы белән балаларга җиткерүдән, аларда туган якка мәхәббәт тәрбияләүдән гыйбарәт иде. Ә андый иҗади шәхесләр җирлегебездә

җитәрлек: Фоат Садриев, Харрас Әюпов, Зөлфәт, Факил Сафин, Флүс Латыйфи, Фәрит Гыйльми, Шәмсия Җиһангирова, Ләбиб Лерон һ.б.

Эшләү чорында укучылар өчен әдәби-драма театры оештырдым. Минзәлә шәһәрендә уздырылган зона бәйгеләрендә коллектив призлы урыннарны яулады.

Сәләтле балалар белән аерым программа нигезендә эшләдем, нәтиҗәдә алар район һәм республика олимпиадаларында призлы урыннар яулады. Бөтен тырышлыгымны биреп, нәтиҗәле итеп башкарган хезмәтем югары бәяләнде. Мөслим районы мәгариф бүлегенең һәм Татарстан Республикасы мәгариф министрлыгынын күпсанлы Мактау кәгазьләре, 2000 елда Татарстан мәгариф министрлыгының «Мәгарифтәге казанышлары өчен» күкрәк билгесе белән бүләкләндем, ә 2002 елда миңа «Татарстан Республикасының атказанган укытучысы» дигән мактаулы исем бирелде.

Лаеклы ялга чыккач та тулы канлы тормыш белән яшәүне дәвам иттем. Төсле җепләр белән чигеп картиналар эшләү һөнәрен үзләштердем. Үз кулларым белән чиккән 100дән артык картинам бар. Шулай ук калфак чигү белән мавыгып киттем. Бу һөнәремне балаларга да, яшьләргә дә мирас итеп калдырырга телим.

Өлкәннәр белән дә, мәктәп балалары белән дә төркемнәр туплап, аларга чигү эшенең бөтен нечкәлекләренә төшендереп, төрле алымнарны күрсәтәм, күргәзмәләр оештырам, мастер-класслар үткәрәм.

Районыбыз үзешчәннәренең иҗат концерты көннәрендә картиналарым Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының фойесын бизәсә, Алабуга шәһәренең мең еллыгын бәйрәм иткәндә, алар Мөслим делегациясенең чыгышын тулылындырып, бизәп торды.

Күзгәмәләремнең иң зурысы Мәдәният елы кысаларында 2014 елның августында мәгариф хезмәткәрләренең киңәшмәсе көннәрендә булды. Күргәзмә ай буе дәвам итте. Һәр көнне мин лаеклы ялдагы хезмәттәшләрем белән бергә тәрбия сәгатьләре, тормыш дәресләре, күренекле якташларыбыз белән очрашулар уздырдым. Мөгаллимнәр, күргәзмәгә бәя биреп: «Матурлык һәм зәвык тәрбияләүдә иң күркәм чара», – диделәр.

Иҗатым турында «Ватаным Татарстан», «Земля-землица», «Авыл утлары» газеталарында бик матур мәкаләләр басылып чыкты.

Үзем эшләп чыккан Мөслим лицее коллективы белән тыгыз элемтәдә торам. Яшь укытучылар өчен ачык дәресләр, тәрбия сәгатьләре, шигърият кичәләре оештырам.

Оныкларым укыган Мөслим гимназиясендә әбиләр советы әгъзасы булып торам. Балаларыбыз өчен кичәләр, бәйрәмнәр оештырабыз, концерт-спектакльләр куябыз, экскурсия-походлар оештырабыз. 2017 нче елның май аенда күп кенә талантлы шәхесләр үсеп чыккан Түреш авылына экскурсия оештырдык. Бу авылда туган күренекле шагыйрьләр Харрас Әюп, Мөҗәһит Әхмәтҗанов, Ләбиб Лерон шигырьләрен балалар бик матур итеп укыды. Авыл халкы белән очрашу Түрешнең горурлыгы булган «Харрас чишмәсе» янында узды.

Ветераннар советы оештырган «Картаймагыз әле, ветераннар» клубы эшендә дә актив катнашам. Кичәләр, концерт программаларын алып барам.

Иҗат дәртен сүндермичә, яшьләргә үрнәк булып, тәҗрибәмне биреп, өлкәннәрне бергә туплап, файдалы эшләр башкарып, тормышымнан ямь һәм тәм табып яшәргә омтылам.

Озак еллар мәгариф өлкәсендә эшләү чорымда әтиемнең: «Әти-әниләр сиңа иң кадерле кешеләрен – балаларын ышанып тапшырган, бер генә баланың да язмышына битараф булма», – дигән алтын сүзләре колагымда һәрвакыт яңгырап торды. ■

Безнең мирас №8 август 2017

Фронтовик укытучылар – педагогларның үзгә бер когортасы. Бөек Ватан сугышында укытучылар катнашмаган бер генә зур сугыш та булмаган. Советлар Союзы Маршалы Александр Василевский болай яза: «Укытучы фронтта да, окопларда да үз профессиясенә тугры калды – шәхси үрнәге белән ничек сугышырга икәнен өйрәтте».

Кемнәр соң алар – фронтовик укытучылар? Сугыштан соңгы язмышлары нинди булган? Бу – үзенә бер кызыклы тема. Аларның һәркайсы хакында аерым китап язарга булыр иде, чөнки һәрберсе үз фронт юлын үткән һәм ул юл фашизм өстеннән гомуми җиңүгә китергән. Мондый укытучылар белән безнең мәктәп тә горурлана ала. Шуларның берсе турында язып үтәргә телим.

Виктор Александрович Иванов 1916 елның 27 декабрендә ТАССРның Мөслим районы Яңа Усы авылында крестьян гаиләсендә дөньяга килә. Башлангыч, аннары җидееллык мәктәпне бетерә.1934 елда ул Минзәлә педагогия училищесына укырга керә һәм аны 1937 елда бик яхшы билгеләренә генә тәмамлый. 1937 елдан 1940 елның февраленә кадәр Мөслим районының Татар Шураны мәктәбендә химия, биология һәм физика укытучысы булып эшли.1940 елның февралендә Кызыл Армия сафларына алынып, октябрь аенда Киев авиация-техник училищесын тәмамлый һәм истребитель авиациясенә самолетларның махсус җиһазлары механигы, техник хезмәт старшинасы итеп җибәрелә.

Әмма тыныч тормыш һәм алга таба уку планнарын сугыш боза. В.А.Иванов сугышның беренче көненнән 1945 елның декабренә хәтле Хәрби Һава Көчләре сафларында Бөек Ватан сугышының төрле фронтларында була. 16 нчы Һава Армиясенең 774 нче «Суворов» һәм «Александр Невский» орденлы истребитель авиациясе пол-

ГОМЕР ОЗЫНЛЫГЫ ДӘРЕС

Светлана Җәләева,
Мөслим лицееның тарих укытучысы

Виктор Иванов гаиләсе белән

кында зур сугышчан юл үтә. (Әлеге полкка, Берлинны алгач, Берлин исеме бирелә). Аерым алганда ул, отделение командиры, истребитель төрендәге самолетларның өлкән механигы буларак, Сталинград, Курск, Керчь һәм Киев шәһәрләрен, Белоруссия, Австрия һәм Польшаны азат итүдә, Берлинны штурмлауда катнаша. Күрсәткән батырлыклары өчен «Кызыл Йолдыз» һәм Бөек Ватан сугышы» орденнары, «Сугышчан хезмәтләре өчен», «Батырлык өчен», Сталинград оборонасы өчен», «Варшаваны азат иткән өчен», «Берлинны алган өчен», «Фашистлар Германиясен җиңгән өчен» медальләре һ.б. бүләкләр белән бүләкләнә. Германиядәге гаскәрләр сафында булганда 1945 елның ноябрендә демобилизацияләнә.



Виктор Иванов

Өйгә кайткач, үзенең күптәнге югары белем алу хыялын гамәлгә ашырырга уйлый һәм 1946 елда Казан дәүләт педагогия институтына читтән торып укырга керeп, 1950 елда табигать-биология факультетын тәмамлый. Шул елларда Мөслим урта мәктәбендә химия һәм физика фәннәрен укыта, балаларга ныклы белем бирү өстенә, аларның күңелендә табигатькә, туган төбәккә мәхәббәт тә тәрбияли. Һәм барысына да ярдәм итәргә тырыша.

1949 елның ахырында Мөслим урта мәктәбе янып китә. Шундый авыр вакытта – 1950 елның мартында В.А.Ивановны мәктәп директоры итеп билгелиләр. Виктор Александрович җиң сызганып эшкә тотына һәм мәктәп, кыска вакыт эчендә торгызылып, гадәти режимда эшли башлый. Директор буларак, ул педагогик алмаш әзерләүдә дә күп көч куя.

Мөслм урта мәктәбе республика авыл районнары арасында иң зурларыннан берсе санала. Анда 1200-1300 бала укый, аларга 100ләп укытучы белем бирә. В.А.Иванов директор булган чорда (1950-1977 еллар) биредә 4 атказанган укытучы, 17 халык мәгарифе отличнигы хезмәт куя. Ул мәктәпнең укыту һәм матди-техник базасын ныгытуга да күп көч сала, ярдәмче корылмалар – интернат, мастерской, спорт залы, музей бинасы, җылыту үзәге һәм мәктәпкә ике янкорма да төзетә.

Виктор Александровичның фидакарь хезмәте нәтиҗәсе буларак, мәктәптә өлгереш елдан-ел үсә бара, аны тәмамлаучылар һәр елны югары уку йортларына, техникум һәм училищеларга керә. Ул директор булганда 70тән артык укучы мәктәпне алтын һәм көмеш медальләргә тәмамлый. Мәктәптә аның башлангычы һәм укытучыларның көче белән төбәкне өйрәнү музее оештырыла, анда 3000нән артык экспонат санала. Музей эшчәнлегенә районның һәм республиканың югары оешмалары тарафыннан югары бәя бирелеп, дипломнар һәм ТАССР Мәгариф министрлыгының Кубогы белән бүләкләнә. В.А.Иванов 10 елдан артык авыл советы һәм район советы депутаты итеп сайлана, «Халык мәгарифе отличнигы» билгесенә, «Хезмәт ветераны» медаленә лаек була.

Бүгенге көндә аның ике улы – Альберт Викторович һәм Алмаз Викторович белән хатыны Светлана Әнәсовна, әти-әниләренең эшен дәвам итеп, Мөслим лицеенда укытучы булып эшли. Ивановлар династиясенең гомуми эш стажы 214 ел тәшкил итә. Виктор Александрович үзе мәктәптә 43 ел буе хезмәт куеп, 1990 елда вафат булды.

Виктор Александрович Иванов күпләргә үрнәк булырлык гомер кичерде. Бу олы шәхес хакындагы якты хатирәләр укучылары, аны якыннан белгән кешеләр күңелендә гомерлеккә сакланыр. ■

ДАМИР ИСХАКОВ: «ОФЫКЛАРНЫ ЕРАГАЙТАСЫ ИДЕ»

Күренекле җәмәгать эшлеклесе, тарих фәннәре докторы, этнолог, политолог Дамир Исхаков 65 яшьлеген билгеләп үтте. Шул уңайдан галим белән очрашып әңгәмә кордык.

– Сез – утыздан артык китап чыгарган, фәнебезне, милләтебезне үстерүгә шактый зур өлеш керткән кеше. Шул хезмәтләр арасында иң мөһиме кайсы дип уйлыйсыз?

– Чынлап та, 65 яшь тулгач, алга да, артка да карыйсың. Офыкның бик еракта түгел икәнлеген чамалыйсың. Бу яшьтә бер урында озаграк таптансаң да ярый. Мин гомер буе этнология, этнография өлкәсендә эшләдем. Төп белгечлегем шул. Күпләр оныткандыр инде: мин – Казан татарлары арасында этнология буенча беренче фән докторы. Хәзер инде яңа, яшь докторлар да бар, тик алар нигездә этносоциология юнәлешендә эшли. Минемчә, безнең җәмгыятьтә этнологиянең әһәмиятен аңлап бетермиләр. Моны аңласалар, мин эшләгән Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтында этнология юнәлеше бетүгә таба бармас иде. Мин узган ел ахырында гына этнология бүлегеннән урта гасырлар тарихы бүлегенә күчтем. Хәзер элекке бүлектә этнология буенча ярты ставкада утыручы бер генә кеше калды. Элек ул этнология буенча ачылган бүлек иде. Аның исеме әле хәзер дә шулай. Әмма бүген анда белгечләр калмады. Россия – күп милләтле җәмгыять. Мондый җәмгыятьтә этнологиянең кирәге чыгып тора.

2002 елны уздырылган халык санын исәпкә алу вакыйгасын – Мәскәү ягыннан басым ясап, татарны 40-50 төркемгә бүләргә җыенуларын искә төшерик. Бу омтылышка фәкать этнология яссылыгында гына җавап бирә алдык. Шул вакытта этнологлар да кирәк булды. Бу эштә бик актив катнашкач, моны мин яхшы беләм. Этнологлар киләчәктә әле кирәк булачак. Ни кызганыч, аларга эш урыны юк. Бүген вазгыять шундый. Дөресен генә әйткәндә, гомумрәсәй халәте бу.

Үзем эшләгән эшләр арасында иң әһәмиятлесе – татарларның тарихи демографиясен һәм тарихи этнологиясен эшләүдер, мөгаен. Бу мәсьәләләргә төрле яктан карарга мөмкин. Шулай да

гуманитар өлкәдә күзаллавы булган кеше совет чоры белән бүгенге дәверебездәге халәтебезнең ничек аерылуын шунда ук чамалаячак. Чынлыкта без зур эшләр башкардык. Билгеле, мин эшләгән эшләр генә түгел, күмәк хезмәтләр дә булды болар. Әйтик, татарларның алты томлык тарихи этнографиясен яздык. Барча татарның традицион мәдәниятен тасвирлау, тарихи-этнографик атлас дип атала ул. Аның да сәер яклары бар. Биш томы Казанда чыкты. Алтынчы томын бездә нәшер итә алмагач, Казакъстанда чыгардылар да, Казанга ике нөсхәсе генә кайтты. Татарларның каралты-курасын, традицион йорт-җирләрен тасвирлауга багышланган китап бу. Авторы үлеп китте дә, аны башка кеше әзерләп бетерде. Аны бер саллы китап итеп чыгарасы иде.

– Татарның таралышы дигәннән, узган ел ахырында Уфада булган татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр җыенында ясаган кызыклы күзәтү-нәтиҗәгез истә калды. «Татар – бер ул. Татарстан, Башкортстан, Пермь, Себер тарафлары аша узып, Алтайга барып җитәсең. Анда да татар кешеләре яши. Патша Россиясе, Совет заманында зур татар милләтен төрле аз санлы халыкларга бүлеп, төрле исемнәр тактылар», – дип сөйләгән идегез. Этнология өлкәсендә эшләмәгән белгеч булса, биш йөз татар авылын җәяүләп кичмәсә, Алтайга баргалап йөрмәсә, галим мондый нәтиҗәгә килмәс иде.

– Чынлап та шулай. Тәмамлап килә торган яңа хезмәтемдә татар халкының егерменче гасырдагы демографиясенә анализ ясадым. Анда барча халык санын исәпкә алуларны тикшереп, «сөреп» чыктым. Бик кызыклы нәрсәләр бар. Безнең галимнәрдә демографиягә гомумән игътибар бик аз. Эчкәрәк кереп карасаң, хәтта совет чорында уздырылган халыкны исәпкә алу мәгълүматларында да уйландыра торган сан-күрсәткечләр шактый күп. Шуларның берсен генә телгә алып китәм. Әйтик, 1926 елгы җан исәбе алу мәгълүматларында Алтайда хәзер татар дип йөртелмәгән төркемнәрдә дә бу исем-атама шактый еш очрый.

Мәсәлән, хакас дип билгеләнгән төркемнәр дә телләрен татар теле дип яздырган. Аларның милли үзаңнарында да, без – татар, дигән төшенчә булган. Бу бит кызык! Бүгенге күзлектән аларны бәлкем татар дип карап та булмыйдыр. Хакас булып оешкач, алар инде бүген хакас булып йөри. Чынлыкта кеше үзен татар дип атаган икән, ул татар кешесе булып кала ләбаса. Әйтик, үз телләрен белмәсәләр дә, без Литва татарларын да татар дип йөртәбез, берничек тә төшереп калдыра алмыйбыз. Шул ук 1926 елгы мәгълүматларда Дагстанда биш меңләп татар булуы күренә. Җан исәбен алу вакытында кешенең милләтен сораганнар. Икенче сорау туган телне ачыклауга кагылышлы булган. Ул вакытта Дагстанда милләтен татар дип яздыручылар биш мең булса, туган телен татар теле дип яздыручылар – унҗиде мең. Тикшереп караган идем, күренде: туган телен татар дип яздыручылар анда яшәгән нугайлар икән. Димәк, әле 20-30 нчы елларда Дагстанда яшәгән нугайларның башларында яртылаш булса да, без татар инде, дигән күзаллау булган. Димәк, татар этносын тасвирлаган вакытта әле без хәзер дә күп нәрсәне төшереп калдырабыз. Моңа тарихи карарга кирәк.

Татарлар кайчандыр гомумән Үзәк Азиядә генә яшәгән. Аннан соң таралганнар. Таралган вакытта күпмедер өлеше барыбер шунда калган. Шуларның «калдыкларын» бүген дә чамалый алабыз. Алар тел ягыннан да безгә бик якын. Үзебезнең татар диалектологларының да сөйләгәне бар. Себер татарлары диалектларын өйрәнгән вакытта әкрен генә үзгәрү процессы барганын, ягъни Алтай телләренә күчүләрен күзәтергә мөмкин икән. Аермалык булса да, болар – шул ук бер тел эчендәге сөйләшләр. Моның тамырлары бик еракка барып тоташа. Бәлкем, исән-сау булсам, бу хакта яңа бер хезмәт язармын әле дип торам. Тарихи этнология булса да, тел белгечләре өчен дә кирәк бу. Чөнки алар, телләргә классификация ясаганда, тарихи мәгълүматларга да игътибар итә. Хәзер төрки телләрне төркемнәргә бүлеп өйрәнгән яңа карашлар бар. Анда татар теле белән кыпчак теле арасындагы үзара мөнәсәбәтләр яссылыгында ыгы-зыгы күзәтелә. Димәк, киләчәктә яңа, кызыклы нәтиҗәләр ясалырга мөмкин.

Чынбарлыкта кыпчак теле – хәзерге татар теленең урта гасыр варианты гына ул. Урта гасырда Идел буендагы әдәби тел, шул ук вакытта Урта Азиядә чагатай, үзбәк теленең беренче вариантлары да бар. Ул, мөгаен, башкачарактыр. Аңа уйгырларның йогынтысы булган.

Кимак дигән зур халык булган бит. Аларны Көнчыгыш кыпчаклар дип тә йөртәләр. Аларның дәүләте Иртыш бассейнында, Иртышның көньяк өлешендә булган. Унберенче гасырда чәчәк аткан ханлык була бу. Уникенче гасырда алар таркала башлый. Кыпчаклар шулар эченнән чыккан. Кимакларның бөтен элитасы, ханнары – татар кабиләләреннән, ягъни аларны берникадәр дәрәҗәдә татар дип карарга була. Болар соңрак Урта Азиядәге Хәрәзем дәүләтендә бик әһәмиятле вазифа башкарып, монголлар килгән вакытта бик җитди урыннарны биләгән. Монголлар кергән вакытта аларның бер зур төркеме Һиндстанга качып, Дәһли солтанлыгына нигез салып, шунда мөселман булып яшәп яткан. Алар исламны XI гасырда ук кабул иткән була. Болар – мәҗүси кыпчаклар түгел, Көнчыгыш кыпчаклары. Шуларның кайберләре хәтта төрекләр яшәгән урыннарга да күчеп китә.

– Татарстандагы авыл исемнәрен игътибар белән карап чыксаң да, борынгы татар кабиләләренең исемнәре ярылып ята түгелме соң?

– Чынлап та шулай. Әйе, үзең туып үскән Мөслим районындагы Тамьян, Табын, Кубәк, Мухан, Чакмак авылларының исемнәре борынгы чорларга барып тоташа икән дип

«Олуг Мөхәммәд хан». Р.Вахитов рәсеме

дөрес чамалыйсың. Әйтик, Тамьян атамасының Кырымдагы Тамань дигән ярымутрау варианты да бар бит әле. Берничә урында Төмән дигән исем дә очрый. Алар барысы да – чынбарлыкта кабилә исемнәре. Шибан Болгар вилаятен яулап алуда катнашкан. Аннан соң аның урыс җирләрен, Кырымны алуда да катнашы бар. Шунда Шибанның кул астында кырык меңлек гаскәр булуы күренә. Бер гаскәр башлыгының исеме Төмән-Таман вариантында телгә алына. Шуның кул астындагы ун мең кешелек тагы бер төркем боркыт төркеме дип атала. Боркытлар хәзерге Төньяк Башкортстанда, Пермь якларында күренә. Хәтта Гәйнә башкортлары дигән төркемнең кенәзләре, биләре – боркыт кабиләсеннән чыккан шәхесләр. Алар беркайчан да үзләрен башкорт дип йөртмәгән, татар дигән исемнәрен саклаган. Әйтик, Кама буендагы Куян, Култай дигән авыллар шуларга бәйле. Минә драматург Риза Ишморат Төньяк Башкортстаннан. Бөре тирәсеннән. Аның шәҗәрәсендә дә Боркыт исеме бар. Сезнең яктагы Табын, Тамьян, Күбәк дигән атамалар минә шушы Себер Шибаниларына бәйле. Бездә топонимнарны чынбарлыкта системалы рәвештә өйрәнгән галимнәр юк әле. Дөрес, Фирдәвес Гарипова бераз өйрәнде, тик анализлауга барып җитмәде.

Урыс гербында ике башлы каракош, бөркет бар, аны урыслар ике башлы «орел» дип йөртә. Ул билге – бөркет чынлыкта борынгыдан килә. Татар чыганаклары буенча ул – Чыңгыз

ханның шәхси кошы, тотемы, тамгасы. Әлеге билге Алтын Урда акчаларында да бар. Җанибәк хан вакытында аеруча күп таралган, Үзбәк хан вакытында да очрый. Әйе, һәрбер монгол, төрки кабиләсенең үз кошы булган. Шул кошлардан әкренләп герб барлыкка килгән, акчага суккач, инде дәүләт символына әйләнгән. Ул «Идегәй» эпосында да бер җирдә күренеп китә. Анда «дәүләт кошы» дигән бер гыйбарә бар. Шуларны өйрәгән вакытта урыс тарихының татар тарихына бәйле икәне дә күренә. Ул билге урыс акчасына тиктомалдан гына кермәгән. Әйтергә теләгәнем шул: тарихны өйрәнгәндә этнология мәгълүматларын да кертсәң, бик кызыклы нәтиҗәләр ясарга мөмкинсең. Инде «Тарихи этнология буенча мәкаләләр» дигән хезмәтнең икенче томына да язмалар җыйдым. Икенче том татар ханлыклары чорына багышлана. Анда бик кызыклы нәрсәләр бар. Шәҗәрәләрне ныклап өйрәнгән вакытта Кырым, Касыйм, Казан ханлыгында Олуг Мөхәммәд ханга бәйле берүк кабиләләр хакимлек иткәнлеге күренә. Болар –Ширин, Барын, Аргын, Кыпчак кабиләләре. Безнең Казанда Караваево дигән урын бар. Аның татарча исеме йә Карабай, йә Караби. Ул – менә шушы Аргыннар кабиләсенә бәйле шәхес. Кырым татарлары арасындагы аргын кабиләсендә дә бу исем бар, ягъни алар монда Олуг Мөхәммәд белән килеп утырган, дәүләтне үз кулларына алган.

– Сезнең башлангыч белән Казаныбызда бер фәлсәфи семинар димме, түгәрәкме эшләп килә. Укучыларыбызга шул хакта да мәгълүмат биреп китсәк, яхшы булыр иде.

– Хәтта сиксәненче елларда да академик институтларда дискуссияләр була иде. Хәзер фикер тартышлары бетте. Моның сәбәпләре күптөрле.

Милли университет, Ислам академиясе оештыру зарурлыгы... без шактый проблеманы тикшердек. Бездә булган проблемалар шунда ук күренде, чөнки төрле-төрле өлкәдә эшләүчеләр фикерен белдергәч, мәсьәлә төрле яктан күренә. Гел йөрмәсәләр дә, анда Рафаил Хәкимов, Рәфыйк Мөхәммәтшин кебек кешеләрнең дә катнашканы бар. Шушы фикер алышулар барышында татарны гомуми үстерү программасын эшләү зарурлыгы барлыгы күренде дә инде. Мин шуннан куркам: бу мәсьәләне интернетта тикшерү кирәкмәгән ыгы-зыгы, радикализм китереп чыгарырга мөмкин. Башка милләтләрне сүгә башларга омтылучылар булыр. Бүтән милләтләрне түгел, үзебезне кайгырырга кирәк. Вазгыять катлаулы булса да, аны чишүнең төрле-төрле юллары бар. Мин, мәсәлән, урысларны сүгүнең бер мәгънәсе дә юк, дип уйлыйм. Урыс милләтчеләренең дә хәле җиңел түгел: аларның үз проблемалары бихисап. Минем белән сөйләшкәннәре, безгә Россия милләте дигән фикер-ниятне байрак итеп күтәрүнең кирәге юк, бездән тагын совет милләте ясамасыннар, дип белдерде. Аларның урыс булып каласы килә. Дөрес бу: алар – урыс, без татар булып калыйк. Беренчедән, бу дискуссия интеллектуаллар катнашында барырга тиеш. Икенчедән, тел белән тегермән тартмаска, буш сүз сөйләмәскә кирәк. Бәлкем, безгә бу таррак даирәдән чыгып, бәхәс клубы оештырырга кирәктер. Мин аның исемен дә таптым. Аны «Ирек мәйданы» дип атарга мөмкин. Журналистлар, язучылар, галимнәр өчен җыелышып фикер алыша торган бер мәйданчык оешса, яхшы булыр иде.

Әңгәмәдәш – ***Рәшит Минһаҗ***

Редакциядән: Күренекле җәмәгать эшлеклесе, тарих фәннәре докторы, этнолог, политолог **Дамир ИСХАКОВ** быел 65 яшьлеген билгеләп үтте. Без аны гомер бәйрәме белән котлап, сәламәтлек, иминлек һәм уңышлар теләп калабыз! ■

ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ

Габдерәшит Ибраһимов



«Большая Сибирская» кунакханәсе. Уфа. 1907-1912 еллар

УФА

30 сентябрь көнне, нәкъ кичке азан әйтелгәндә, без Уфага килеп җиттек. «Большая Сибирская» кунакханәсенә барып урнаштым. Кичен, төнгә каршы бераз шәһәрдә йөрдем. Бөтен җир, көндез диярсең, электр утлары белән яктыртылган иде. Уфа инде мин белгән шәһәр түгел, 14 ел эчендә бөтенләй башка бер мәмләкәт хәленә килгән. Эзләп табып, төнне дә шунда үткәрү теләге белән, Әбүссөгуд Әхтәмов әфәнденең өенә бардым.

Әбүссөгуд әфәнде – элекке Дума әгъзасы, заманында милләт өчен хезмәт иткән кеше. Русия мөселманнарын алсак, голәмә балалары арасында иң беренче булып рус университетын ул бетерде.

Уфа шәһәре Русиянең эчке төбәкләрендә яшәгән татарларның дини үзәге булып тора. Биш миллионнан артык мөселман кешесенең дини эшләрен идарә итү өчен оештырылган Шәригать мәхкәмәсе, ягъни рухани идарә (духовное управление) биредә урнашкан.

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

Безнең мирас №8 август 2017

РУСИЯДӘ МӨСЕЛМАН РУХАНИ ИДАРӘЛӘРЕ

Бөтен Русиядә – Төркестан һәм Казахстанны санамыйча – дүрт шәригать мәхкәмәсе бар. Боларның берсе һәм иң зуры – Оренбург рухани идарәсе, аның үзәге Уфада урнашкан.

Икенчесе – Кырым рухани идарәсе, идарә үзәге Акмәчет (Симферополь) шәһәрендә.

Өченчесе – Мавәрә-и Кавказ мөфтилеге, идарә үзәге Тифлистә (Тбилисидә).

Дүртенчесе – Мавәрә-и Кавказ шәйхелисламлыгы, идарә үзәге шулай ук Тифлистә урнашкан. Бу соңгысы – шигый мәзһәбендәге мөселманнар өчен оештырылган Шәригать мәхкәмәсе (рухани идарәсе), алдарак күрсәтелгән өчесе исә, әһл-е сөннәткә, ягъни Мөхәммәт пәйгамбәрнең (с.г.в.) сүзләренә һәм эш-хәрәкәтләренә тугрылыклы калучыларга аталган. Менә шулай итеп мин бу юлы Оренбург шәригать мәхкәмәсенең үзәге булган Уфа шәһәренә килдем.

МӘКТӘПЛӘР, МӘДРӘСӘЛӘР, СӘҮДӘ

Мин бу шәһәргә соңгы мәртәбә 1891 елда килгән идем. Ул килгәнемдә шактый озак калдым, ике ел яшәдем. Ул вакытларда голәмә дип атарлык кешеләр – казыйлардан кала бары тик ахун Хайрулла әфәнде генә, ә мәдрәсә дип атарлык, шул ук ахунның тырышлыгы белән салынган, 20-30 шәкерт укый торган кечкенә генә бер мәдрәсә бар иде. Мөселманнар арасында сәүдәгәр дип атарлык бер-ике кеше табарга мөмкин булса да, аларының да үз йортлары, кибетләре юк иде. Кечкенә генә бер мәчет булганын да әйтеп үтәргә кирәк.

Иртән иртүк тордым, атлы арбачы яллап, мәктәп һәм мәдрәсәләрне карап йөреп чыктым. Мәчетләрнең дә барысына да бардым, күрдем. Мәчетләрнең дә, мәдрәсәләрнең дә биналары бик матур, төзек иде. Мәчетләр электр белән яктыртыла, ә ике манаралы мәчет шәһәрнең нәкъ уртасында, иң караулы җирдә урнашкан.

Мәдрәсәләрнең һәрберендә 300-400ләп шәкерт укый икән. Тик мин булган көннәрдә әлегә уку елы башланмаган, шәкертләр әле җыелалар гына иде.

Мөгаллим һәм мөдәррисләрнең (укытучы-галим һәм дәрес бирүче укытучыларның) кайберләре белән күрешеп сөйләштем. Мәктәп программалары һәм укытылачак фәннәр турында да сораштым, исемлекләрен дә карадым: гарәп теле, дин дәресләре, тәфсир, хәдис, дини фәлсәфәдән тыш, хисап, алгебра, гомуми тарих, табигать белеме, география, геометрия, табигый фәлсәфә, химия, икътисад дәресләре дә укытыла һәм гаять көчле мөгаллимнәре дә бар. Уфада яшәгән көннәремдә мөгаллимнәрнең күпчелеге белән күрешеп сөйләшә алдым.

Иң мактауга һәм хуплауга лаек яклары – бу мәктәп һәм мәдрәсәләрнең идарә ителү рәвеше. Чөнки алар бары тик хәерхаһлылык ияләренең рәхимлелеге белән идарә ителә, берничә кеше бу кадәр зур чыгымны үз өстенә ала, бары Аллаһ сүзенең, Исламиятнең бөеклеген һәм хакыйкатьләренең кыйммәтен белдерү, җәелдерү нияте белән, вөҗданнары кушканга гына янчыкларын ача икән – мактамыйча мөмкинме соң?! Бу затлар, иманнарының бурычы санап, Аллаһ ризасы өчен, һәр ел меңнәрчә сум акча сарыф итүне үз өсләренә алганнар.

Мин кич җиткәнче шулай йөрдем, кайбер дус-ишемнең барып хәлләрен дә белдем: Мәдрәсә-и галиянең назыры (мәдрәсә эшләрен күзәтеп, тикшереп торучы) Сәлимгәрәй Җантурин, Кызлар мәктәпләренең мөдирәсе Суфия ханым, өченче мәчетнең *(«Хәсәния» мәчете турында сүз бара. –* **Ред.***)* ахуны һәм мөдәррисе Сабир Хөсни әфәнде җәнаплары һәм хөрмәтле сәүдәгәр Садретдин Нәзири һ.б. күп кенә кеше белән күрешеп, сөйләшеп, кайбер мәгълүматлар алдым. Кич җиткәч кунакханәгә кайттым, газеталар укып вакыт үткәрдем.

Иртәгесе көн иртәннән тагын йөрергә чыктым. Уфа шәһәре бүгенге көндә мөселман шәһәре дип аталырга

Безнең мирас №8 август 2017



Оренбург рухани идарәсе бинасы. Уфа. 1907-1910 еллар

лаеклы: зур һәм төзек бина күрсәгез – хуҗасы мөселман кешесе булыр, зур кибетләрнең дә хуҗалары мөселманнар. Уфа базары да мөселман базарына әйләнгән. Зур мәдрәсәләрдән башка шактый санда башлангыч мәктәп тә бар икән, ике зур кызлар мәдрәсәсе эшли. Зур сәнгать уку йорты да бар. Кыскасы, Уфа шәһәре бу соңгы елларда ай түгел, көн үткән саен үзгәрә, алга бара.

Шунысын кабатлап әйтергә кирәк: ул мәктәп һәм мәдрәсәләрнең һәммәсе дә, мөселманнарның бары тик үз тырышлыклары, үз көчләре белән салынып кына калмый, идарә эшләре дә хәерхаһлы, иманлы кешеләр тарафыннан тәэмин ителә.

Уфа шәһәрендәге мөселманнарның саны турында төгәл генә мәгълүматыбыз булмаса да, бөтен Уфа губернасында 1300000 мөселман яшәгәнлеге билгеле.

Уфа губернасына бәйле төбәкләрдә, авылларда да бик күп санда мәктәп һәм мәдрәсә бар. Араларында 200-300 шәкерткә белем бирә торган авыл мәдрәсәләре дә аз түгел.

Мин бу юлы Уфада өч көн калдым һәм бу вакыт эчендә бик күп нәрсә күрдем. Эчемнән уйланганда: «Бу безнең Русия мөселманнарының киләчәгендә бердәнбер идарә үзәге һәм таянычы», – дип әйтәсем килде хәтта. Әгәр биредәге мөселманнарның бу гайрәтләренә, бу тырышлыкларына, бу ислами хәерхаһлыкларына бөтен Русия мөселманнарының идарә үзәге булган Шәригать мәхкәмәсе (рухани идарәсе) дә ярдәм итсә иде, һичшиксез Уфаның киләчәге тагын да якты һәм тагын да өметле булыр иде, ләкин кызганыч ки, бу идарә тере мәет кебек торуын дәвам итә.

ОРЕНБУРГ РУХАНИ ИДАРӘСЕ

Оренбург рухани идарәсе турында да бераз мәгълүмат бирергә телим. Бу идарә, югарыда да әйтеп үтелгәнчә, биш миллионнан артык мөселманның дини идарә үзәге булып тора. Шулай булгач, моның әһәмияте дә шул ук нисбәттә зур булырга тиешлеген икеләнмичә әйтә алабыз. Бу идарә турында биреләчәк мәгълүмат та – шул биш миллион мөселман халкының рухи яшәешенә караган мәгълүмат дигән сүз.

Мөселманнарның Оренбург рухани

идарәсе 1787 елда Екатерина II патшалык иткән чорда оештырылган. Аның оештыручысы да бу әби патша була, чөнки Екатерина II, сәяси максатына тугры калып, Кырымны алганнан соң, кулын Истанбулга сузарга тели. Шул сәбәпле ил эчендәге иминлекне тәэмин итәр өчен бердәнбер юл – Русия мөселманнарын тыныч тотарлык һәм канәгать итәрлек бер чара уйлап табу була. Менә шундый зәгыйфь һәм алдауга корылган фикергә нигезләнгән оешма булса да, нәтиҗәдә бу идарә Исламияткә шактый хезмәт иткән.

Баштагы чорда бу идарәгә бирелгән хокук никадәр генә аз булса да, ул, мөселманнар өчен барып башларын куярлык, сүзләре сыярлык урын булып тора, бераздан җыеп торучы көч хәленә килә һәм үзәк рәвешен ала.

Ханлыклар бер-бер артлы җимерелеп, ханнар юкка чыга бару белән бөтенләй яклаучысыз калган һәм бүдәнә чебешләре кебек як-якка сибелешкән мөселманнар, диннәрен саклауны үз өстенә алучы идарә оешканын күреп, аңа барып сыенганнар. Бу идарәнең кул астына татарлар гына түгел, казахлар да кергән.

Идарәнең рәисе һәм әгъзалары хөкүмәт тарафыннан билгеләнә, аларга бик аз гына түләү дә каралган була. Билгеле булганча, Екатеринаны бу чараның бары тик бер ягы гына кызыксындыра: ул, аз-маз күз буяп, мөселманнарның фикеренә йогынты ясарга һәм эчке тынычлыкны тәэмин итәргә тели.

Шулай булуга да карамастан, калебләре нык һәм рухлары белән нурлы шәригатькә бәйле мөселманнар, идарәнең ачылышыннан соң, араларында нинди генә мәсьәлә чыкса да, шунда ук бу идарәгә мөрәҗәгать итә башлаганнар. Хөкүмәт әгәр берәр нәрсә тәкъдим итсә, кушса, мөселманнар, бу идарәдән фәтва[1] алмыйча торып, аны кабул итмәгәннәр, күнмәгәннәр.

Ул заманнарда юллар юк, пароходлар юк. Шулай булса да, бик ерак җирләрдә яшәүче мөселманнар да, бер җөмлә белән язылган фәтва алыр өчен, айлар буе юл йөреп, бирегә килә торган булганнар. Бу рухани идарә биргән фәтваларны мөселманнар югары фәрман дәрәҗәсендә кабул иткәннәр. Татарлар, сәүдә эшләре буенча төрле якларга таралсалар да, бу идарәгә дини бәйлелекләрен һәрвакыт саклаганнар. Шул рәвешле, бу кечкенә генә идарә тора-бара һич уйланылмаган рухани көчкә, министрлык дип аталырлык оешмага әверелгән.

Ләкин, бик кызганыч, бу рухани оешмада, аның йөздән артык елга сузылган эшчәнлегендә, мөселманнар мәнфәгате өчен чын-чынлап хезмәт итәрлек кеше булмаган.

Идарә җитәкчелеге шура (совет) рәвешендә булган: бер рәис белән өч әгъзадан торган. Аларны сайлап кую кайчандыр Оренбург һәм Казан мөселманнарына тапшырылган булса да, ни Оренбург мөселманнары идарә рәисен, ягъни мөфтине, ни Казан мөселманнары идарә әгъзаларын, ягъни казыйларны сайлап куя алмаганнар.

Шулай итеп, бу идарә ярты үле, ярты тере хәлдә дип әйтерлек эш йөртергә мәҗбүр калган, кәлимә-и тәүхидне[2] суза-суза бүгенгә кадәр килгән. Русларның җаһиллеге дә бу хәлнең шулай үзгәрешсез калуына ярдәм иткән. Мөселманнарның рухи көче исә гаҗәеп дәрәҗәдә арта гына барган. Моннан соң инде Русия мөселманнарының үзеге кайда дигән сорау куелса, җавап бер булачак – биредә, Оренбург рухани идарәсендә.

Моннан алтмыш еллар элек бөтен дала казахлары һәммәсе дә бу идарәгә бәйле булганнар. Ул вакытларда Оренбург рухани идарәсе карамагында 12000000нан артык мөселман исәпләнгән. «Үзе бер зур дәүләт булган»

---

[1] Фәтва – билгеле бер вакыйга яки мәсьәләләргә карата мөфти тарафыннан шәригатькә нигезләнеп бирелгән җавап, карар.

[2] Кәлимә-и тәүхид – «Лә иләһы илә Аллаһ, Мөхәммәдүн рәсулуллаһ» дигән изге җөмлә.

дип әйтсәм дә, дөреслеккә туры килер. Тик ни булса да булган, бер яктан, идарә рәисе һәм әгъзаларының үз вазыйфаларын тиешенчә башкармаулары, икенче яктан, казахларның җаһиллеге тәэсир иткән һәм хөкүмәтнең боларга таянган хәйләсе, харәмләшүе дә өстәлгән: 1864 елда 7000000 казахны сүгеп, янап, гаепләп куркытканнар, гүя болар мөселман түгел, шәригать кануннары белән яшәмиләр, борынгы гадәтләр һәм дәүләт кануннары буенча яшиләр, дигән сылтаулар тапканнар, Ислам кануннарына котырган эт кебек ташланганнар, соңгы чиктә бичара казахларны бу идарә карамагыннан аерып алуга ирешкәннәр.

Инде хәзер хөкүмәтнең максаты – бу идарәне ябып, мөселманнарның бөтенләй ояларын туздыру. Илле елдан бирле бөтен хөкүмәтләр һәм аларның сәясәтчеләре шушы юлдан баралар. Нәкъ кырык ел буе, хөкүмәт төркичә укый-яза да белмәгән кешеләрне мәҗбүри бу Рухани идарәгә рәис итеп билгели. Хәзерге идарәнең рәисе, мөфти Мөхәммәдъяр Солтанов – хөкүмәт фикерләрен яклаучы кеше, диннең, шәригатьнең ни икәнен дә белми, төркичә уку-язудан мәхрүм, ләкин Рухани идарә рәисе – мөфти, инде егерме биш ел мөфти булып тора.

Мин үзем бу идарәгә сайланып, берара әгъза булып тордым, Солтанов югында сигез айга якын рәислек вазыйфасын да башкардым. Хөкүмәтнең бу идарә белән бәйле бөтен яшерен уеннарын аңлаганнан соң, үз теләгем белән вазыйфадан баш тартып, Истанбулга киттем һәм бу идарә, Русия мөселманнарының киләчәге турында «Чулпан йолдызы» исемле әсәремне язып тәмамладым. Яшерен рәвештә, нәшриятлар күзәтү астында тотылып, көн дә басу, талаулар булып торган болгавыр заманда, ярдәм кулын сузган изге бәндәләр булышлыгы белән бу әсәрне бер төндә Махмуд Бәй матбагасында китап итеп бастырганнан соң Одессага китердем һәм шуннан бөтен Русия мөселманнары арасында тараттым.

Менә шул «Чулпан йолдызы»нда Оренбург рухани идарәсе турында мәгълүмат шактый күп, шуңа күрә биредә ул хакта артык тәфсилләп тормыйм.

Тик шуны кабатлап әйтергә телим: Русия мөселманнарының киләчәген тәэмин итәр өчен Оренбург рухани идарәсе бик төпле, нигезле яңартуга мохтаҗ. Бу үтә кирәкле яңартуны башкарыр өчен милли рухта тәрбияләнгән, киң мәгълүматка ия һәм иҗтимагый фикердән хәбәрдар күркәм шәхесләр кирәк булган кебек үк, милләтнең дә тырышлыгы кирәк.

Мин бу юлы Уфада булган вакытта, егерме ел буе Оренбург рухани идарәсендә әгъза булып торган Гинаятулла казый белән дә как-кат күрешеп сөйләштем: хөкүмәт бу идарә хакында күптәнге һәм мәгълүм фикерләрен һәрвакыт көн тәртибендә тота икән. Хөкүмәт, әлбәттә, үз мәнфәгатен күзләр, ләкин милләт тә үзенең шәригать кушкан хокукларын саклап калу өчен ваемсыз булмаска тиеш.

МИРЗАЛАР

Биредә мирзалар ике төрле: беренчесе – рус мәктәпләренең югары сыйныфларында, күбесе исә хәрби мәктәпләрдә белем алган, берара зур урыннарда эшләгән, шул рәвешле Уфа, Вятка губерналарында үзләренә шактый гына күчемсез мөлкәт булдырган кешеләр. Болар арасында иң танылганнары – Тәвкилизадәләр. Бу нәселнең шөһрәте бүгенгә көнгә кадәр килгән, Тәфкилевләр дип аталып йөртеләләр. Тәвкилизадәләр, Чукмалдин язганча, Себердә хөкемдарлык иткән Күчүм хан нәселеннән килә икән, Ярмак талауларыннан качып, Урал башкортлары арасына килеп сыенганнар.

Бу нәселдән бүгенге көндә бары тик бер генә кеше исән дип әйтергә мөмкин, исеме – Котлыгмөхәммәт Мирза Тәфкилев. Хәзерге вакытта Петербургта Дума әгъзасы булып тора. Мин бу шәхес белән күп тапкырлар күрешеп сөйләштем: гаять яхшы кеше. Ләкин шуның белән бергә, бабаларының дан-

шөһрәте турында берни белми, мал-мөлкәтен дә югалткан, затлы урынын да саклый алмаган. Энесе исә, бер рус кызына гыйшык тотып, хәтта динен дә алыштырган.

Тәфкилевләр моннан утыз еллап элек Русиянең иң дәрәҗәле затлы нәселе булып саналганнар, бары тик мөселманнар арасында гына түгел, руслар арасында да, хәтта хөкүмәт каршысында да бик зур урыннары булган. Котлыгмөхәммәт Мирзаның атасы Батыргәрәй һәм аның энесе Сәлимгәрәй бик танылган, дан-шөһрәткә ия шәхесләр булганнар, Алтын Урда ханы Җиһангир хан җәнаплары нәселе белән никях аша туганлыклары да булган.

Болардан башка Уфада кайбер кантон[3] уллары мирзалар да бар. Болар да югары уку йортларында укыганнар. Тәфкилевләрнең кияүләре – Җиһангир хан нәселен дә әйтеп үтәргә кирәк. Уфа мөселманнары арасындагы югары уку йорты бетергән кешеләр бар да шушы төркемнәргә карый.

Мирзаларның икенче төре – Каргалы мирзалары дип аталып йөртелгән кешеләр. Боларның барысы да соңгы елларга кадәр рус башлангыч яки урта мәктәбен бетереп, ягъни бары тик русча укый-яза белүләре белән генә мирза булганнар. 10 сум, иң күбе 20 сум хезмәт хакына канәгать булып хөкүмәт эшләрендә эшлиләр, мирзалыклары белән бик горурланалар икән. Тик бу соңгы биш ел эчендә алар арасында да югары уку йортлары бетергән кешеләр күренгәли башлаган.

СӘҮДӘ

Моннан 15 еллап элек Уфа шәһәрендә руслар арасында да, мөселманнар арасында да зур сәүдәгәрләр булмаган. Затлы нәселле кешеләр арасында күчемсез мөлкәт һәм байлыкка ия шәхесләр булса да, алар сәүдә белән шөгыльләнмәгәннәр. Шәһәрнең күп кенә урамнары баткаклыкка әйләнеп, яз-көз бер өйдән икенчесенә барып кайту, күршеләргә кереп чыгу бик кыенлаша торган булган.

Моннан егерме ел элек сузылган Себер тимер юлы бу җирләрдән дә үтте. Моңа бәйле рәвештә сәүдә эше киңәйде. Бүген Уфа Русиянең иң төзек шәһәрләренең берсе булып санала. Уфада сәүдә эше шулкадәр киңәйгән ки, мөселманнар арасында да миллионнар белән эш итүче кешеләр бар. Чит илләр белән хезмәттәшлек алып баручылар да бик күп. Шәһәр халкының күпчелеген руслар тәшкил итсә дә, сәүдә өлкәсендә мөселманнарның тоткан урыны зур, киләчәкләре дә якты булыр кебек күренә. Уфа губернасында ашлыктан мул уңыш алына. Ашлык белән сәүдә итү бик алга киткән, төзелеш өчен агач җитештереп сату да аннан калышмый. Хайван җитештерү дә игътибарга лаек: бүгенге көндә хөкүмәт атлы гаскәр өчен Уфа губернасыннан җитди микъдарда хайван сатып ала. Себер якларына хас май, бал да күп табыш китерә. Уфа балы бөтен Русиядә танылган, ул бик хуш исле була.

Уфа губернасыннан читкә күп микъдарда мал чыгарылганга, әйбер төяп ташу чаралары, тимер юллар, елга юлы, таш юллар да шактый төзекләндерелгән, җайга салынган, шулай булгач, сәүдә эше алдагы көннәрдә тагын да киңәячәк. Урал тауларындагы файдалы казылмалар да эшкәртелә башласа, һичшиксез, берничә йөз миллионга ия кешеләр дә барлыкка киләчәк.

Шул рәвешле, Уфада өч көн торганнан соң, мин, әзерләнеп, зур Себер юлының башы булган Чиләбе шәһәренә барырга чыктым. Уфа белән Чиләбе арасы – 400 километрлык юл.

Төрекчәдән
***Асия Рәхимова** тәрҗемәсе.* ■

---

[3] Кантон – Уфа, Пермь, Оренбург губерналарында яшәгән башкортлар, моннан илле еллар элек үзенә бертөрле мохтарият (автономия) һәм имтияз (танылган өстенлек) белән идарә ителәләр иде. Ул вакытларда аларның рәисләре кантон дип атала иделәр. Шул кантоннарның уллары булган мирзалар кайбер төбәкләрдә хәзер дә бар, ләкин инде әһәмиятләре генә калмаган. *(Габдерәшит Ибраһимов искәрмәсе.)*

Безнең мирас №8 август 2017

Татар дин галимнәре Корбан турында

КОРБАН ЧАЛУ

Галимҗан БАРУДИ

Әсирлектә дә корбан чалганнар. Германиянең Вюнсдорф лагере. 1916 ел

Корбан чалу – ислам диненең шигарләреннән һәм олуг билгеләреннәндер. Имам Әбү Хәнифә һәм башка байтак галимнәр фикере буенча, бу гамәл – ваҗиб. Шулай ук, сөннәт дип әйтүче галимнәр дә күптер. Мәҗбүри диелсә дә, сөннәт диелсә дә, пәйгамбәребез, аңа Аллаһының сәламе вә салаваты булсын, бер дә калдырмыйча үтәгән, үзе өчен һәм өммәтендәге көче җитмәгән кешеләр өчен үз кулы белән чалган.

Бәс, көче җиткән, исламга ышанган кеше каршында корбан чалу – тиеш гамәлдер. Әгъзалары сәламәт, симез хайванны үз кулы белән яхшы итеп чалу тиеш. Әгәр үзе яхшы чала алмаса, булдыра алган кешене вәкил итеп, үзе аның янында Аллаһыга ялварып, кабул булуын теләп торырга тиеш.

КОРБАННЫҢ АСЫЛЫ

Корбан чалу – Ибраһим галәйһиссәламнән калган сөннәт. Башта, Аллаһының боерыгы сәбәпле, углы Исмәгыйльне чалмакчы булган, углы да разый булган: «Аллаһы боерган эшне кыл, мин түзәрмен», – дигән.

Ибраһим галәйһиссәлам углын чалмак булганда, аның вә углының Аллаһы хөкеменә вә боерыгына тулысынча буйсынулары ачыклангач, Аллаһы аларны бу сынаудан коткарган вә олуг хикмәт өчен, аның углына фида итеп, бер шәрәфәтле кучкар җибәргән, углы урынына шуны чалырга боерган һәм шуның белән риза булачагын белдергән. Ибраһим галәйһиссәлам, Аллаһы ризалыгын теләп, углы урынына шул куйны чалган.

Әгәр Ибраһим галәйһиссәлам, Аллаһы ризалыгын эстәп, сөекле улын корбан иткән булса, бәлки, бөтен диннәр әһелләренә (Ибраһим милләтеннән булган кешегә) улларны корбан итү тиеш булып калыр иде. Аллаһының бөтен кешелеккә мәрхәмәтедер ки, кеше урынына, Аллаһыга якынаю, үзен фида кылу (йолу) максаты белән бер хайван чалып, Аллаһы ризалыгы өчен садака һәм ярдәм итсә, шул җитә торган булган.

Бәндә бик шөкер кылсын, Аллаһы Тәгалә инсан баласын корбан итүне тиеш вә мәҗбүри итмәгән, үзенең ризалыгын шуңа бәйләмәгән, ә бер хайван җитә, дип күргән. Шуңа бу шәригатькә куана-куана, бер хайванны корбан итеп, фәкыйрьләрне файдаландыру, шуның белән Аллаһыга шөкер итү вә якынаю тиештер. Кеше дә сәламәт, фәкыйрьләргә дә ярдәм, гаиләгә дә иркенлек!

ХОЛАСА

Корбан чалуда Ибраһим галәйһиссәлам вакыйгасын искә төшерүдә – кешене корбан итүдән котылып, хайван корбаны белән чикләнү, аның (аз гына нәрсә) белән күп әҗер-савапка ирешү, шул ук вакытта фәкыйрьләргә ярдәм, гаилә әһелләренә иркенлек кебек байтак хикмәтләр табыладыр.

Хәдис китапларында киләдер ки, рәсулуллаһ, аңа Аллаһының сәламе вә салаваты булсын, гает намазын үтәгәч, хөтбәне тәмам кылу белән, шунда ук, печелгән мөгезле ике кучкарны Аллаһыга мөнәҗәт итеп, «Мөхәммәдтән һәм корбан чалмаган өммәтемнән кабул ит, бисмиллаһи Аллаһу әкбәр», дип, үз кулы белән чалган. Имам Әбү Дауд риваятенә күрә, пәйгамбәребез ошбу рәвештә мөнәҗәт кылган: «Күкләрне вә җирне барлыкка китерүче бер Аллаһыга гыйбадәт кылучы буларак, йөземне юнәлттем һәм потка табынучылардан булмадым. Минем намазым да, корбаным да, тормышым да, үлемем дә – галәмнәр Раббысы булган Аллаһы Тәгалә өчен. Миңа шулай әмер ителде һәм мин – иң беренче буйсынучылардан. Йә Аллаһы, бу Синнән һәм Сиңа!» Ошбу рәвешле мөнәҗәт кылгач, куйны чалган.

Рәсулуллаһның корбан чалуын аңлатканда ике рәкәгать намаз укуы турында берни дә күчерелми вә ышанычлы фикыһ вә фәтва китапларында күренми. Халыкның «Иман шарты» китабы өйрәткәнчә, корбан чалгач, бер сүз дә сөйләшми, тизрәк ике рәкәгать намаз укулары нигезле эш булырга охшамый. Ул намазны гавам халкы ваҗиб дәрәҗәсендә күреп килгән: «Ул намазны укымаганда ярармы, корбан кабул булырмы?» – дип сораучылар күп булды. Бу бидгать дип фаразлана, халык арасына кергән, шуңа имамнарның бу мәсьәләгә игътибар итүләре бик тиеш.

Минем үз уемча, Кадер кичәсе, Рәгаиб кичәсе намазлары кебек, Китап һәм сөннәттә нигезе булмаган, кылуы тиешле булмаган, гавам халкының гоманлары (дәлилгә нигезләнмәгән уйлары) бөтенләй корбан өчен шарт кебек күрү булганга, бу хата гоманнан кайтару өчен аларны бу намаздан тыю тиеш булса кирәк.

«Дин вә әдәп» – 1907. – №13.

Безнең мирас №8 август 2017

МӨБАРӘКБАД!

Һади Максуди

Гает сәгыйд корбанның җитүе илә «Йолдыз» җәмигъ әһле исламны, хосусан үзенең кариларын тәбрик итәдер.

Җәнаб Хак һәр каюмызга дәхи бик күп сәнәләрнең мөбарәк бәйрәмнәрен бәрабәр күрүне, шатлык вә сәгадәт илә кичерүне насыйп әйләсен.

Бүген бөтен дөньяда өч йөз миллион микъдарында булган мөселманнарның барчасы өчен уртак булган бәйрәмнең асылы – шатланудадыр.

Бүген һәр мөселман ханәсендә гомуми шатлыктыр. Һәр ханәдә корбан тәгамнәре әзерләнмештер. Бай, фәкыйр – барчасы туктыр.

Барча мөселманнарга гомуми бәйрәм тәгамы булу өчен әзерләнгән корбан өлеше һәр ханәгә ирешмештер. Ирешмәсә, дәүләтле кешеләрнең фәкыйрьләргә карата золымыдыр.

Мәгәр Русиядә ачлык хөкем сөргән өлкәләрнең фәкыйр мөселманнары бу гомуми шатлыктан мәхрүмнәр. Бәлки бичараларның ашарлык икмәкләре дә җитәрлек микъдарда түгел.

Аһ, бу гомуми бәлагә каршы ни чара кылмак кирәк? Бу хәл хәтергә килгәндә, шатлыкны гомуми дию мөмкин түгелдер. Бу хәл гомуми борчылуга сәбәп булырга тиеш. Коры борчылуда файда юк. Бу борчылу хәер вә ихсанга сәбәп булырга тиешледер.

Ничара ки, бәйрәм шатлыгы арасында бу ач вә ялангач бичараларның кызганыч хәлләрен хәтергә китерүче булмас. Булса да, үзенең нигъмәт вә дәүләте шөкранәсе өчен, бу бичараларга ярдәм өчен булмас.

Хәлбуки, һиммәт кылучы булса, бу бик җиңел бер эштер. Ачлык булган тарафларның һәрберсендә ачларга ярдәм өчен ачылган комитетлар бар.

Казанда ач мөселманнарга ярдәм өчен тәэсис кылынмыш бер комитет бардыр. Бу комитетның әгъзалары барчасы гадел мөселманнардыр. Моңа бирелмеш акчаларның һәрбер тиене тиешле урынына сарыф кылыначагына шөбһә юктыр.

Инсаф итәргә, мөселманнар. Үзебезнең бәйрәм исрафларыбызга сарыф ителәчәк акчаларыбызны кысып, бу бичараларга ярдәм итәргә.

Корбаннарыбызның кимендә өчтән бер өлешен ачлар өчен бер җиргә җыеп, бик ач авылларга юллыйк.

Бер айдан бирле комлы, тузанлы кара икмәк белән судан башка тәгам күрмәгән ачлар, һич булмаса, бер мәртәбә ит вә шулпа күрсеннәр.

Хәзер дә кышның иң суык вакытларыдыр. Итләрнең бозылу ихтималы юктыр.

Бәлки шәт ачларга ярдәм комитеты бу хосуста бер һиммәт кылыр. Казанда кырык мең мөселман бардыр. Аз булганда ун мең пот корбан ите була торгандыр. Бу корбаннардан ике мең пот кадәр ит ачлар файдасына җыелса, йөз мең кадәр ачларның бер көн тамаклары тук булыр иде.

Әгәр дә җыелган итләр сатылып акча ителсә, моннан дүрт мең сум кадәр акча җыелыр иде.

Гафил булмаска кирәк.

Корбан өч өлештән тора, аның бер өлеш кадәресе фәкыйрьләргә сарыф кылыну өчен тиеш булгандыр. Хәзер дә фәкыйрьләрнең берничәләре өлкәбездәге ачлардыр.

Ач мөселман кардәшләрем хәтеремә килү илә шатлыклар онытылды. Шатлыкны туклыклы сәнәләрдә итәрбез. Вә шул сәнәләрдә шатлык мәкаләләре дә язылыр.

Йолдыз. – 1907. – №74.

Текстларны басмага ***Фатих Хәбиб*** *әзерләде.* ■

Әсәр филология фәннәре докторы, профессор РИФКАТЬ ӘХМӘТҖАНОВның шигъри тәрҗемәсендә бирелә.

КУТАДГУ БИЛИК

(Котайткыч белем)

Йосыф Баласагуни
(Йосыф Хасс-Хаҗиб)

Намаз укыганны «монафикъ», диләр,
«Монафикъ» диелде тәкъвәрәк бийләр.

Хәләл бетерелде, харам өстәлде,
Харам ашаучының пычрак өстәле.

Хәләл дигән сүз бар, үзе генә юк,
Харам-талау китте, бетәсе дә юк.

Канә, кем харамны харам диюче?
Һәр харамны ташлап хәләл җиюче?

Фикер иясе дип аталмыш ул кем?
Кайда ул хакыйкать? Ачсын битлеген.

Харам белән артык каралды күңел.
Хәләл кайда? Табыйк шуны, и, угыл.

Бу бапта хәтергә килде шундый сүз,
Моны яхшы тыңла, и, күңле төз.

Харам белән күңлем булды кара кер,
Белемгә тотылмый йөз көнемнән бер.

Тән дәрте көн бирми, һәвәс котыра,
Тагать-гыйбадәткә сирәк утырам.

Галәм юлы мотлак үзгәчә китте,
Кешеләр күңеле үзгәрде инде.

Дөреслекнең өстен алдау каплады,
Эзләп, ышанырлык инсан калмады.

Вафа качты илдән: җәфа көчлерәк;
Ышаныр, таяныр кешеләр сирәк.

Туганнар, кардәшләр мине ташлады,
Дуслар миһербанлык итми башлады.

Әманәт — сүз генә, хыянәте — чын,
Нәсихәт диелә, юк тик тотучы:

Сатучылар сатты әманәтләрен,
Остазлар онытты нәсихәтләрен.

Кайда кагыйдәләр куючы затлар?
Мөртәт-мөнкирләрне тыючы затлар.

Белемчеләр әйтә алмый белгәнен.
Хатыннар оятсыз — өртми йөзләрен.

**Теле йомшак илнең, күңеле каты,
Турылык дигәннең калды тик аты.**

*Ахыры. 2013 елның 10 нчы саныннан басылып килә.

Бозылыш ай саен, көн саен арта —
Акыллылар аңлый, белемле белә.

Туры-төз юк инде, кәкрелек тулган,
Берәү дә йөрмидер Тәңре юлыннан.

Җәмәгатьләр ишле, мәчет аз иде,
Мәчет күп, җәмәгать[1] хәзер аз инде.

Барча кешеләрне көмеш кол кылды,
Көмеш кемдә, бар да шуңар буйсынды.

Ни ди, ишет, әнә, фикерле кеше
(Күңелгә ал аны, игелек башы):

«Кайда ул тугрылык кылучы, кайда?
Кайда Алла хаккын белүче, кайда?

Бар инсан әхлакы тәмам бозылды,
Моны, хәтта, «гаҗәп» дию юк инде.

Мөселманнар этләр кебек талаша,
Кяфер генә рәхәт яши, тамаша!

Мөселман туздыра бар мөлкәт-малын,
Аермый беркем дә харам-хәләлен.

Кичен йокы бирми азгын шау-шулар,
Кая монды гыйлем, Корьән укулар!

Теле йомшак илнең, күңеле каты,
Турылык дигәннең калды тик аты.

Аталык кыла, күр, атага угыл,
Угыл бәк булып, күр, ата булды кол.

Яшәү кысанланды, озайды гаме.
Хирыслык күп малга, юк яшәү тәме.

Ятим, мал, ярлыны кызганучы юк,
Галәм серләренә таң калучы юк.

....

Ахырзаман җитте — канун[2] өзелә,
Яманга ияреп яхшы бозыла.

Угыл-кыз атаны хөрмәт итмидер,
Алар өлкәннәрне сүгә һәм көлә.

Бозылыш ай саен, көн саен арта —
Акыллылар аңлый, белемле белә.

....

Тарих кануннары тикшерелделәр
Һәм ак белән кара бердәй булдылар.

Болар — кыямәт көн билгеләредер,
Беленгәч билгесе, килер әле бер.

Илаһым сакласын иманыбызны,
Кичерсен гөнаһлар кылганыбызны.

Һиҗри дүрт йөз алтмыш икенче елда[3]
Язылды бу шигъри үлчәмле юллар.

Акылым җиткәнчә яздым мин төгәл,
Укучым, укыгач, миннән өлге ал.

Нинди юл-юрыктан барсаң да үзең,
Бераз бирдем сиңа акыл нигезен.

Сөйләп бирдем дөнья һәм дин турында,
Йөре әйткәнемчә, язма юлыңнан.

Теләсәң дөньяны — күрсәттем юлын,
Ахирәт дисәң дә, өйрәттем шуны:

Гыйбадәт кыл, шуннан Алла көч бирә,
Ходай бирә дәрман, кылма үч кенә.

Илаһи, башладым үзем бу сүзне,
Теләгемне күптән беләсең үзең.

Теләмәдем үзем өчен хакимлек,
Кешегә игелек иттем — һәркемлек.

Укучы укыса мине искәреп,
Дога кылыр әле, димен, хисләнеп.

Теләгем-өметем менә шул гына.
Укучым, рухыма дога кылсана.

Телем сөйләде һәм язды кулларым,
Телем, кулым үлер, и, дус-туганым.

Бу китап телемнең, кулымның эзе,
Хөкеменә куйдым, и, җете күзлем.

---

[1] Җәмәгать — биредә «мәхәллә кешеләре җөмләсе».
[2] Канун – биредә «борынгы күпкыллы эскерипкә».
[3] 1070 нче елда.

**Җофардан килә тик һәрвакыт хуш ис,
Ерактин исеннән беленә тирес.**

Онытма мине, и, тере укучым,
Дөнья куеп, яткач кара җир кочып.

Йа, син — мәңге яшәр иям, син — олуг,
Ярлыкагыл мине — мин моңлы колың.

Абынгыч кол идем, гөнаһым күптер,
Языкны ярлыка, гафу итә күр.

Колың идем, мин бер колдай кол инде,
Рәхимле бер хуҗа була бел инде.

Мин — колың, син — хуҗа, син гафучедер,
Мине ярлыка, бар языкны кичер.

Шулай ук ярлыка барча мөэминне,
Гарептән шәрыкка кадәр, һәркемне.

Утын мин, утыннан утынлык килер,
Беләсең, аңлыйсың барсын да, кичер.

Җофардан килә тик һәрвакыт хуш ис,
Ерактин исеннән беленә тирес.

Өметләнүчеләр өчен изге син,
Өметемне инде өзмәссең димен.

Языклы колыңмын, кылганым җәфа,
Вафалы хуҗа син — кыл миңа вафа.

Җәфалыдан җәфа гына киләдер,
Вафалылар вафа кыла беләдер.

Барча мөэминнәрне кичергән көндә
Мине дә исәплә шулар рәтендә.

Пәйгамбәребезгә төмән мең сәлам:
Изге кулавызга тугры мин тәмам.

Аның дүрт дустына миннән, Ходаем,
Иге теләк кенә җитсен һәрдаим.[4]

**Төмән мең чәчәкле язлар кебек идем,
Көзем килде барсын сарыларга төреп.**

БЕРЕНЧЕ КАСЫЙДӘ. ЕГЕТЛЕК ЧОРЫ ӨЧЕН АЧЫНУ ҺӘМ КАРТЛЫКТА ҮКЕНҮ ТУРЫНДА

Бураган болыттай яшьлектә җилкенеп,
Гомерем төкәнде узгынчы җил кебек.

Исәр егетлегем, и, исәр егетлек,
Тоталмадым сине — киттең шул ычкынып.

Янә килсәң иде тик бер кайтып, димен,
Учыма күтәрим, ефәк бүзләр куеп.

Исәр егетлегем, кая киттең узып!
Чакырып алынмый, табылмый кыдырып.

Яшәү татлылыгы, җаным сөенече:
«Егетлек кебек бер ни юк», – дим, кычкырып.

Балачак бәхете, егетлек шатлыгы
Юк инде, калдылар кайдадыр качынып.

Карыйлыкта кур[5] юк, акыллы булсаң да,
Гомер үтте зая, юккарак кызыгып.

Хәтерләп ачынам синнән, и, егетлек —
Бөтен матурлыгым калды ич йолкынып.

Тәмам *аргуандай*[6] иде яңакларым,
Калды алар бүген зәгъфырандай булып.

Җофарлы баш *кяфур* шикелле ак булды,
Айдай йөзем сүнеп, күз-күлләрем корып.

Төмән мең чәчәкле язлар кебек идем,
Көзем килде барсын сарыларга төреп.

Тәнем каен кебек ак иде, төз иде,
Хәзер җәя кебек калдым шул бөгелеп.

Тереклек куәтен уенда туздырдым,
Хәзер елыйм инде мин шуңа үкенеп.

Балачак кичердем, яшьлектә очындым,
Көннәремне күмдем, утырамын чүгеп.

Ашадым ат кебек, эчтем сыер кебек,
Гыйшыгымда чаптым тузан бөркелдереп.

---

[4] Тикшерүчеләр фикеренчә, Йосыф Хасс-Хаҗибның язганы шунда тәмамлана, моннан калганын — касыйдәләрне һәм азаккы бүлекне бүтән бер кеше (мәсәлән, күчерүче) язган, диләр.
[5] Кур — «ут саклау өчен калдырылган күмер», монда «эчке потенциал, рухи гайрәт».
[6] Аргуан — «затлы агач һәм шул агач сутыннан ясалган матур кызыл шәраб», зәгъфран – «сары чәчәкле үсемлек, сарылык символы», кяфур – «камфара, аклык символы».

Чыгып кош чөюгә[7] күпме күңел ачтым,
Тик егетлек кошым кайтмады, чөелеп.

Дус-ишләремә мин җандай якын идем,
Дошманга ташландым асаудай[8] өереп.

Исәпсез кешене мин сүктем-рәнҗеттем,
Гаделлексез ярлык[9], тел, кул тидереп.

Кукыраеп дошманны җиңгән ир шикелле,
Кыя булып бастым, күкрәгем киереп.

Адашканлыгымнан ояламын хәзер,
Гүя, айныганмын бер эчеп исереп.

Намаз-ниаз калды — кешегә табындым,
Кудым дөньяны мин туктамый йөгереп.

Теләк азгынында чаптым ничә тапкыр
Котырган бүредәй улап һәм үкереп.

Кеше тотып йөрдем акча талау өчен,
Ачындырып, изеп, тәмаман бөлдереп.

Ник алай кылдың, дип, сораса бер Раббым,
Калам үземне мин оятка төшереп.

Каю тиле хәле булыр минекедәй?
Һәр үткән көн өчен гомерегә төкереп.

Сөенечләр үтте, монда яшим инде,
Зая булды көн, ай кәеф-сафа сөреп.

Хөсрәү яки Кайсәр кебек булдым ич мин,
Шәтдат һәм Гад кебек оҗмахлар җиткереп.

Бөтен дөньяны мин Искәндәрдәй тоттым,
Нух яшенә җиттем күпме рәхәт күреп.

Яшен-кылыч тоткан Хәйдәр кебек булдым,
Рөстәмгә килгән дан миңа да бер килеп.

Күңелемнән Гайсә кебек күккә мендем,
Яшәдем Нәүширван кебек канун биреп.

**Ялангач килдем мин дөньяга, ялангач
Китәмен, нигә мин тырыштым котырып?**

**Кичәр дөнья гүя көчле бер җил кебек,
Җиһан җиле мине алды шул бөтереп.**

Яшәдем Карундай хәзинәләр җыеп,
Яшәдем Әсхабе-Растай тимер кальгә корып.

Боларның азагы бер — җиргә керүдер,
Ике бүз кисәге калды миңа торып.

Ялангач килдем мин дөньяга, ялангач
Китәмен, нигә мин тырыштым котырып?

Кичәр дөнья гүя көчле бер җил кебек,
Җиһан җиле мине алды шул бөтереп.

Яшәүгә ямь биргән саф холкым, син кайда?
Егетлектә түктем сафлыкны бетереп.

Ниләр чәчкән булсам, шуны урдым инде,
Шул урганны яшим хәтергә китереп.

Егетлегем узды, карыйлыгым җитте,
Әйткән сүзләремне яшимен тикшереп.

«Озын төннәрендә гыйбадәт кыл, – димен
Үз-үземә, — баттың гөнаһларга кереп;

Бу тәнне корт-коңгыз, суалчан кимерер,
Ник симерттең аны татлы аш сеңдереп».

Уян син гафил җан, уян да бер ела,
Илаһка табуг кыл, җаныңа кот биреп.

Егетлек еракта, карыйлык каршымда,
Яшимен үземне саф юлга күндереп.

Бу дөнья әветкәч азмы халык азды,
Менә мин шундыймын —
сөйдем күңел биреп.

Йа Рабби, син мине уяу кыл, и, Иям,
Күңелне пакьләдем – кума мине сөреп.

Языкны син генә онытырлык хуҗам,
Мине ярлыкла Син, гөнаһым кичереп.

Тәмам ■

[7] Кош чөю – «ау кошы (лачын һ.б.ш.) белән аулау».
[8] Асау — «кыргыйлашкан айгыр».
[9] Ярлык — «хөкем, әмер, приказ».

Безнең мирас №8 август 2017

ҺАДИ ТАКТАШНЫҢ ФАТИХ ӘМИРХАНГА *мәрсиясе*

Рүзәл Мөхәммәтша

Каләм язганны ут алмый, дигәннәре хактыр, мөгаен.

Татарстан Республикасының Милли музее уздырган бер кичәдә кунакларга Һади Такташның «Ул безнең өчен үле иде инде» мәкаләсе тәкъдим ителгәч, шулай дип уйлап куйдым. Мәңге яшь һәм яшьләр өчен мәңге үз шагыйрь белән вакытында гаять дәрәҗәдә җенләнеп алганлыктан, ми аппараты, җиңел генә кабынып, «архивы»ннан әлеге язманы җәһәт кенә табып алмакчы иде... булмады. Гаҗәпме? Юк икән. Истәлек, соңрак ачыкланганча, шагыйрьнең күптомлыкларына (искесенә дә, «тулыландырылган», зәңгәрсу тышлы яңасына да) кермәгән. «Яңалиф» журналының 1931 елгы декабрь санында гына басылып калган. Һәм... хәзер басылачак менә.

Күләме ягыннан (бәлки, эчтәлеге ягыннан да?) зур булмаган бу мәкалә язучы Фатих Әмирханның үлеме уңаеннан язылган, Һади Такташның үлеме уңаеннан дөнья күргән. Ул – яңа заманның искесе өстенә менеп таптануы нәтиҗәсе. Борын асларындагы бала йоны алсу таңда сыек мыекка алышынган яңа чор «даһилары»ның «заман пароходыннан» Тукайларны, Дәрдемәндләрне бәреп



H. TAQTAŞ

UL BZNEꞐ ӨCEN YLE IDE INDE

(ISTƏLEK)

Kmnər өcender Fatьjx Əmirxan əle xəzrdə də jaqtь ʙer jazucь ʙulьp jəşi torƣandьr. Ul yze tudrƣan, yz ruxnda tərʙiələgən tatar ʙurƶua intelegintsiəsenen, dөreserək əjtkəndə tatar „dƶentelmentlarь", tatar „madmuazillərə" jərəgndə yzlərə ylgəncə jəşər ʙəlki. Ləkin Fatьjx Əmirxan ʙzneꞑ sьjnf өcen yle tudь-ul ylygə qədər yk ʙzneꞑ өcen yle ide...

Min Fatьjx Əmirxan ʙiən ʙrnce mərtəsə 22 nce jlnьꞑ qşnda ʙer məktəptə ʙulƣan tatar studentlarь kicəsndə tanştьm. Ul vaqtta inde min tanьlьp kilə torƣan ʙer şaƣir idem. Tanştьrucь kşeneꞑ ismen xəterləmim xəzer. Ləkin Fatьjxnьꞑ tanьşu vaqtnda minem jərəktə ez qaldrƣan:

H. Taqtaşnьꞑ quljazmasь.

—Sovet jazucьlarьna ʙulƣan acь kəly qaraşь, şuꞑa jynəltkən syzlərə əle də xətrmdə.

Anьꞑ sovet, revolytsiə jazucьlarьn kyrə almauь, alarƣa ʙulƣan kəly qaraşь, revo-

A'arnьꞑ əsərlərə ʙlən ƣaqlsizlar jortnda qəqьrьnьp jərycə tilələrneꞑ syzlərə arasnda ajrma ʙik az. Auru ʙer jaqtan nəsldən kilgən sifilistə ʙulsa, ikncə jaqtan nəsldəge

Такташның «Яңалиф»тә басылган мәкаләсе һәм иллюстрация рәвешендә урын алган кулъязмасы. 1931 ел

төшерергә илереп яшәгән чаклары. Такташның бу истәлеге – шул шаукымның асылын чагылдыручы документ.

Соңрак, 1969 елда, шагыйрь Хәсән Туфан «Могикан» поэмасында (ул да Фатих Әмирханга багышланган) язганча:

Безнең әле
Үтә яраткан төс
Бары зәңгәр, бары ал иде.
Үз артында ***аның***[1] *атына да*
Тел тидергән чаклар бар иде,
Бар иде...

«Карт-корыны» нигилистик караш
Күмдермәкче иде терелэй:
Ул, янәсе, аристократ әдип,
Сез, янәсе, люмпен, плебей!..

Такташның бу истәлеге – шул карашны раслаучы документ.

Язма, әйткәнемчә, томлыкларга кермәсә дә, аңа кайбер әсәрләрдә сылтама бирелгән икән. Афзал Шамов каләменнән төшкән «Бер кичәдә» хикәясе – шундыйлардан: Габдулла Тукайның үлеменә ун ел тулуга багышланган чарадан соң бер төркем иҗатчылар – Һади Такташ, Гадел Кутуй, Фәхри Әсгать, Гомәр Толымбай, журналист Габдулла Әхмәдиев, автор үзе һәм тагын ике-өч кеше Фатих Әмирхан эргәсендә «кич утырырга»га кала.

1923 ел. Апрель. Казанның салкын бер куышы. Серле караңгылык. Бүлмәдә чатнап мич яна...

Шушы урында язучыга хатирәләрен яңартырга мөмкинлек бирик: «Сүз татар әдәбиятының бүгенге торышына, яңа бөреләнеп килүче футуризм, символизм һәм имажинизмнарга, шул «измнар»га ияреп язылган, ул вакытлардагы газета-журнал битләрен шактый чуарлаган шигырьләргә күчте. Бу темага күчкәнче мәҗлесебез шома, матур, бәхәссез барган иде, әдипнең үз сүзләре белән әйткәндә, кыйблабыз бер юнәлештә иде. Бу темага күчкәч, Ф.Әмирхан модалы «измнар»га ияреп язылган мәгънәсез, эчтәлексез шигырьләрне шигырь дип санамавын әйткәч, бу «измнар»ны заманның вакытлы бер чире дип атагач, әдәбиятта бары реализм методы гына яшәргә тиеш, дип сөйли башлагач, ничектер мәҗлесебезнең рухы үзгәрде, юлыбыз сикәлтәләнә төште, чәкүшкәләребез[2] дә бәрелешеп, сынгалап алды. Ф.Әмирхан мондый сөйләшеп утырулар вакытында тактны, әдәпне саклый белә, тупас сүзләр әйтеп мәҗлестәшләренең хәтерен калдырмый, аларның үз-үзләрен сөю хисләренә тукынмый иде. Шулай да нәрсәдер булды, әдипнең бу сүзләре кай ягы беләндер Һ.Такташка ошамады. Ул урыныннан торды, төн уртасы булуга карамастан, китәргә җыенды һәм, кул бирмичә генә саубуллашып, чыгып китте. <...> Ф.Әмирхан Такташның урыныннан торып ни өчен чыгып китүен төшенде, билгеле. Ләкин ул аңа әһәмият бирмәде...»

Афзал Шамов Такташның «Яңалиф»тә басылган истәлеген дә хәтергә төшерә һәм аңа кагылышлы фикерен: «Әгәр шагыйрь мәҗлеснең ахырына чаклы утырып, Ф.Әмирханның соңгы сүзләрен ишеткән булса, бәлки, бу истәлеген икенче рухтарак язган булыр иде», – дип йомгаклый.

Бәлки, бәлки...

Әмма без истәлекнең язылган нөсхәсе белән генә таныша алабыз.

---

[1] Аерымлау – минеке. – Р.М.

[2] Бу чор мәҗлесләрендә «урыс агае» хәзерге кебек табын күрке булмый әле. Сүз, хөрмәтле укучылар, сез уйлап өлгергән «чәкүшкә» турында бармый. – Р.М.

Безнең мирас №8 август 2017

УЛ БЕЗНЕҢ ӨЧЕН ҮЛЕ ИДЕ ИНДЕ

Һади Такташ
(Истәлек)

Ф.Әмирхан фотосы. Ачык хат (открытка). Казан. 1915

Кемнәр өчендер Фатих Әмирхан әле хәзер дә якты бер язучы булып яши торгандыр. Ул үзе тудырган, үз рухында тәрбияләгән татар буржуа интеллигенциясенең, дөресрәк әйткәндә, татар «джентельменнары»ның, татар «мадмуазельләре»нең йөрәгендә үзләре үлгәнче яшәр, бәлки. Ләкин Фатих Әмирхан безнең сыйныф өчен үле туды – ул үлүгә кадәр үк безнең өчен үле иде...

***

Мин Фатих Әмирхан белән беренче мәртәбә 22 нче елның кышында бер мәктәптә булган татар студентлары кичәсендә таныштым. Ул вакытта инде мин танылып килә торган бер шагыйрь идем. Таныштыручы кешенең исемен хәтерләмим хәзер. Ләкин Фатихның танышу вакытында минем йөрәктә эз калдырган, совет язучыларына булган ачы көлү карашы, шуңа юнәлтелгән сүзләре әле дә хәтеремдә.

Аның совет, революция язучыларын күрә алмавы, аларга булган көлү карашы революция әдәбияты көчәйгән саен көчәя барды.

Егерме өченче елда башланган татар революция әдәбиятындагы күтәренкелек, пафос вакытында Фатих тирәсе «шул вакытта революция давылын җырлаучы» язучылардан көлү, гайбәт сату почмагы булып әверелгән иде.

Ул миңа бер очрауда яшь язучылар турында болай диде:

– Мин яңа әдәбиятта кызык бер нәрсә күрәм. Аларда рухани яктан табигыйсезлек бар. Аларның әсәрләре белән гакылсызлар йортында кычкырынып йөрүче тилеләрнең сүзләре арасында аерма бик аз. Авыру бер яктан нәселдән килгән сифилиста булса, икенче яктан нәселдәге алкоголь тәэсире, – диде.

Сулдан уңга: «яшь» язучылар Габдрахман Минский, Демьян Фәтхи, Шамил Усманов, Әсгать Айдар, журналист Исмәгыйль Усманов, Һади Такташ. 1928 ел

Фатыйх яшь язучылар турында шундый караштa иде. Ул, пролетариат революциясен күрә алмаган кебек, революция язучыларын да күрә алмый иде.

***

Май ае. Сирень исләре урамнарга сибелгән. Аны соңгы мәртәбә Ленин бакчасында очраттым. Ул бакча уртасында үзенең арбасында бер ялгызы утырадыр иде.

Аның белән озак кына утырдык. Сүз арасында мин аңарга:

– Фатих әфәнде, сез хәзер матбугатта бөтенләй катнашмый башладыгыз. Аратирә генә булса да язгаларга иде, – дидем. Ул:

– Мин элек революциянең гакесен[1] көтә идем. Хәзер инде яза башладым, – диде.

Шул сүзеннән соң үлгәнче нәрсәләрдер язып калдырган бугай. Ләкин аның ул нәрсәләре революциянең гакесен көтеп тә, гакесе булмагач, әрнүле йөрәктән язылган нәрсәләрдер.

Фатих революциянең гакесен көтте. Ләкин ул революциянең гакесен көтүдән яза алмады түгел, аның йөрәге инде үзенең сыйныфы белән бергә үлгән иде. Гакесе булганда да ул, бәлки, терелмәс иде.

Такташ

Югарыда басылган мәкалә 1926 елны Фатих Әмирхан үлгәч үк язылган иде. Һәм шул ук вакытта Такташ аны байтак иптәшләргә укып та узды. Ләкин ул вакытларда нинди сәбәпләр беләндер (үзе аны «ныклабрак, яхшылабрак язу теләге белән» дип аңлатты), Такташның бу мәкаләсе журнал һәм газеталарыбызның берсендә дә басылмыйча калды. Үткән ел Такташ әсәрләренә сүз башы язганда мин Такташның бу мәкаләсенең «язмышы» белән аеруча кызыксынгач, ул үзе архивыннан табып аны миңа тапшырган һәм, кирәге булса, файдаланырга кушкан иде. Такташның бу мәкаләсен, һичшиксез, аның буржуа милләт интеллигенциясенә булган мөнәсәбәтен ачуда зур ярдәм иткән документларның берсе итеп санарга кирәк һәм шуның өчен без аны матбугатта чыгаруны кирәк таптык. ■

[1] Киресен, контрреволюцияне, дигән сүз. – «Яңалиф» редакциясе искәрмәсе.

Безнең мирас №8 август 2017

ЗЫЯ ЯРМӘКИНЕҢ ТУУЫНА 130 ЕЛ

«КҮКРӘК СӨТЕ БЕРЛӘН КУШЫП ШӘФКАТЬ КАНЫН…»

Зыя Ярмәки
(1887-1965)


ضیاء یرمکی.

طویغولرم

یان، کوی، صزلان عزیز جانم یانغان یخشی
بورەك قانك صغلوب، صغلوب طامغان یخشی
طورمش یولن اوستدنگنه اوتوب کیتمەی؛
آز بولسەده آز قالدروب بارغان یخشی.

ناشری:
«کریموف، حسینوف وشرکاسی» نك اوفا شعبەسی.

اوفا، «شرق» مطبعەسی.

ЭЛЕКТРО-ТИПОГРАФІЯ
Товарищества «КАРИМОВЪ, ХУСАИНОВЪ и Ко»
УФА.
1913 г.

Зыя Ярмәки. «Тойгыларым». Уфа, 1913

Алсу башкаруында Зыя Ярмәкинең (Әхмәтзыя Шәйхетдин улы Насыйров) «Ак каен» исемле җырын Конфедерацияләр кубогын Санкт-Петербург шәһәрендә рәсми ачу тантанасында бөтендөнья халкы тыңлады. Ул Җир шарының йөзләгән телеканалы аша турыдан-туры трансляцияләнде. Әмма гасыр дәвамында халкыбыз яратып тыңлаган һәм мәктәпләрдә өйрәнгән бу җырның сүзләре шактый гына үзгәртелгән, ә соңгы юллары яңадан ук язылган икән. Әйтик, Зыя Ярмәки «*...тау яны*» дип язган. Җырда бу сүзләр»... *тау ягы*»на әйләнү сәбәпле, Татарстанда яшәүчеләр шигырьдә сурәтләнгән табигый мохит, Самарадагы ямьле Сок буйларыныкы түгел, ә Иделнең уң ягы, Яшел Үзән төбәгенеке, дип уйлыйдыр, мөгаен. Җырдагы сүзләргә ышансак, балалар яз башында карга бата-чума бәйрәм ясыйлар булып чыга, ә бит Зыя Ярмәки үзенең шигъри юлларында: «*Җәй башында, һәр ел сабан беткәч*», – дип, вакытны төгәл әйтә. Шигырьнең азагындагы өч юлның, аеруча, Самара өлкәсенең Иске Ярмәк авылында Сабан туе үтә торган урын турындагы – «*Әулияләр тавы буенда*» дигән юлның башка сүзләр белән алмашынуы совет чорындагы дәһрилек шаукымы белән аңлатыла булса кирәк. Шуның өстенә, күпләр җырны «Татар халык көенә» дип әйтә һәм яза. Әмма җырның авторы билгеле. Ул – талантлы, әмма бик аз иҗат иткән композитор Мөрсәлим Вәлиев.

Халык арасында шактый танылган «Әни» исемле җыр текстының да Зыя Ярмәкинең күңел җәүһәре икәнен күпләр белми, аны башка авторларга нисбәтләүчеләр, хәтта, Габдулла Тукайныкы, дип язучылар да бар.

Революциягә кадәр шагыйрьнең бер-бер артлы «Күрсәтәм» (Эстәрлетамак, 1912), «Яшьлек дәртләре» (Эстәрлетамак, 1912), «Тойгыларым» (Уфа, 1913), «Әдәбият гөлләре» (Ырынбур, 1913) исемле шигырьләр җыентыклары дөнья күргән, әсәрләре «Бәянелхак», «Казан мөхбире», «Вакыт», «Шура», «Ак юл» исемле мәртәбәле газета-журналларда басылып чыгарга өлгергән. Игътибарыгызга Зыя Ярмәкинең шушы җыентыклардан берничә шигырен тәкъдим итәбез.

Редакциядән

БЕЗ ТҮГЕЛМЕ?

Без түгелме дөньяны тетрәткән ата баласы,
Без түгелме дөньяны гизгән җиһангир баласы.

Кайда бездә иске гайрәт, кайда шәүкәт – берсе юк!
Калмады бит җир йөзендә ичмасам бер данәсе.

Инде бетдек, кайда китдек, бармы бер белгән кеше?
Сыкрый җанлар, тетри дөнья, бар микән сизгән кеше?

Әллә кан үзгәрдеме? Юк, әлдә ул гайрәт каны!
Тор! Уян! Әй, мәңгелек дөньяда шан алган кеше!

ТЕЛ ВӘ ТАРИХКА МӘХӘББӘТ

Егетләр, кайда сездә иске гайрәт?
Егетләр, кайда сездә иске һиммәт?
Уян, күз сал менә шул тузган илгә,
Көтә сезне, бетәм, ди, кайда хидмәт?

Бетә ил, кайда ярдәмгә егетләр?
Бетәләр, без дәме шунда бетәбез?
Кирәкми, бетмибез, бездә чыдам бар,
Әнә шул якты йолдызга җитәбез.

Менә бу колда әнкәйнең теле бар,
Бусында – милли төстә ак-яшел «төс».
Мине илтәләр анлар ак тәхеткә,
Өмид бар, мин җитәм бер көн бәхеткә.

Менә – күкрәк, минем ул милли калкан,
Бу тел – кылычым, мирас ул карт бабайдан.
Тотам калкан, чабам дошман, әйтәм сүз,
Ватам мин дә, бабайлар дөнья ваткан.

Әнә, Алтай тавы күкрәк киергән,
Әнә, Эссе күле, җиргә җәелгән.
Сөям ул күл белән тауны җанымдан,
Беләм, Чыңгыз бабай шул анда йөрегән.

Китәм, мин дә барам Чыңгыз бабайга,
Тегәм күз ак бәхеткә, милли айга.
Булам кол милли телгә һәм тарихка,
Яшә милләт, үләм мин ошбу юлда!

ӘНИ

Ий, әни, бер көн рәхәт күрми үлеп киткән әни,
Тик яну-ялкын белән тормыш юлын үткән әни.

Яшь көнемдә төн буенча ак бишекне тирбәтеп,
Егласам күз яшләрем сөрткән, сөеп үпкән әни.

Мин сине мәңге онытмаска гаһед бирдем хәзер,
Күңлемә алтын кеби сүзләр төзеп киткән әни.

Мин сөйләрмен, әнкәем, илгә синең ул сүзләрең,
Ий, миңа тойгым сөйләрлек тел биреп киткән әни.

Һәр намаз саен Ходайга ялбарырмын мин хәзер,
«Кыл дога, бәбкәем», – диеп, вәгъдәм алып киткән әни.

Ий, миңа күкрәк сөте берлән кушып шәфкать канын,
Күп өчен кан-яшь түгәрлек аң биреп киткән әни.

Белмим, ил аңлар микән соң яшь күңелнең ялкынын,
Ий, күңелгә мәңгелек эз калдырып киткән әни.

КИҢӘШ

Күңел кошың канат җилпеп очмас борын,
Урман, таулар, диңгезләрне кичмәс борын,
Шатлан әле, сөй дөньяны, уйна да көл,
Күз яшьләрең төрелеп-төрелеп төшмәс борын.

Күкрәгеңдә тормыш уты капмас борын,
Йөрәк каның сыгылып-сыгылып акмас борын,
Болгар кызы кара күзен мөлдерәтеп,
Яшь күңелгә сүнмәс ялкын якмас борын.

Шатлан әле, сөй дөньяны, уйна да көл,
Тормыш тавы басып, кысып измәс борын,
Чык сәхрага, рәхәт тормыш көен көйлә,
Сандугачың күкрәгеңдән бизмәс борын.

Киң диңгездә колач салып бер йөзеп кал,
Дулкыннары тау-тау булып купмас борын,
Каек белән әйләнмәдә әйләнеп кал,
Упкыннары мәңгелеккә упмас борын.

ХАТЫНЛАР

Сез матурсыз, пакь фәрештә, сайрыйсыз былбыл кеби,
Сез кычырткалар арасында күренгән гөл кеби.

Сез мәхәббәтле, ягымлы, сезгә дип яшь җан чаба,
Белми мескин, алдана, хәсрәт өчен ник шатлана?

Сез фәрештә, пакь күңел, шәйтан да сез, иблис тә сез,
Мәңге иптәш, мәңге дуст һәм мәңгелек дошман да сез.

САБАН ТУЕ АЛДЫННАН

Туры айгырны ничә көнләр инде
Көйләп-көйләп кенә сыйлыйлар.
Башка вакыт түгел, кыйнау кая,
Кыргычлыйлар, башын сыйпыйлар.

Туры айгыр да нидер сизә, нидер көтә,
Башын салып-салып уйлана.
Кайчан кызыл яулык колагында,
Кайчан артка калган, хурлана.

Йөрәксенә кайчак, кешнәп куя,
Киң сарай да аңа тар кебек.
Күптән инде күңеле тышка тарта,
Киң далада нидер бар кебек...

АК КАЕН

(Мөрсәлим Вәлиев музыкасы)

Яфраклары яшел ак каенның
Хәтфә җәйгән кебек һәр ягы.
Әйлән-бәйлән уйный яшь балалар,
Гөрләп тора һәркөн тау яны.

Яшь балалар, бигрәк матур кызлар
Ак каенны сөеп мактыйлар.
Җәй башында, һәр ел сабан беткәч,
Ак каенда бәйрәм ясыйлар.

Ап-ак каен инде бик карт каен,
Яшьләр күңле аның куйнында.
Ялгыз гына үсә, ялгыз яши
Әүлияләр тавы буенда.

***

Ян, көй, сызлан җаным, янган яхшы,
Йөрәк каның сыгылып-сыгылып тамган яхшы.
Тормыш юлын өстендән генә үтеп китмәс,
Аз булса да эз калдырып барган яхшы.

Текстны басмага Самара өлкәсенең Камышлы,
Кләүле һәм Исаклы районнары имам-мөхтәсибе
***Габдулла хәзрәт Мөхәммәдкәрим** әзерләде.* ■

Безнең мирас №8 август 2017

Бервакыт та дусны бирмәм ятка,
Дошманны дус итмәм бер чакта.
Наис Гамбәр

Казан белән Мөслим арасындагы дүрт сәгатьлек юл сизелми дә үтте. Сәфәрдә чакта башка кылә торган борчулы уйлар да моңсу гына юл читендәге каеннарга сарылып калды. Әйтерсең мин Мөслимгә якын дустым чакыруы буенча кайтып киләм. Район үзәгендә мәгариф бүлеге хезмәткәре Лениза ханым Гәлимова каршы алды. «Әйдәгез, эшкә керешкәнче, мин сезгә Мөслим үзәген күрсәтәм», – диде ул һәм без күп тә үтми гөлләргә, агачларга төренеп утырган, матурлыгы белән аллея-бакчаны хәтерләткән киң урамга килеп кердек. «Пушкин урамы бу, – диде ханым, – бераздан ул Тукай урамы белән кисешәчәк. Киләчәктә Тукай урамында, Казандагы кебек, «Печән базары» төзергә уйлыйлар. Анда шигъри митинглар узачак. Мөслим соңгы елларда менә шулай чәчәккә, гөлгә күмелде».

Шагыйрьнең яшьлек утравында

Ирек Нигъмәти

Тукта! Бу сүзләрнең кайчандыр минем колагыма кергәне бар иде бит инде. Кемнән ишеткән идем соң әле мин аларны? Хәтерне яңартырга теләгәндәй, күкрәк кушлыгында тыныч кына типкән йөрәк, чыгымсыз ат кебек дуамалланып, сикергәләп алды. Күз алдыма Мөслим төбәгенең газиз улы, шагыйрь дустым Наис Гамбәр килеп басты. Әйе, туган ягы турында сүз чыкканда, бу сүзләрне ул бик еш әйтә иде. Бу сүзләрне генәме? Менә хәзер дә кайсыдыр урам чатыннан эш сумкасын иң башына кыеклап аскан Наис абый килеп чыгар да, яныбызга тукталып: «Их, егетләр, нәрсә беләсез соң сез. Тукай, Пушкин проспектлары алар бит безнең яшьлек урамнары иде», – дип кыска, юан бармаклары белән кайларгадыр күрсәтә-күрсәтә, шушы урамнар турында бөртекләп сөйләп китәр иде сыман. Хыял мине саклык белән генә кулымнан тотып, Хәтер утравына таба алып китте. Наис абый белән «Татарстан яшьләре» гәҗитенең шул чактагы баш мөхәррире Ислам абый Әхмәтҗанов таныштырган иде. Җитәкләп диярлек пропаганда һәм агитация бүлегенә алып керде дә: «Менә, Наис, сиңа шәкерт алып кердем. Практиканы синдә узар. Ите сиңа, сөяге миңа», – диде дә, икебезне генә калдырып, чыгып китте. Бүлмә түрендә уйчан күзләрен кульязмасына төбәгән нык бәдәнле, пөхтә кара сакаллы ир-ат утыра иде. Җитди йөзеннән аның һич тә елмая торган кешегә охшамавы мине бераз каушата төште. «Бүген хатларга җавап язарсың», – дип, кулыма бер кочак хатлар тоттырды. «Хатлар йомшак, итагатьле тел белән язылырга тиеш», – дип тә өстәде. Язмаларны уйланулларга, сүз эченә сүз яшерүгә корып әзерләргә киңәш бирә иде. Беркөнне эш азагында ул укуым, яшәвем белән кызыксынды. «Нинди спорт төре белән шөгыльләнәсең?» – Аның миңа биргән беренче соравы иде бу. «Штанга», – дидем. Йә Хода, агайның йөзе кинәт яктырып китте. «Әйдә, кул көрәштерәбез», – диде ул көтмәгәндә. Шул арада костюмын чөйгә элеп куйды. Наис абый, һичшиксез, миннән күпкә көчлерәк иде. Әмма ул минем көчне сынап карыйсы итте бугай. Мускулларыбыз хәйран киерелсә дә, кулларыбыз бер якка да аумады. Әнә шулай көн саен эш азагында без кул көрәштерергә өйрәнеп киттек. Ул спорт дөньясын, татар спортчыларының язмышларын

биш бармагы кебек белә иде. Хәер, спорт дөньясын гынамы соң? Татар әдипләре арасында әле дә булса Европа, дөнья әдәбиятын аның кебек өйрәнгән, белгән язучы бармы икән? Соңрак ул көчле, шәп шагыйрь булып танылды. Наис Гамбәр шигырьләрен ялгызың калып укыганда гына җанга рәхәтлек табарга мөмкин. Һәр юлын кайтып-кайтып укыйсың, укыган саен ул синең җелегеңә сеңә бара. Шигырьләрен Аккош күле буендагы бакча йортында көзге урман, күл камышлары белән бергә тын калып тыңлаган вакытлар булды. Безнең дуслык шулай башланган иде... «Кылт» итеп аның бервакыт ярым шаярып, ярым җитди итеп әйткән сүзләре искә килде: «Сезнең Дөбъяз, Биектау түрәләре халыктан яшеренеп, койма артында яшәргә ярата. Безнең Мөслим, Актаныш якларында бөтенләй башка халык яши. Син бүген район башлыгы белән бер табында «Алмагачлары»н җырлап утырырга, сәхнәдә бергәләп биергә мөмкинсең, иртәгесен райком бюросында да, иген кырында да син аның янында чит кеше түгел. Иҗат яшьләре арасында да шул ук җитәкчеләр, редакция, мәдәният хезмәткәрләре, укытучылар... Ял вакытларыбызда һава сулап йөргәндә хыялланырга ярата идек: Мөслимдә киләчәктә Пушкин, Тукай исемендәге проспектлар булачак, Тукай урамындагы «Печән базарында» төрле бәйрәмнәр, шигырь бәйгеләре гөрләп торачак. Еллар узар, Мөслимне алда танып булмаячак әле. Бер кайткач күрербез». Менә кайттым. Казанда Мөслимдәге Пушкин урамы кебек борынгы стильдәге кичке фонарьлар, көяз егетләргә сөйгән ярлары белән серләшү өчен әзерләнгән фигуралы сөялгеч урындыклар, хәрбиләр кебек бер сафка баскан төз куаклар, тәүлек буе яктылык нуры сибеп утырган гөлчәчәкләр, мәңге яшел хуш исле чыршылар белән балкып утырган урамнар да, парклар да бардыр, алар анда булырга да тиеш, сүзем юк. Әмма аның Мөслимдәгесе Казанныкыннан мең кат кадерлерәк, мең кат ямьлерәк. Чөнки алар Наис Гамбәр кебек фидакарь Мөслим егетләренең яшьлек дәрте белән туган гүзәллек үрнәге. Наис абый Мөслимне бик еш телгә ала иде. Аеруча район үзәгендәге музейны ул бик яратып исенә төшерде. Чөнки аның беренче нигез ташларын ул салган, халык яратып йөрсен өчен аңа күп көч куйган булган. Бинаның һәр бүрәнәсен, һәр сайгагын аның куллары сыйпап узган. Төзү материалларын да, ерак сәфәрләргә чыгып, юк-бар акчалар белән авырлыклар күреп юнәткән. Шулай да күңелен төшермичә эшләгән. Балта остасы буларак та шагыйрәнә матурлыкны өстенрәк күргән. Казан урамында берәр якташын очратса, ул шунда ук: «Мөслим ни хәл анда, музейга балалар йөриме? – дип сораштыра башлар. Җавапны рәхәтлек кичереп тыңлар. Бервакыт шундый якташларының берсе, хәл белешкәннән соң, аңа: «Наис, синең музееңны бастылар бит, мамонт сөякләрен урлаганнар», – дип куймасынмы? Көтелмәгән мондый сүзләрдән соң, агай югалып калыр, күңелсезләнер дип тә уйлаган идем. Ә абзый борчылуын беркайчан да йөзенә чыгармый иде. Ул чакта да, киресенчә, башта тәмәке тартудан саргая башлаган вак, тигез тешләрен күрсәтеп көлеп җибәрде. Аннары, йөзендәге якташын күрүдән балкыган күрешү шатлыгын югалтмыйча, уң кулының имән бармагын югары күтәрде дә: «Менә шуннан белегез инде Мөслим музееның дөньякүләм әһәмиятен. Кайсы музейлар кулы уйнаганын беләм. Әмма Мөслимдә мамонтлар җитәрлек әле», – диде ул, үзен егетләрчә эре генә тотып. Нәис абый бу сүзләрне әйткәндә зурдан кубып уйлый белә торган ихлас күңелле якташларын да, музей саклаулыгындагы башка мамонт, динозавр склетларын да күз алдында тотты булса кирәк. Хәер, аның үзендә дә мамонтлар рухы яши иде. Минем тизрәк Наис кулы белән дөньяга килгән музейны барып күрәсем, аның кулы аша үткән экспонатларны күздән кичерәсем килә башлады. Теләгемне Лениза ханымга да әйттем. «Менә бит ул, каршыгызда гына», –

диде ул, юлның аръягында безгә йөзе белән торган кәһвә төсендәге ике катлы таш бинага күрсәтеп. «Ялгышмасам, Наис агай төзегән музей агачтан булырга тиеш иде бит», – дидем мин, хәтеремә төзәтмә кертергә маташкан ханымның сүзләренә сәерсенеп. – Бу бит бөтенләй башка, таш музей». «Әйе шул, – диде мәгариф бүлеге хезмәткәре. – Наис абый вафатыннан соң, күп сулар акты бит инде. Үзәктәге барлык иске, агач биналар сүтелде. «Туган якны өйрәнү музее» бинасы да моннан берничә ел элек кенә өр-яңадан күтәрелде. Теләсә-кайсы илнең президенты кереп карап йөрерлек матур итеп төзергә тырыштык. Ни дисәң дә, музей Мөслимнең йөз таныклыгы булырга тиеш. Әйдәгез, кереп карыйбыз». Без сүзсез генә музейга атладык. Шулчак уйлар өерендә Наис Гамбәрнең шушы музейны төзеп йөргән көннәрен тасвирлап язган «Ма-ту-у-у!!!» исемле хикәя-хатирәсе күңелдә яңара башлады...

«Рәссам егет Рәйхан Хантимеров белән Мөслим районы үзәгендә туган якны өйрәнү музее оештыру нияте белән җенләнеп йөргән көннәребез иде. Казанга килүебез дә шул хаҗәттән иде: ясалма киез кирәк иде безгә һәм бик күп кирәк. Табып булырмы аны, без теләгәнчә бирерләрме, буш кул белән кайтып китмәбезме? Гавәм каршында көлкегә калмабызмы? Зурдан куптык ла, хәерсез; җитмәсә, бу дөньяда, сине аңлаучыдан битәр, алдаучылар күбрәк ич. Мөслимдә дә, әнә туган җиремдә, күз күргән кешеләрем, моңа турыдан-туры «җаваплы иптәшләр» күпме тупсалар таптап йөреп тә музей ачу өчен яраклы бина табып бирә алмадылар, һәм без череп беткән бер «тавык кетәге»нә кереп утырырга мәҗбүр булдык. Югыйсә, без уйлаганча, бу эшкә бөтен район җәмәгатьчелеге кубарылырга тиеш иде дә бит, юк шул, юк. Мөслимнең әле бу, әле теге почмагында шәхси «хан сарайлары» гөмбәдәй үсеп чыккан бер мәлдә, без – ике хәерче дивана – үз дөньябызны онытып, оешмадан оешмага бусага таптап йөрдек: «Фәлән-Фәләнеч, ярдәм итегез инде, музей өчен бер-ике кило кадак» яки «бер-ике кубометр такта табып булмасмы», янәсе. Ә бит музей аларга да «кирәк» иде. Рухи хаҗәтләрен канәгатьләндерү, халык алдында, тарих алдында торган бурычларын үтәү өчен түгел, әлбәттә. Югарыдан килгән рәсми кунаклар алдында: »Менә без дә тик ятмыйбыз, халык өчен яшибез», – дип шапырыну өчен кирәк иде музей аларга».

Шагыйрьнең шул елларда әйткән фикерен Лениза ханымга да җиткердем. «Наис абый вакытында ил болгана башлаган иде бит инде, – диде Лениза Рушат кызы. – Рухи хәзинәләр шалкан бәясенә төште. Намуска кадәр сатылды бит. Инде ташларны кабат җыяр, мирасыбызны барлар вакытлар җитте. Рухы зәгыйфь булган дәүләт яши алмый. Шушы хәлгә бәя биреп, район җитәкчелеге, гасырлар буе тупланган гореф-гадәтләребезне, тарихыбызны саклау, иманга кайту, халыкның тормыш тәҗрибәсен яшь буыннарга тапшыру, яшьләрне иҗади хезмәткә максатчан әзерләү нияте белән, 2015-2020 елларны эченә алган «Без – мөслимлеләр!» дигән проект төзеде. Аны тормышка ашыруда бөтен район халкы – Мөслимнең мәгариф, яшьләр эшләре һәм спорт, мәдәният, сәламәтлек саклау, социаль яклау бүлекләре, төрле оешмалар, учреждениеләр катнаша. Балалар бу эшкә шулхәтле бирелде ки, алар Мөслим урамнарының чисталыгы өчен җан атып торалар. «Апа, җирдә бер чүп аунап ятса, шундук иелеп алабыз, районга килгән чит кешеләрдән оят», – дип, безгә шушы эштә үзләренең янып йөрүләрен белдерәләр. Борынгы мирасыбызга да халыкның карашы елдан-ел үзгәрә. Музейны исә районыбызның төп рухи байлыгы итеп саныйбыз. Наис абый заманында нинди кирәкле эш башкарып калдырган икән. Иске бина сүтелгәнгә үпкәләмәгез сез. Якташыбыз башлаган эш дәвам итә бит!»

Музей чынлап та күз явын алырлык зәвыклы итеп төзелгән иде. Ул тамашачыларга иркен, якты күргәзмәләр залы белән ачылып китә. Без кергәндә

анда Мөслим төбәгендә яшәп иҗат итүче рәссамнарның күргәзмәсе бара иде. Бусагадан ук диярлек якты йөз белән музей директоры Синара ханым Җаббарова каршы алды. «Иң еш кунагыбыз – мәктәп укучылары, – диде ул. – Мәктәпләргә автобуслар бирелүе да аларга килү юлын җиңеләйтте. Туган як тарихын өйрәнгәндә бездән балаларның өзелеп торганы юк. Мөслимнән читтә яшәүче якташларыбыз да ялга кайтканда безгә кереп, күңелләрен тынычландырып китә. Туган як һәркемгә кадерле бит. Музеебыз бик бай. Биш меңгә якын борынгы хәзинә саклана. Заллар иркен булгач, барысын да күрсәтеп барырга мөмкинлегебез бар. Дүрт өлештән – археология, этнография, күренекле шәхесләр һәм сугыш даны бүлекләреннән тора. Археология бүлегендә таш гасырында яшәгән кешеләр кулланган савыт-сабалар, ук очлары, сөңгеләр саклана. Динозавр скелетлары, мамонт сөякләре дә Мөслим җиреннән табылган хәзинәләрдән. Менә мамонт калдыкларын Наис абый Гамбәровка су коенучы малайлар табып китергән иде. Мамонтлар монда аз дигәндә ун мең еллар элек яшәгән. Авырлыклары 10-12 тонна, биеклекләре 5,5 метр булган. Бозлык чорында үлеп беткәннәр».

Тагын Наис абыйның исеме телгә алынды. Синара ханым башка сүзгә күчкәнче, сорау бирергә ашыктым: «Наис Гамбәрнең музей төзергә алынуын хәтерләмисезме?» Шуны гына көткән сыман, Синара ханым тагын да ачыла төште: «Нигә хәтерләмәскә? 1989 елда район башкарма комитеты туган якны өйрәнү музее төзү турында карар чыгарды һәм аңа җаваплы итеп Наис абыйны билгеләделәр. Ул, көне-төне дигәндәй, музей төзү белән мәшгуль булды. Казан, Чаллы арасын таптады. Рәссам Рәйхан Хантимеров белән тузган типография бинасын яңартып, бер ел дигәндә музейны өлгертеп тә куйдылар. Җәен малайлар гел алар янында кайнашты. Җитди, сакаллы абыйларның авыл җирендә музей төзеп ятуы алар өчен кызык иде. Музей ачылу көнен зарыгып көтүчеләр дә малайлар булды. Аннары әбиләр, бабайлар еш килә иде. Алар исә, андагы экспонатларны карап, яшьлекләрен искә төшереп йөргәннән соң: «И, оланнар, бик тә рәхмәтле эш башкарасыз икән, Аллаһ ярдәменнән ташламасын», – дип, Наис абыйларны үсендереп, матур теләкләр теләп чыгып китәләр иде. Энтузиастлар, мәктәп музейлары оештыручылар ярдәме белән чүплек башларында аунап яткан, йә булмаса сандык төпләрендә, чормаларда кадерләп сакланган күңел җәүһәрләре музей түрендә урын ала башлады. Наис абый әдәбият, сәнгать, фән дөньясын тирәнтен аңлаган бик зыялы, укымышлы зат иде. Аның кулындагы гап-гади самавыр күз алдында матур тарихи хикәягә әйләнә дә куя. Мамонтлар турындагы хикәясен Мөслим малайлары, укулар башлангач та, дәресләрдә сөйләп «биш»ле билгеләре алды. Аның күңеле матур иде. Тарихыбызга туган якны өйрәнү музеен оештыручы һәм аның беренче директоры булып кереп калды. Казанда торганда да, монда кайткач, музейга керми калмады. Кызганыч, бу дөньядан иртәрәк китеп барды».

«Синара ханымның Наис абый турындагы хатирәсе күңелдә яңадан «Мату-у-у!!!» хикәясен яңартты:

«...берәүнең безнең машина янында туктап калуы сискәндереп җибәрде – таң ката нишләп йөри бу бәндә? Мин теләр-теләмәс кенә урынымнан күтәрелергә мәҗбүр булдым. Карасам, өстенә аксыл төстәге таушалганрак плащ, башына ямьшәйгән кәпәч кигән берәү кулларын маңгаена куйган да, янтая төшеп, Күк йөзенә текәлгән. Ә Күктә... Күктә – тантана: Кояш инде шактый күтәрелергә өлгергән: гөмбәзи җиһан биек, тирән, ачык.

Ул Күк йөзен күзәтә, мин – аны. Һәм шул мәлдә миемне бер гасабилы уй көйдереп узып китте: «Йа Ходa бәндәсе, тегеләйрәк түгелме соң син?» Ни күрә икән ул тирән Күк чоңгылында? Нинди уйлар бәргәләнә икән аның зәгыйфь җанында? Менә аның сүрән, моңсу күз карашлары кинәт яктырып китте, бүлтәеп торган бит очларына алсулык

йөгерде. Әле генә боегып басып торган җан иясе бу минутларда барлык җаны-тәне белән, барлык вөҗүде белән көләшатлана, тантана итә иде. Ул, кәпәчен кулына алды да, башын горурәнә тоткан хәлдә, сакаурак кукрәк тавышы белән Күккә текәлеп бер сүз, бары бер сүз әйтте:

– Ма-ту-у-у!..

Миңа ничектер уңайсыз булып китте. Ул бит берүзе, тулы бер Җиһан белән күзгә-күз калып сөйләшә иде ләбаса! Ул китте. Шул китүе белән мәңге чишелмәслек сораулар да биреп калдырды: «Нигә соң әле бу дөньяның ма-тур-лы-гын күбрәк күрә алган, тормышны матурайту сәләтенә ия булган кешеләргә яшәве торган саен ныграк кыенлаша бара? Шуңа да минем Күкләрне яңгыратырлык, Җиһанны иңрәтерлек итеп кычкырасым килә: җаны исәннәр – ишетерләр, теле барлар – кабатларлар, күзе барлар – күрерләр, иншаллаһ!.. – Ма-ту-у-у!..»

...Музейны карап йөргәндә аның диварларыннан, борынгы хәзинәләреннән мөслимлеләрнең йөрәгеннән күчкән күңел җылысы, күңел матурлыгы бөркелгәнен тойдым. Үземнең дә ирексездән шул хикәядәге акылга җиңел булып та, Күк гөмбәзенә сибелгән йолдызларны көндезен күрә алу кодрәтенә ия изге җан әйткән шул сүзләрне кабатлыйсым килде. Чынлап та, матур иде музей! Мөслимнең фидакарь улы Наис Гамбәр дә дөнья матурлыгына бөтен җаны-тәне, бөтен вөҗүде белән гашыйк булып яшәде. Аның туган җирен фидаиләрчә яратуы тирән уйларга салырлык фәлсәфи шигырьләрен укыганда да ачык сизелә иде. Әдәбият-сәнгать дөньясында якты эз калдырган шәхесләр турындагы публицистик бәяннарын, әдәби тәнкыйть мәкаләләрен, бүтән төр саллы хезмәтләрен дә каләм әһелләренең күңелләрен сискәндерерлек өр-яңа сүздән башланган сәнгати югарылыкта иҗат итте...

Быел 25 августта әдәбият-сәнгать дөньясы Мөслим халкының күренекле улы, танылган татар шагыйре Наис Гамбәрнең тууына 70 ел тулуны билгеләп үтә. Ихтимал, бу тантаналы көннәрдә Мөслимдәге «Туган якны өйрәнү музее»ның күргәзмәләр залы диварына аның портреты эленер. Кеше күңеленә матурлык орлыгы салу өчен ачылган музейга да киләчәктә аның исеме бирелер, бәлки, үз музее төзелер дип өметләник. Әнә, Германиядә ел саен йөзләрчә музейлар төзелә икән. Мөслимдә аның берсе бар инде. Тарих әнә шулай языла. Мирас шулай туплана.

Наис Гамбәр

КАЙТСАМ...

Кайтамын да... Китә алмый ятам,
Көннәр, төннәр ятам интегеп;
Бураннары чыкса – бишмәтем юк,
Яңгырлары яуса – итегем.

Мин гел шулай: кайтсам – китмәс өчен
Бер-бер хәйлә табам, алдашам;
(Йөрәгемдә – утлар, мин су эчәм
Атлар белән агач ялгаштан.)

«Акыллылар» әйтәдер дә (бәлкем?) –
Йөри шунда тик эт сугарып;
Этем түгел, атым сугарулы, –
Кайту белән ташлыйм тугарып.

Тугарылып ташлыйм кайту белән, –
Камыт суккан төшләр ял алсын!
Тик син генә, Ыгым, мәңге тынмас
Яраларны җөйли аласың.

Суың җылы синең, тының җылы –
Синдә генә басам сусымны.
Атлар ялгашыннан сулар эчәм –
Җирсү, сусау әллә шушымы?!

Җиккән атлар тора өй каршында,
Син сорама: «Тагын кай таба?»
Кайтмам, диеп китәмен дә, Мөслим,
Әфсеннәрең тартып кайтара. ■



Серле шагыйрь дустым истәлегенә

Фарсель Зыятдинов

«Кем кулларына калдырыйм?» – шагыйрь Рөстәм Мингалимнең шул исемдәге китабы, минем өстәлемдә инде җиде елга якын, истәлек буларак, күңелемне үзенә җәлеп итеп тора. Мин аны көн дә диярлек кулыма алам һәм кайсы да булса шигырен укыйм, уйланам, Рөстәм белән сөйләшкәндәй булам. Бу китапны бүләк иткәндә аның тәүге битенә истәлек итеп язган юллары аерата уйландыра: «Кайчак ялгыз гына моңланып утырам да: «Килеп тә чыкмыйлар бит!» – дип, дусларны тиргәп алам. Аннан, озакламый килер, килер... Фарсель килеп чыгар әле, дип, үземне юатам...» Аннан соң ул өстәп тә куйган: «Сиңа, Фарсель, бәхетле озын гомер һәм еш очрашып яшәвебезне телим! Рөстәм Мингалим, 2010 ел, гыйнвар».

Күренекле татар шагыйре белән без шулай бик аралашып яшәдек. Аз гына очрашмый торсак та бер-беребезне юксына идек. Әйе, еш очраша идек. Аның Достоевский тукталышындагы фатирында да, безнең Зорге һәм Завойский урамындагы фатирларда да, төрле очрашуларда, кичәләрдә дә, аның Язучылар берлеге йортындагы яшьләргә консультация бирү бүлмәсендә дә, хәтта хастаханәдә дә очрашырга туры килә иде.

Республика хастаханәсендәге хирургның аңа операция ясаган мизгеле истә калган. Шулчак операция бүлмәсенә ярдәмче сестра керде дә: «Киселмәгән җире калмады инде бу абыйның, бүген кайдан башларга уйлыйсыз соң?» – диде ул хирургка, ә тегесе исә аптырап калмады: «Кайсы җирен киссәң дә аңа барыбер, берни әйтми инде ул... Әллә артык түзем, әллә...»

Фикердәшләр: сулдан уңга - Мөсәгыйт Хәбибуллин, Шәукәт Галиев, Фәрваз Миңнуллин, Гәрәй Рәхим, Илдар Юзеев, Гариф Ахунов, Рөстәм Мингалим

Рөстәм Мингалимгә күп сынаулар үтәргә, катлаулы операцияләр кичерергә туры килде, әмма ул төшенкелеккә бирелмәде. Көр күңелле, шаян телле, чын мәгънәсендә күтәренке рух белән яшәде ул, чын шагыйрь булып калды. Ә шулай да, үзе әйткәндәй, ул елларда минем өчен серле дустым иде. Мин дә аның өчен шулай тоелганмын, күрәсең, бу аның миңа багышлап язылган «Серле дустыма» дигән шигырендә дә ачык чагыла:

Мин шикләнеп карыйм сиңа кайчак,
Күптәнге дус үзем синең белән.
Аз беләсең мине, серле дустым,
Ахры, мин дә сине бик аз беләм.
Бер син җилдә очкан мамык кебек,
Бер кузгатып булмас таш шикелле.
Бер син хәтәр-көчле янгын кебек,
Бер янгыннан калган чәчәк көле.
Бер кагасың ярга диңгез булып,
Бер диңгезгә киткән каек кебек.

Үз шатлыгың белән исерек син,
Чит кайгылар белән аек кебек.
Син бу җирдә юкка яшәмисең,
Юкка дуслашмадым синең белән.
Ләкин аз беләсең мине, серле дустым,
Ахры, мин дә сине бик аз беләм.
Безне дөнья белсә, нишләтерләр? –
Уем ялгыш булса, кичер берүк.
Йә атарлар безне, йә асарлар,
Йә салырлар һәйкәл бүгеннән үк.

Бу шигырьдә аның узган гасырның 70нче елларындагы карашы, уй-фикерләре чагыла, яши-яши, аралаша-аралаша без бер-беребезне тирәнрәк аңлаштык... 1997 елда миңа 60 яшь тулу уңае бедән котлап язган шигырендә дә бу ачык чагыла:

Алтмыштан соң да еллар күп,
Юллар күп әле, Фарсель.
Язучылар белән атла,
Галимнәр белән бар син!
Җитә бит Синдә егетлек,
Чыныккан татар ла Син!
Абыйларга, сабыйларга
Үрнәк булып йөр, Фарсель.

Әйләнеп уздырмасалар
Тормыш әйләнмәләре –
Син аларның күзләреннән
Йөзеп узарлык әле...
Милләтнең Син бик кирәкле,
Бик тә газиз баласы.
Бир, каләмдәш, безгә кулың:
– Бәйрәмең котлы булсын!

Каләмдәшләр: Рөстәм Мингалим (сулдан беренче), Әхәт Сафиуллин, Данил Салихов, Илдар Юзеев, Фирдәвес Әһлия, Галимҗан Гыйльманов, Альберт Хәсәнов



Безнең дуслык Арча районындагы хуҗалыкларның берсенә эшкә баргач тагын да тирәнрәк ачылды. Рөстәм укый торган группа студентларын, ягъни төркемдәшләрен шушы колхозга урып-җыюда булышырга җибәргәннәр иде. Мине исә университеттан студентларның эше, яшәеше өчен җаваплы вәкил итеп билгеләделәр. Рөстәм Мингалим белән бергә бу төркемдә шагыйрь Гәрәй Рәхим дә бар иде. Язмыш безнең өчебезне шунда очраштырды. Яшь чак, дәртле чак, иҗат ялкыны ташып торган чак... Иҗат та иттек, җиренә җиткереп эшләдек тә. Тиз арада без авыл халкының ихтирамын яуладык, үзенә күрә нindидер бер канәгатьлек табып эшләдек без ул көннәрдә. Аннары Казанга кайткач, университетның тулай торагына урнашкач, авылда булган көннәрне сагынып искә ала идек. Рөстәм белән Гәрәй Рәхим дә аерылмас дусларга әверелде, кайчан карама, алар бергә булды. Кайда дисез? Тулай торакның гладилкасында. Ике дус киемнәр үтүкли торган шушы бүлмәне иҗат итү бүлмәсенә әверелде, аларның иң көчле, иң кыйммәтле, үзләрен таныткан шигырьләре, әсәрләре шунда туды. Еш кына мин аларның икесен дә Татарстан радиосының «Яшьлек радиодулкынында» дигән тапшыруына чакыра идем, алар соңгы көннәрдә язган шигырьләрен укыйлар, фикер уртаклашалар, яшьләргә киңәшләр бирәләр иде. Миңа, бу тапшыруның редакторы буларак, сабакташларны чакыру, бергәләп гәпләшү үзенә күрә бер бәйрәмгә әверелә иде. Рөстәм Мингалимнең шул көннәрдә Татар радиосыннан сөйләгән гаҗәеп тирән фикерле әсәре һаман да истә. Бу әсәрен ул «Кем кулларына калдырыйм?» дигән җыентыгына да керткән. Лирик-эпик жанрда язылган бу әсәре «Яна-яна киткән торналар» дип исемләнгән. Болай караганда бик гади булса да, тирән мәгънәгә ия ул. Шагыйрь аны гади генә башлап җибәрә: тәүге мәхәббәтен искә ала, аның белән серләшә һәм гади генә детальләр аша образын күз алдына китерә, кичерешләрен, уй-хисләрен тирән итеп ачып бирә. Аны укыгач, ирексездән үзеңнең дә гомер юлыңны күз алдына китерәсең һәм сине дә шул ук тойгылар биләп ала: тиешенчә хәл ителми, аңлашылмый калган мизгелләр күңелне кузгата, йөрәкне сыкрата, ул көннәргә әйләнеп кайтасы, барысын яңача – бүгенге акыл белән хәл итәсе килә, ягъни шундый теләк уяна.

Шушы уңайдан шагыйрьнең «Яшьлек» радиодулкынында яңгыраган тагын бер шигырен искә аласы килә. «Диләрә Тумашевага» дигән бу шигырен ул, без – студентлар бик тә яраткан, бик тә ярдәмчел, бик тә кешелекле укытучыбыз – Себер татары кызына багышлап язган. Университетның татар теле кафедрасы мөдире Диләрә апа Тумашева бу шигырьне радиодан тыңлагач, зур рәхмәтләр әйтеп безнең редакциягә шылтыратты.

Себерне сөрген диләрме?
Сөрген түгел ул Себер!

Татарлар җире ул, дисәк,
Сүзнең иң дөреседер!

Кара урман – тайгаларда
Мөмкиндер адашырга.
Адашмаган, юлын тапкан
Диләрә Тумашева!

Туган телен, туган җирен
Яктырткан шәхес бит ул:
Гыйлеме белән генә түгел,
Хатын-кыз буларак та гөл,
Гөлләрдән нәфис бит ул!

Еллар үткән саен яраткан, якын күргән дуслар китә бара, бары тик алар белән булган истәлекле мизгелләр генә кала. Күпме каләмдәшләребезне югалттык инде: Фәннүрләр, Харраслар, Рахмайлар, Рифкать Закировлар...

Үзенчәлекле талант иясе Рөстәм Мингалим белән без соңгы тапкыр 2014 елның май ахырында озаклап сөйләштек һәм беренче июньдә, ягъни минем туган көнне очрашырга сүз куештык, әмма очрашырга насыйп булмады. Болай дисәм дөрес үк булмас. Без нәкъ шул көнне очраштык, әмма ул инде башка халәттә иде. Рөстәм дустым мин туган көнне мәңгелеккә күзләрен йомды. Аны без Самосырово янындагы татар зиратында җирләдек. Аның каберенә бер уч туфрак салып, Рөстәм дуска соңгы теләгемне юлладым:«Игелекле, ярдәмчел һәм бик тә тыйнак Дустым! Тыныч йокла! Урының җәннәттә булсын! Дусларың, укучыларың, шәкертләрең сине һәрчак сагынып искә алырлар!»

Рөстәм Мингалим шигырьләре

УКЫТУЧЫМ

Күңелемдә – син торасың әле,
Син тикшергән дәфтәр яңара;
Кызыл кара белән язган сүзләр,
Синең сүзләр:
«Күчереп язарга!»
Хәтере калып уйлый балачагым
Синең шулай кырыс икәнне.
...Кич утырып күчерәм.
Язам, язам...
Урындыкта йоклап китәмен.
Атна-ун көн үтә,
Кабат менә
Кыен хәлдә калам, кызарам –
Дәфтәремдә
Миңа таныш сүзләр.
Синең сүзләр;
– Күчереп язарга!
Хәзер инде аңлап уйлыйм сине.
Ә син шундый яхшы,
сөйкемле —
Язмышымны кайгырткансың икән
Мине тапкан әнкәм шикелле.
Кисәткәнсең
Кайчак кеше белән
Тормыш артык кырыс уйнавын:
Китә дә бер хатаң –
Һич төзәтеп аны
Кабат күчереп язып булмавын.

КӨН ЧЫГЫШЫ БУЛЫРГА ТЕЛИМ

Көн чыгышы булырга телим.
О-о, изге жир,
көн дә иртән
миңа кояш суза торган
гүзәл күренешеңә тимим,
үземчә, яңа, җырлаучы
көн чыгышы булырга телим.
Бер кеп-кечкенә кеше мин.
Ядрә булып өзә алам
дошман сулышын.
Зур тормышны яратам:
көлеп йөргән абыйларны,
үбешеп торган яңа парны,
биләүдәге сабыйларны...
Дөнья, күрсәтмә миңа
аһ-зар, сугышың,
күрсәтмә, жырымда шулар
чагылуы бар.
Кешеләрнең йөрәгенә
ачы тоз бөртеге булып
кагылуым бар, —
юк-юк, моны теләмим мин,
көн чыгышы булырга телим,
гел шатлык авазларына,
саф шатлык авазларына
хәреф эзләп
төннәр буе сүзләр язарга:
үлчәп, җыеп аларны,
йөрәгемдә кайнатып,
иртүк халыкка сузарлык
 кояш ясарга.
Мин —
Көн чыгышы булырга телим.

КҮҢЕЛЕМӘ САЛЫП КУЙДЫМ

Әткәм мине
                бер үпкән дә
                    киңәш бирми китеп барган.
Сабый булганмын шул.
Әнкәм сүзен
                күңелемә салып куйдым,
                бикләп куйдым —
                                бөтен хыялым шул:
— «Гомер барда,
Туры очып ялгышсаң да, бәрелсәң дә
                                әй, чыдыйсы иде.
Гомер беткәч,
Максатына тими узган таш шикелле
Егылмыйсы иде!»

ҖӘЯ, ҖЕП ҺӘМ УК

Берәүләр әнә тезелә —
Таза җәя кебек була,
Тезелүне дәвам итә —
Таза җәягә җеп була.
Алар җебе киерелә —
Кыз һәм уллары ук була.
Берәүләр әнә тезелә —
Таза жәя кебек була,
Тезелүне дәвам итә —
Таза җәягә жеп була.
Алар җебе киерелә —
Җәянең угы юк була.
Берәүләр әнә тезелә —
Уртаклашыр уй күп була.
Тезелүне дәвам итә —
Сүзләре кайнар ут була,
Үзләре укка әйләнә —
Җәя белән жеп юк була.

КӨЗГЕ ТӨНДӘ

Күргәнем юк иде мондый төнне —
Төн дисәң дә бүген төн менә!
Су төбендә яткан шәһәр төсле
Казан бүген яңгыр төбендә...
Күмелгәннәр мине борчыр хәлләр,
Караңгылык барын яшергән.
Шуның өчен бугай җаным тыныч,
Калган кебек мең ел яшәргә.
Ә юеш төн шулай йөзен юа
Миңа күренәсе көннәрнең.
Көзге яңгырдан соң шытып чыгар
Яз шытмаган сөенеч гөлләрем...
Күргәнем юк иде мондый төнне —
Төн дисәң дә бүген төн менә...
Су төбендә яткан шәһәр төсле
Казан бүген яңгыр төбендә. ■

КАМИЛ МОТЫЙГЫЙ
(1883-1941)

Камил Мотыйгыйның (Камил Мотыйгулла улы Төхвәтуллин) 1917 елдан соңгы тормышы яңа җәмгыять шартларында үзенә ярашлы хезмәт урынын табу омтылышлары, өзләнүләр, өмет-ышаныч, күңел күтәрелү, күңел төшү кебек катлаулы, каршылыклы уй-хисләр тудыра торган вакыйгалар белән тулы. Инкыйлаб алып килгән үзгәрешләргә зур өметләр баглаган җырчы-журналист хөкүмәт алышынуның беренче көннәреннән үк үз холкына хас кайнар ашкыну-мавыгу белән яңа хакимият гамәлгә куйган эшләрдә турыдан-туры катнаша башлый. Петроградта булуыннан файдаланып, Советның җир, солых турындагы декретларын, Россия һәм Шәрык мөселман хезмәт ияләренә адресланган сәяси мөрәҗәгатьләрен татарчага тәрҗемә итә, Петроградта Милли эшләр комиссариаты карамагында ике генә саны чыккан татарча «Ярлы халык» газетасының баш мөхәррире булып эшләп ала.

1918 елның мартында ул гаиләсе белән Самара шәһәренә күчеп килә һәм май аенда «Самара вилаять мөселман эшләре комиссариаты»ның сул канаты чыгарган «Киңәш» газетасына эшкә урнаша. Ләкин, шәһәргә чех-словак гаскәриләре бәреп керү сәбәпле,

бу газетаның да бары өч кенә саны чыгып кала. Самарада ишле гаиләсе белән яшәгәнлектән, Мотыйгый кызыллар белән бергә китми, шәһәрдә кала. Чех-словаклар вакытында милли шурачылар Самарада «Безнең фикер» исемле үз газеталарын чыгара башлыйлар һәм газета эшенә Камил Мотыйгыйны да җәлеп итәләр. Шушы «милләтчеләр» газетасында аз гына вакыт эшләү Мотыйгый биографиясенә «кара тап» булып ята һәм гомере буе аның совет хакимияте каршында чит-ят сыйныф вәкиле, «ышанычсызлар» исемлегендә йөрүенә сәбәп була.

1918 елның октябрендә Самара кабаттан совет хакимияте кул астына керә. Монда чыга башлаган «Яңа көч» газетасы белән күпмедер хезмәттәшлек иткәннән соң, Мотыйгый 1919 елның башларында туган каласы Җаекка кайта һәм анда әүвәл «Ихтилял байрагы», аннан «Яңа фикер» дигән газеталарның баш мөхәррире итеп билгеләнә. Әмма Гражданнар сугышы чорында Җаек шәһәре йә казаклар, йә советлар кулына гел күчеп торганлыктан, бу газеталарның да гомере бик кыска була. Мотыйгый шулай төрле урыннарда төрледән-төрле эшләрдә эшләп, төрле гаделсезлекләр, яңа туып килә торган совет бюрократиясенең нахак гаепләр эзләп тормышында казынуларыннан туеп, 1924 елда Казанга күчеп китәргә карар кыла.

Егерменче-утызынчы еллардагы пролеткультчылык матбугаты һәм рәсми хакимият органнары Мотыйгыйга якты йөз күрсәтүдән ерак торалар, алар аңа һаман элеккеге эксплуататорлар сыйныфының бер вәкиле итеп карыйлар, матбагачылык өлкәсендәге инкыйлабкача тырышлыкларын, беренче милли газета-журналларны чыгарудагы фидакарь хезмәтен кечерәйтеп, ул үзенә файда алу өчен генә эшләнгән хосусый бер эшмәкәрлек, хезмәт ияләрен талау чарасы гына булган, дигән фикерне алга сөрәләр. Ә эшкә яллаучы белән эшкә яллланучы арасында була торган гадәти хәл – 1906 елда «эшчеләрне забастовкага котырткан өчен» Мотыйгый тарафыннан Тукайның матбага эшеннән азат ителү вакыйгасы совет чоры матбугатында Мотыйгый өстенә ташланган иң зур гаепләрнең берсенә әверелә. Асылда, бу очраклы вакыйганың Тукай язмышына зыян китерерлек бернинди тискәре нәтиҗәсе булмый.

Хәвефле утызынчы елларда Камил Мотыйгый иҗтимагыймәдәни тормыштан читләшебрәк яши. Илдәге гомуми мохит, җәмгыятьнең асыл шәхесләре өстеннән башланган хөкем процесслары, репрессияләр Мотыйгыйдагы рухи ныклыкны җимергәннәнҗимерә бара. 1937 елда улы – Мәскәүдә Татар опера студиясенең директоры булып эшләгән Хәмит Төхвәтуллинның, кулга алынып, бер гаепсезгә хөкем ителүе аны бөтенләй аяктан ега, өметсезлек упкынына төшерә. Моның өстенә, 1941 елның җәендә Мәскәүдә узарга тиешле зур бәйрәмдә – Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында катнашучылар исемлеген төзегәндә егерме ел татар җыр сәнгатенә фидакарьләрчә хезмәт иткән сәхнә ветеранын исемлектән төшереп калдыру Мотыйгыйдагы рәнҗү хисләрен тагын да тирәнәйтә төшә. Еллар дәвамында җыелып килгән нахак гаепләүләр, кимсетелүләр, әрнү-рәнҗүләр ахырда аны соңгы чиккә җиткерә – 1941 елның 26 гыйнварында Камил Мотыйгый үз-үзенә кул сала.

Рүзәл Мөхәммәтша *әзерләде.* ■

Әдәбият

1. Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек: 2 томда: 2 том/ төзүчеләре Рәис Даутов, Равил Рахмани. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2009. – Б.137.

Безнең мирас №8 август 2017

ТАТАР ХӘРБИ РАЗВЕДЧИКЛАРЫ

Рәис Зарипов

«Хәрби разведка энциклопедиясе»ндәге дүртенче татар генералы – генерал-майор М.М.Шәйморатов. Каһарман милләттәшебез турында сүз барганда, нигездә, бар игътибарны аның 112 нче Башкорт кавалерия дивизиясен (1943 елның февраленнән – 16 нчы гвардия кавалерия дивизиясе) оештыруда катнашып, Бөек Ватан сугышында зур батырлыклар кылган кыю командир булуына гына юнәлтү гадәткә кергән. Ә бит Казан түрәләре, олуг тарихчылары һәм галимголәмәсе тарафыннан үгисетелгән татар баласы Миңнегали Шәйморатов хәрби разведчик та әле. Энциклопедиядән күренгәчә, тормышын хәрби хезмәткә багышлаган милләттәшебез, 1920-1921 елларда 9 нчы Казан кавалерия курсларында укый, аннары ике мәртәбә Төньяк Кавказ Хәрби округындагы кавалерия курсларында хәрби белемен камилләштерә. 1931-1934 елларда М.В.Фрунзе исемендәге хәрби академиядә төп факультетның 1 нче курсын һәм Көнчыгыш факультетын тәмамлый. Шул елдан алып, Бөек Ватан сугышы башланганчы – РККА Генштабының Разведка идарәсендә. Хәрби разведчик буларак, Кытайның, башкаласы Урумчи (Өремче) булган Шинҗаң-Уйгыр автоном районында (Көнчыгыш Төркестан) хәрби киңәшче булуы билгеле. Бу җәһәттән, әлеге мөһим фактны Разведка идарәсенең 2 нче бүлегендә отделение башлыгы булып, майор званиесендә хезмәт иткән Миңнегали Шәйморатовның 1938 елның 19 декабрендә үзе язган автобиографиясеннән өзек белән ныгытып кую урынлы булыр: *«СССР саклану халык комиссары боерыгы буенча 1934 елның апреленнән 1937 елның ноябренә чаклы Синьцзянда оператив командировкада булдым»* **(Слава башкирских конников / Авт.-сост. Ф.Н.Вахитов, Н.И.Камалов. – Уфа: Китап, 2005. – С.74.).**

Хәрби разведкага багышлап чыгарылган икенче бер хезмәттә татар милләтеннән булган Шәйморатовның *«1939 елның сентябреннән 1941 елның апреленә кадәр Разведка идарәсе карамагында булуы, апрель аеннан шул ук идарәнең 3 нче бүлегенә караган – 2 нче отделение, һәм 4 нче бүлек башлыклары итеп урләтелүе»* раслана **(Разведка в Великой Отечественной войне / Александр Колпакиди, Александр Север. – М.: Яуза : Эксмо, 2010. – С.573.).**

Кызыгы шунда: әлеге саллы хезмәттә хәрби разведка генералы Миңнегали Шәйморатовның ике Кызыл Байрак (1938, 1941) һәм ике Кызыл Йолдыз (1942, 1943) орденнары белән бүләкләнүе күрсәтелсә, ике елга соңарып дөнья күргән «Энциклопедия военной разведки» китабында милләттәшебезнең 1943 елда Ленин орденына лаек булуы да ташка басылган. Моңарчы безнең карамакта 8 нче кавалерия корпусы составындагы 112 нче кавалерия дивизиясе командиры

Миңнегали Шәймөратов. 1930 нчы еллар

полковник Миңнегали Минһаҗетдин улы Шәймөратовны Ленин орденына тәкъдим итү буенча тутырылган «Бүләкләү документы» гына бар иде. Дөрес, ул турыда 8 нче кавалерия корпусы командиры генерал-майор Алексей Семенович Жадовның (1942 елның 25 ноябренә кадәр – Жидов), полковник Миңнегали Шәймөратовка «генерал-майор» званиесе бирүне сорап язган характеристикасында да мәгълүмат бар: *«Хәрби өлкәдәге уңышлары өчен ул ике Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнгән һәм Ленин орденына тәкъдим ителде <...> «Генерал-майор» званиесе бирүгә лаек»* **(Слава башкирских конников… Күрс. хезм. – С.102.).**

Буталчыклыкларга урын калдырмас өчен генерал Жадовның 8 нче кавалерия корпусы белән 1942 елның май аеннан командалык итә башлавын искәртү мөһим. 5 айдан ул инде – Дон фронты составындагы 66 нчы армия командующие. Күпләр өчен билгеле булмаган кызыклы бер вазгыять. Ноябрь ахырларында Жадовка фронт командующие генерал-лейтенант Константин Константинович Рокоссовский шылтырта һәм Югары Башкомандующий Иосиф Сталинның армиянең уңышлы хәрәкәт итүеннән канәгать калуын, әмма армия белән командалык иткән генералның фамилиясен ошатып бетермәвен белдерә һәм аңа икенче көннән дә калмыйча фамилиясен үзгәртергә куша. Алексей Семенович бик авырлык белән генә күнә һәм Жадов булып йөри башлый. Бу әле мәсьәләнең бер генә ягы, аның икенчесе исә тагы да гыйбрәтлерәк. Варшавада туган Рокоссовскийның әтисе – Ксаверий исемле. Әмма Константин Рокоссовский Гражданнар сугышы вакытында Кызыл Армия ягына чыккач, әтисенең исемен «Константин»га үзгәртә. Бөек Ватан сугышының соңгы ярты елында II Белоруссия фронты белән командалык иткән Советлар Союзы маршалы К.К.Рокоссовский 1945 елның 1 июнендә икенче Алтын Йолдызга лаек була һәм шуннан соң үзенең Великие Луки каласында туганлыгын күрсәтә башлый. Менә шундыйрак хикмәтле хәлләр Миңнегали Шәйморатовны да әйләнеп үтми.

Гомумән, легендар милләттәшебезнең тормыш юлында ачыкланмаган серләр күп булган кебек, хакимият тарафыннан тупас хаталарга юл кую да даими очрап тора. Мисалга, туган авылын буташтыруны гына алыйк. Миңнегали Минһаҗетдин улы XIX гасыр ахырында хәзерге Башкортстанның Кырмыскалы районына керүче Арыслан дигән татар авылында туа. Ләкин нинди дер максатларны күз уңында тотып, аның туган авылы дип күршедәге икенче бер татар авылы – Биштәкә күрсәтелә башлый һәм ул совет чорында хөкүмәт карары белән Шәйморат исемен ала. Бу исә башкорт телчеләрен һәм тарихчыларын Биштәкәдән башкорт авылы «ясау» омтылышларына илһамландырып, очындырып җибәрә. Мифларны һәм әкиятләрне чынбарлык итеп күрсәтү маһирлыгына остарып беткән галимнәр авылда, узган гасырларда ниндидер мифик «яңа башкорт» кавеме яшәгәнлеген «ача». Тик менә филология фәннәре докторы Дөрия Рамазанова язма чыганакларга нигезләнеп раслаганча, документлар киресен күрсәтә: *«Биштәкә (хәзер Шәйморат) авылы Уфа өязе Ногай даругасы вотчинниклары оброкка алган җирдә мишәрләр тарафыннан нигезләнә, припуск 1755 елда язылa. 1811 елдан анда типтәрләр һәм мишәрләр (ләкин сөйләшләре һ.б. яклары белән аерылмыйлар) яши (Башкортстан Үзәк дәүләт архивы, 138 ф., 1 тасв.6, 124 сакл. берәмл. 391.)»* **(Рамазанова Д.Б. Ык елгасы ага чик булып... // Идел. – 1993. – №9. – 65 б.).**

Хәер, Башкортстан шартларында мондый хикмәтле хәлләргә аптырыйсы юк. Мисал итеп, ике тапкыр Советлар Союзы Герое исеменә лаек булган очучы Муса Гәрәев шәхесе тирәсендәге вазгыятьне генә алыйк. Әлегә кадәр бөтен чыганакларда, документларда һәм Википедиядә Муса Гайсә улының Илеш районындагы Иләкшиде авылында туганлыгы күрсәтелә. Чынлыкта ул, узган гасырның 1930 нчы елларында Чакмагыш районыннан Илеш районы составына күчерелгән Ташчишмә авылында туа.

Ә бит Миңнегали Шәйморатов 1938 елда язган автобиографиясендә үзенең «1899 елның 15 августында БАССРның Уфа кантонына керүче Кырмыскалы районы Арыслан авылында крәстиян гаиләсендә туганын» раслый **(Слава башкирских конников... Күрс. хезм. – С.72)**. Ни аяныч, шушы бер җөмлә тагын бер җитди төгәлсезлекне ача. Бу – аның туган көненең ике төрле күрсәтелүе. Хәрби разведка майоры Миңнегали Шәйморатов үзенең туган көне дип 1899 елның 15 августын күрсәтә, ә хәзерге чыганакларга, шул исәптән «Разведка в Великой Отечественной войне» һәм

Миңнегали Шәйморатовка куелган һәйкәл



«Энциклопедия военной разведки» хезмәтләренә нигезләнеп, без аның 1899 елның 17 декабрендә туганлыгына ышанырга тиешбез.

Мәскәү авторлары: *«16 нчы гвардия кавалерия дивизиясе дошман тылында 3 айга сузылган рейдтан соң фронт сызыгын чыкканда, (генерал-майор Шәйморатов. – Р.З.) яу кырында вафат була»*, – дип раслап **(Энциклопедия военной разведки... Күрс. хезм. – С.839.)** тагын бер төгәлсезлек җибәрәләр. Бөек Ватан сугышында шуңа охшаш вакыйга 1942 елда Ржев-Вязьма операциясе вакытында теркәлгән. Генерал-майор Павел Алексеевич Беловның 1 нче гвардия кавалерия корпусы камалышта кала һәм 5 ай буена дошман тылында сугыша. Төгәлсезлек, мөгаен, фамилияләрне буташтырудан килеп чыккандыр: чөнки Шәйморатов һәлак булганнан соң, дивизиягә аның урынбасары полковник Григорий Андреевич Белов командир итеп билгеләнә.

1943 елның 11 февралендә генерал-майор Михаил Дмитриевич Борисовның (1942 елның октябреннән 8 нче кавалерия корпусы командиры) составында 21 нче, 55 нче һәм 112 нче кавалерия дивизияләре булган 8 нче кавалерия корпусы, өстән төшкән Боерыкны үтәү җәһәтеннән фронт линиясен өзеп, дошман тылына үтеп керә. Тагын өч көннән СССР Югары Советы Президиумы Карары белән генерал Борисов II дәрәҗә Суворов ордены белән бүләкләнә, ә Югары Башкомандующий корпус белән өч дивизиягә «гвардия» исемнәре бирү турындагы Боерыкка кул куя. Моннан соң аларның тәртип саннары да үзгәрә: 7 нче гвардия корпусы һәм 14 нче, 15 нче, 16 нчы гвардия кавалерия дивизияләре.

Әлбәттә инде, юньләп әзерләнеп тормыйча башланып киткән һәм 13 көн дәвам иткән рейд чын мәхшәргә әйләнә: хәрбиләр составы буенча нибары 45%ка, атлар буенча 35%ка, артиллерия һәм минометлар буенча 40%ка гына тәэмин ителгән корпус дошман тылында зур югалтуларга юлыга. Рейдка кадәрге бәрелешләрдә танкларының тулысынча юк ителүе аерата зур кыенлыклар тудыра. Чөнки Көньяк-Көнбатыш фронт составындагы 3 нче гвардия армиясе командованиесенең (командующие – генерал-лейтенант Д.Д.Лелюшенко) корпусны көчәйтү өчен зениткалар полкын, танкларны юк итү полкын һәм 399 нчы «катюша»лар гвардия миномет дивизионын бирүдән башка ярдәм итәрлек мөмкинлеге булмый. Әле җитмәсә, ярдәмгә килергә тиешле танк корпусы белән механикалаштырылган корпус дошман оборонасын өзә алмыйлар. Нәтиҗә шул: 23 февраль көнне фронт линиясеннән кире үзебезнең якка чыгу өчен барган авыр сугышлар вакытында аягы яраланган корпус командиры генерал-майор М.Д.Борисов дошман кулына эләгә, аның урынбасары генерал-майор С.И.Дудко, 16 нчы

гвардия кавалерия дивизиясе командиры генерал-майор М.М.Шәйморатов, корпусның сәяси бүлеге башлыгы полковник А.А.Карпушенко, корпусның штаб башлыгы полковник И.Д.Сабуров һәм башка бик күпләр һәлак була. Тик кемнәрнеңдер гаебе белән, Миңнегали Минһаҗетдин улы «хәбәрсез югалучылар» исемлегенә кертелә һәм киләчәктә бу хата каһарман милләттәшебезнең кылган батырлыкларын гадел рәвештә бәяләүдә гаять тискәре роль уйный.

Сугыштан соң Шәйморатовка Алтын Йоддыз бирү буенча омтылышлар нәкъ менә шул гадел булмаган «хәбәрсез югалды» дигән ялгыш штамп аркасында гел каршылыкка очрый да инде. Бу җәһәттән, дошман әсирлегендә хәрби антына хыянәт итмәгән генерал Борисовның 1963 елның 27 гыйнварында ул чактагы СССР Оборона министры Советлар Союзы Маршалы Р.Я.Малиновский исеменә, генерал-майор Миңнегали Шәйморатовка Советлар Союзы Герое исеме бирү кирәклеген нигезләп һәм үтенеп язган Рапорты аерым игътибарга лаек. Рапортның шәхсән Родион Яковлевич кулына эләгүэләкмәве билгесез, мәгәр СССР Оборона министрлыгының кадрлар Идарәсеннән 21 февраль датасы белән җибәрелгән үтә формаль һәм сәер җавап шактый сораулар тудыра. Аннан күренгәнчә, янәсе *«генерал-майор Миңнегали Минһаҗ улы Шәйморатов Бөек Ватан сугышында кылган батырлыклары һәм хезмәтләре өчен 1941 елда – Кызыл Байрак, 1943 елда Кызыл Йолдыз орденнары белән бүләкләнгән. Командование тарафыннан ул башка бүләкләргә һәм Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителмәгән»* **(Слава башкирских конников... Күрс. хезм. – С.115.).**

Ә корпус командиры Жадовның полковник Шәйморатовка генерал-майор званиесе бирү өчен язган характеристикасындагы милләттәшебезнең «ике Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнүе» һәм «Ленин орденына тәкъдим ителүе» турындагы раслауларны кая куясың? Әле бит полковник Миңнегали Шәйморатовны Ленин ордены белән бүләкләргә тәкъдим итеп тутырылган «Бүләкләү документы»н да исәптән чыгарырга ярамый. Анда милләттәшебезнең 1938 һәм 1941 елларда ике Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнүе башкача хаталануларга юл куймаслык итеп, тарих өчен мәңгегә ташка басылып калган. Ул гына да түгел! Документның уң ягында татар каһарманының 1942 елның 18 августында Кызыл Йолдыз орденына лаек булуын да өстәп кулдан язып куйган бер ушлысы. Оборона министрлыгының кадрлар Идарәсендә генерал-майор Борисов соравына җавап язганда шул элементар нәрсәләрне дә ачыклый алмагач, башкалар үтенеченә ни сан?!

Иң зур аңлашылмаучанлыклар генерал Шәйморатовның үлеме белән бәйле хәлләргә барып тоташа. Бөек Ватан сугышыннан соң, генералның хәбәрсез югалмаганлыгын, ә бәлки вафат булуын исбатларга алынган Башкортстан вәкилләре «ачыклаган» бер фаразда, янәсе, яраланып, аңсыз көе әсир төшкән Миңнегали Шәйморатовны шул ук көнне алманнар кылычлар белән чапкалап үтерә һәм коега ташлый, имеш. Тик менә Бөек Ватан сугышында вафат булган яисә әсирлеккә эләккән совет генералларының (шул исәптән Шәйморатовның да) язмышларын, беренче чиратта, Россия Оборона министрлыгының архив материалларына нигезләнеп җентекләп өйрәнгән украин тарихчысы Александр Масловның саллы мәкаләсе 2010 елда «Украинская история» журналында **(№3. – С.30-45)** басыла. Ә инде Александр Алексеевичның генерал Шәйморатовның фаҗигале үлеменә ачыклык керткән мәкаләсе, узган гасыр ахырында инглиз телендәге **«Slavic Vilitary Studies»** журналында дөнья күрә. А.А.Масловның юрамасы буенча, *«генерал Шәйморатов кул сугышы вакытында, авыр яраланып, фашистлар кулына эләгә һәм сорау алган вакытта, гитлерчыларда хезмәттә булган Дон казаклары тарафыннан вәхшиләрчә үтерелә»* **(Зарипов Р.Г.**

Һади Маликов хатыны Рабига белән. 1925 ел

Генерал Власовны кулга алу: фәнни-публицистик очерк. – Казан: Яз, 2014. – 213 б.).

Тагын бер мөһим табыш: Миңнегали Шәйморатов Казан губернасының Тәтеш өязе (хәзерге Татарстанның Кама Тамагы районы) Кече Кариле авылында туып үскән һәм Сталин үткәргән репрессияләр дәһшәтенә эләккән хәрби разведка полковнигы (кайбер хезмәтләрдә – комбриг) Һади Маликов белән яхшы таныш булган. Шул җәһәттән кайбер чыганаклардан өземтәләр: *«...СССРның милли мәнфәгатьләрен яклау өчен, көч операциясе үткәрергә карар кылына. 1933 елның ноябрендә, «Алтай ирекле армиясе» исеменә ышыкланып, чик аша Шинҗаңга гражданнар киемендәге НКВДның 13 нче Алма-Ата полкын кертәләр. Әмма милли хәрәкәтләр белән көрәшү өчен, хәрби чараларны сәяси чаралар белән берләштереп алып бару мөһим. Шул максатлардан чыгып, Шинҗаңга комбриг Маликов җитәкчелегендәге Разведупр (РККА штабының Разведка идарәсе. –* **Р.З.***) вәкилләре төркеме җибәрелә. Төркемгә рус кешесе колагына ят яңгырашлы Фу Дзихуй дигән псевдоним йөртүче, киләчәктә маршал һәм ике мәртәбә Советлар Союзы Герое булачак П.С.Рыбалко, шулай ук В.Т.Обухов, И.Ф.Куц һәм М.М.Шәйморатов кердә. Алар үз алларына куелган бурычны бик шәп итеп башкарып чыгалар»* **(Колпакиди А.И., Прохорв Д.П. Империя ГРУ: Очерки истории российской военной разведки. Кн. 1. – М.: ОЛМА-ПРЕСС, 2001. – С.187-188.).**

«1933 елда кабат тәртипсезлекләр башлана. <...> Шинҗаңның зур өлешен дунгәннәрдән торган 36 нчы дивизия басып ала һәм Шен Шицай ярдәм сорап СССРга мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр була. <...> 1934 елның апрель ахырында совет гаскәрләре, <...> берничә <...> хәрби киңәшче калдырып, Шинҗаңнан чыгарыла. Алар арасында дубанның (наместник, җирле губернатор – Р.З.) өлкән киңәшчесе, танылган разведчик Һади Кәрим улы Маликов белән Фу Дзи-хуй псевдонимын йөртүче <...> Павел Семенович Рыбалко була» **(Паршев А.П., Степаков В.Н. Вторая мировая: когда она началась и когда закончилась? – М.: Яуза: Эксмо, 2009. – С.369-370.).**

Дәвамы бар ■

Безнең мирас №8 август 2017

УТЛЫ КИСӘҮ

Лерон Гыйльфанов

(Истәлекләр, уйланулар)

Үзем инде берничә көн күңел бушлыгында яшим. Хатыным Хәкимә соңгы ике елда бик авырып, берничә тапкыр хастаханәдә ятып чыкты. Әле бер атна элек Түбән Камага китте. Исән йөреп кайтсын инде. Кичә авылдаш дустым, туганым Мөҗәһит тормыш иптәше Бания белән (Бания миңа әти ягыннан туган да әле) безгә кереп, хәлне белеп, якташыбыз – Мөслимдә туып, күп сикәлтәле юллар аша үтеп татар халкының җырчы сандугачы булган Зифа апа Басыйрова турында китап бүләк итте. Зур рәхмәт әйтеп алдым. Алар киткәч, бераз яздым һәм кичке сәгать 9га чаклы шул китапны укыдым. Йокларга ятып, бары 3 кенә сәгать ял иттем. Аннан йокы ачылды.

Хәзер язасы сүзләрем бертуган абыем кебек булган кеше турында. Ул – Әхкыям абый. 1930 елгы. Күп еллар тракторда эшләде, аннан механик булды. Ифрат та кешелекле, үз эшенә бирелгән иптәш иде. Ул чагында тракторларга эш күп. Күп эшләгәч, ватылулар да еш була иде. Әгәр район «Сельхозтехника»сында запас частьлар булмаса, Әхкыям абый күрше районнарга, Башкортостан якларына да чыгып, аларны барыбер табып алып кайта иде. Күп гомере юлда узды. Гаиләсе белән бик тату яшәде. Мин аларда бик еш була идем. Үзе иртәрәк китте шул төп йортка. Пенсиягә чыгып, бер генә ел яшәде. Кичке сәгать 9лар тирәсендә йөрәге туктаган. Табиб килгәндә инде соң булган. Аны җирләргә бик күп кеше килгән иде. Мин дә аңа карата соңгы сүземне әйтеп бәхилләштем...

Язмамны яшәү дәверемдә иң якын кешеләремнең берсе булган Хәлил Михаҗия-

Лерон Гыйльфанов хатыны Хәкимә белән

Ахыры. Башы журналның быелгы 2 нче санында.

нов хакында (әтисе Түреш авылыннан иде) дәвам итәм. Әтисе сугыштан кайткач, Түрештә бухгалтер булып эшләде. Безнең колхоз Карамалыга кушылгач, баш бухгалтер булып бакыйлыкка күчкәнче хезмәт куйды. Сүзем аның улы турында. Хәлил үзе унынчы классны бетерү белән армиягә киткәнче гусеницалы тракторда эшләде. Армиядән кайткач, төрле тракторлар йөртте. Бүген дә фермада трактор белән маллар туйдыра. Хәлилнең матур, җитеш гаиләсе бар. Тормыш иптәше Глүзә белән өч малай үстерделәр.

Бу тормыш кызык шул. Җир шары яралганнан бирле, җирдә кешеләр ник шулай бер-берсен хөрмәт итеп яшәми икән, дип уйлап куям. Нигә күпләрнең бәхете юк? Аерым берәүләр: ярый, пенсияне генә бетермәсеннәр, дип әйтә. Өстәге олы түрәләр кем булса да ярый, диләр. Бу дөрес түгел. Аның белән генә син бәхетле була алмыйсың.

Бәхет сүзе күп мәгънәгә ия. Ашарга булып, саулыгың булмаса, бу бәхетме? Сәламәт булып та, торыр җирең булмаса, бу бәхетме? Йортың булып, туганың яки балаң аракы эчүче яки наркоман булса, бу бәхетме? Язып китсәң, очына чыкмаслык сораулар...

Иске Карамалы колхозында агроном булып Гыйният агай эшләде. Аларның өе почта янында, улы Мирхаҗиян, урта мәктәптә укытучы булып эшләп, хәзер лаеклы ялга чыкты, исән-сау. Аның хатыны Роза озак еллар Карамалыда почта җитәкчесе булып эшләде. Хәзер пенсиядә. Икесе дә үз эшләрен төгәл итеп башкарды. Ә Гыйният агай ничә ел эшләгәндер – әйтә алмыйм. Шунысын беләм: бик таләпчән булды, булсынга эшләтте. Әле аның югары белеме дә юк иде шикелле. Ә бит хезмәткә караш синең белемең күпме булуда гына түгел.

Авылдашым Фәүзел агай Исламов Карамалыда, ферма як урамда Нурлыһода апа белән гаилә корып яшәде. Нурлыһода апа гомер буе хастаханәдә эшләде. Фәүзел абыйларның үскән йортлары безнең рәттә, безгә дүрт өй аша гына иде. Хәзер ул планга икенче кеше йорт салды. Кырында гына авылыбызда казылган кое – сугышка хәтле казылган – бетон «кольцо» утырттылар, башка кое юк. Ә моның суы коры елны да бетми. Сүземә кайтып, Фәүзел агай ничәдер елдан «Октябрь» колхозына күчеп, пенсиягә хәтле яхшы гына эшләде. Пенсиягә чыгып, озак яшәмәде, бакыйлыкка күчте. Төп йортта улы Расих гаиләсе белән яши. Балалары бар. Фәүзел агай безнең белән эшләгәндә үзен яхшы яктан күрсәтте. Кешелекле иде, тавыш күтәрмәде.

Фәүзел агайдан соң баш агроном булып Казанда югары белем алган Сөякәй авылы егете Назиф Нурлыгаянов эшләде. Ул шактый еллар хезмәт куйды. Гаиләле, балалары бар. Тормыш иптәше «Алга» ПМКсында бухгалтериядә эшләде. Яңадан бик каты авырып, терелә алмыйча, Назифны һәм балаларын калдырып, төп йортка китте. Балалары үскәч, Назиф Мөслимгә күчте.

Минем үземә чын алга карап эшләүче икенче иптәш һәм җитәкче колхоз председателе Наил Касыймов булды. Аның турында алда бер язып узган идем инде. Бу иптәшне мин «җир академигы» дияр идем. Йә булмаса, «җир профессоры», яисә «докторы», дип. Гомеремдә аның кебек киң карашлы кешене очратмадым. Мактавым да, хурлавым да түгел. Чын җир кешесе иде. Җирне яратты, хөрмәт итте. Җирдән ничек итеп яхшы уңыш алып була – менә аның максаты. Берничә мисал китерәм. Безнең колхозда, ялгышмасам, 4 ел председатель булып эшләде. Безгә килгәнче, Уразмәт колхозында баш агроном иде. Үзе Буләк авылыннан. Өйләнгән, балалары бар. Тормыш иптәше укытучы иде, Бүләктә укытты. Наил абый йөрер өчен колхоз техникасы юк иде. Ул чорда колхоз җитәкчеләренең түгел, район хуҗаларының да техникасы санаулы иде. Наил абыйның Уразмәттә алынган «Иж» мотоциклы бар иде. Менә шул булды аның машинасы. Ә без басуда (чәчүдә-культидә) һәм көзге сөрүдә эшләгәндә, шушы эшкәрткән җирләрне көн саен диярлек, комиссия кебек,

«матай» белән әйләнеп чыгар иде. Төннәрен дә еш йөрде. Кайчан ял иткәндер ул – гаҗәпләнә идем мин аның җиргә карашына.

Бер мисал. Зәп җире сөргәндә, ул килгәч, тракторны туктатасың һәм шунда Наил абый үзенең чын «профессор» белемен берничә минут эчендә күрсәтә: сиңа аңлатып бирә. Ошамаган урыны булса, ачуланмый, бары тик «монысы болай, монысы тегеләй» дип яхшылап аңлата. Күп очракта районнан биргән күрсәтмәдә, 25-30 см яки 30-35 см тирәсе булсын, диелә. Ә Наил абыйның «үз см»ы иде. Мин әлек тә аның фикере белән килешә идем, хәзер дә шул уйда. Наил абый әйтә иде: әйтик, менә 100-150-200 га басу. Җирнең кызыл балчыктан өске өлеше баягы 30 см. Әрлән балчык чыга башласа, шул җитә, сөргәндә туктап-туктап карарга кирәк, кызыл балчыгын чыгармагыз, дия иде. Наил абый ни өчен шулай әйтә иде? Чөнки җирнең өске катламы бар җирдә дә бертөсле түгел. Безнең Түрештә Өске урман буенча 30 см сөреп булмый, өстәге уңдырышлы туфрак юка. Әйтик, Яңа Карамалыда, Коммуна белән ике арада ничә га икәнен әйтә алмыйм, 20 см лар тирәнлектә вак чуар щебенка таш чыга. Монда минем сөргәндә күп тапкыр сабан төрәне башын сындырганым бар. Менә сөр 30 см га. Мин үзем, сөрү эшләре беткәч, тракторга погрузчик көйли идем. Менә шул ташлы басудан Яңа Карамалы юлына, Түреш буасы юлына, мал фермалары янына юл итеп йөрергә төяп тора идем. Әле андый ташлар хәзер дә бардыр. Ә Наил абый килгәнче үк Хезмәт Кызыл Байрагы ордены алган иде инде. Ул чорда андый зур бүләкне тагын кем генә алгандыр? Хәзер мәрхүм инде Наил абый. Урыны оҗмахта булсын!

2017

«УТЛЫ КИСӘҮ» АВТОРЫ ЛЕРОН ГЫЙЛЬФАНОВ ТУРЫНДА БЕРНИЧӘ СҮЗ

Лерон абыйның гаилә тормышы җиңелдән булмаган. Алар хатыны Шәргыя белән ике ел чамасы гына яшәп аерылыша. Булачак язучы Ләбиб Лерон әнисенең туган авылы Олы Имәндә (Актаныш районы) үсә. Шуннан соң Лерон абый, гаилә кормыйча, өч дистә елга якын ялгыз яши. Аерылышу тетрәнүеннән аны эшгамәлләрендә авыл кешеләре белән бердәмлек, уйларында ил белән, дөнья белән яшәү һәм аракы дигән зәхмәттән ерак тору коткара.

Ниһаять, аңа да бәхет елмая. Түбән Кама шәһәрендә гомер иткән авылдашы, ике бала анасы Хәкимә Түрешкә кайтып йөри башлый, ахырда, өй сатып алып төпләнә. Аңа күз атып, үзара сөйләшеп йөргән Лерон абый уртак тормыш корырга тәкъдим ясый.

1992 елның августында алар бергә яши башлый. Йортка ямь керә, шатлык иңә.

Хәкимә – Харрас Әюповның бертуган апасы. Гаиләсе белән Харрас та, Ләбибләр дә, Хәкимәнең балалары, оныклары, туганнары да бу нигезгә яратып кайта. Лерон абый белән Хәкимә аларны һәрчак ачык йөз, сый-хөрмәт белән каршылады, һәр ике якны икесе дә тигез күрде. Алар бергә кушылгач, безне дә магнит кебек тартып китерә, җыйный торган булды. Лерон абый белән ныклап аралашу шулай башланды. Без, аерылмас дусларга әверелеп, үткән тормышыбыз, авыл язмышы турында озаклап сөйләшсәк тә, аның турында очерк язарга дигән ниятемне тормышка ашыра алмадым. Аның каравы, тракторчыны баш герой итеп алган ике повесть («Шаһзаманов эше», «Көлми торган кеше»), бер зур хикәя («Авыш басу икмәге») һәм «Иртәгә нидер булачак» дигән драма яздым. Ул геройларда Лерон Гыйльфановның күп кенә сыйфатлары чагыла, әлбәттә.

Фоат Садриев,
Татарстанның халык язучысы

Безнең мирас №8 август 2017

Лерон Гыйльфанов
улы Ләбиб Лерон белән

***

Әтием Лерон электән үк каләм тибрәткәли иде. Аның мәгълүмати рухтагы хәбәр-язмалары Мөслим районы газетасында үз вакытында күренгәләп барды. Шулай булуга карамастан, әти «Утлы кисәү» дигән күләмле әсәр язар дип һич башыма китермәдем. Дөресен әйтим, соңгы вакытларда сырхаулап, ашказаны авыртуыннан зарланыштырып алган сиксән ике яшьлек әтидән мин моны көтмәгән идем. Аның бу язганнары турында иң әүвәл үзеннән түгел, ә дусты, чордашы, замандашы, күренекле язучы Фоат абый Садриевтан ишетеп белдем. Ни дип әйтим, булдыргансың, әти! Минем синең турыда, синең кичерешләрең хакында ни уйлаганны, синең эчке дөньяңны Фоат абый Садриев «Утлы кисәү»гә язган кереш сүзендә бик төгәл әйтеп бирде: *«Лерон абый социалистик системаның яшәүчәнлегенә, киләчәктә зур уңышларга ирешәчәгенә инанган иде. Ул үзен шул уңышларны тизләтергә тиешле кеше, гаделлек өчен көрәшче, тормышның хуҗасы итеп тойды. СССРны таркатып, океан кебек илебезнең җир өсте һәм җир асты байлыкларын ул байлыкларда дәхеле булмаган затларның әләктереп алуын, колхоз-совхозларның таркатылуын ул шәхси фаҗига итеп кабул итте. Бүген дә бәгыре телгәләнүдән тынычлана алмый...»*

«Утлы кисәү» тәмам. Әмма әти, күңел төпкелендә яткан хәл-вакыйгаларны кузгатып, гомер юлында очраган кайбер кешеләрне исенә төшереп, соңгы вакыттагы уйлануларын теркәп, көндәлек рәвешендә янә берникадәр хатирә язды. Алла теләсә, ул язма да басмабызда озакламый дөнья күрер әле.

1 августта сиксән өч яшен тутырган әтием Леронның бүген игелек иясе Хәкимә апа белән тыйнак кына гомер итеп яткан чаклары. Баксаң, аларның бергә кавышып яши башлауларына да быел августта 25 ел тула икән. Кем әйтмешли, көмеш туйларыгыз мөбарәк, күңелләрегез һәрвакыт түгәрәк, тормышыгыз җитешле булсын! Ходай сезне сәламәтлектән аермасын. Балаларыгызның, оныкларыгызның игелеген күреп, озын-озак яшәргә язсын үзегезгә!

Ләбиб Лерон ■

Безнең мирас №8 август 2017

АМЕРИКА ГАЛИМЕ ҺӘМ ТАТАР ГАРМУНЫ

Эльмира Каюмова

2015 нче елның 17 ноябрендә Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясендә бик үзенчәлекле кандидатлык диссертациясе якланды. Тарихта беренче тапкыр татар гармунына багышланган фәнни эш тәкъдим ителде («Казан татарларының традицион мәдәниятендә гармун»). Вакыйганың мөһимлеге шулай ук авторның нинди шәхес булуына да бәйле. Пол Уолтер Куйвинен – төп Америка кешесе, нәселендә фин тамырлары бар.

Гармун татар халык мәдәниятенә XIX гасырның икенче яртысында килеп керә һәм чын милли уен коралына әверелә. Аның килеп чыгышы – шактый катлаулы мәсьәлә. Бер яктан, ул

XIX гасырның башында Германиядә барлыкка килгән, дигән караш киң таралган. Шулай ук, гармунның Рәсәйдә тууы да мөмкин. Ә төп сыйфатларны (элементларны) алганда, тарихы бик ерак заманнарга барып тоташа. Мәсәлән, авыз гармунының иң беренче мисалы итеп Кытайдагы «шэн» музыка коралы санала (б.э. кадәр III меңъеллык).

Гармун төзелешенә үзгәртүләр кертеп, татарлар аны милли музыкаларына (ягъни бертавышлы пентатоник көйләренә) яраклаштырып кулланганнар. Тальян, хромка, саратов гармуны (әстерхан татарлары аны «саз» дип атый) аеруча популяр булган. Берничә җирле исемнәр дә мәгълүм: тальян, венски, вараксин, рус (яисә русски) һ.б.

Хәзерге вакытта гармунда уйнау традициясе сүнеп барса да, башкаручылар әле шактый. Әлеге музыка коралы бик таралган булгангамы, үзебезнең белгечләр аңа әллә ни игътибар итмәгәннәр.

Америкадан килгән Пол Куйвинен, татар телен махсус өйрәнеп, Арча, Әтнә, Балтач һәм Биектау районнарына экспедицияләргә чыгып йөргән. Үзе җыеп алган материал белән бергә «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясендә һәм Венгрия Фәннәр академиясендә сакланган архив язмаларын да кулланган. Барлыгы 88 башкаручыдан 656 инструменталь үрнәк тикшерелгән. Халык гармуннарының 7 төрен ачыклап, аларны үзләштерергә дә өлгергән. Өстәвенә П.Куйвинен көйләрне нотага төшерү һәм уйнарга өйрәтү юнәлешләрендә яңа ысуллар уйлап тапкан.

Бу диссертация белән миңа якыннан танышырга насыйп булды. Рәсми оппонентларның берсе буларак, аның эчтәлеген җентекләп өйрәндем һәм югары бәя бирдем. Чынлап та, «Казан татарларының традицион мәдәниятендә гармун» – саллы, җитди хезмәт. Ул – күп еллар дәвамында (ун еллап чамасы) алып барган эзләнүләр, уйланулар нәтиҗәсе. Татар гармуны Америка галиме тарафыннан төрле яклап, тәфсилләп тикшерелгән. Язу стиле дә үзенең логикасы, төгәллеге, фактларга таянуы белән аерылып тора. Андый хезмәтнең барлыкка килүе татар мәдәнияте һәм, гомумән, фольклор фәне өчен искиткеч зур вакыйга!

Автор ерак илдә туып үсеп, бөтенләй башка мохиттә тәрбияләнсә дә, аның карашларында Көнбатыш цивилизациясен өстен итеп күрү сизелми. Киресенчә,

П.Куйвинен диссертацияне яклауда.

Пол Куйвиненның диссертациясе һәм авторефераты

безнең сәнгатькә соклану, үзенчәлеген тулы канлы итеп раслау, Көнбатыш музыкаль мәдәниятенең киң колач җәю аркасында югалып баруы, аның киләчәге турында борчылу чагыла.

Пол Куйвиненның Татарстанга килеп, иң беренче нәүбәттә татар телен өйрәнүгә керешүе – үзе бер күрсәткеч. Югыйсә, тәрҗемәче белән дә фәнни сәяхәткә чыгарга мөмкин иде. Әмма галим җиңел юлдан бармады, гармунчылар белән турыдан-туры ана телебездә сөйләште, чөнки халык традициясен тирәнтен белүне максат итеп куйды. Пол белән очрашкан вакытта да мин аның белән фәкать татарча гына аралаштым.

Э.Каюмова һәм Сәгыйть Хәбибуллин фотолары ■

Безнең мирас №8 август 2017

МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

Адлер Тимергалин



ТӘФСИР *г.* — Аңлатма, мәгънә, комментарий, ачыклама, трактовка, экзегеза. *Тәфсир әл-Коръән*—Коръәннең фәлсәфи аңлатмасы, Коръән тәфсире. Шулай ук *Һәфтияк тәфсире* дигән төшенчә дә бар. *Гыйльме тәфсир* төшенчәсен исә *герменевтика* төшенчәсе колачлый (күп мәгънәле һәм аныклауга бирелми торган борынгы текстларны аңлату ысуллары һәм традицияләре).

Комментарийлар берничә сүздән алып Коръәннең бөтен текстын (җөмлә артыннан җөмләне һәм хәтта сүз артыннан сүзне) тулысынча аңлату рәвешендә булырга мөмкин. Тәфсирнең бер төре *(тавил)* Коръәннең эчтәлегенә генә кагыла: төрле «мәктәпләр» (суфилар, шигыйлар) Коръән кәшифләрен үз карашларына яраклаштырырга тырыша (Ив Тораваль, «Мусульманская цивилизация»).

XX гасыр башларында татар дөньясында Коръән тәфсире ясау белән шөгыльләнүчеләр күбәйгәч, Нәҗип Думави борчылып язган сүзләр игътибарга лаек: «Коръән яза такмакчы, Тәфсир ясый касабчы. Казылык белән сатмакчы, — Ахыр заман тидия!»

//Саба җил гөл исен җәйде — язды, «гашыйк» сүзенә бер тәфсирме язды?
Котб. *Тәфсире хәдис* — хәдисләр тәфсире. *Тәфсир кылу, тәфсирләү*.

Тәфсирнең күплек саны шәкеле — *тәфасир*. ■

Дәвамы. 2014 елның 3 нче саныннан басылып килә.

2017 ЕЛДА ДИНИ БӘЙРӘМНӘР ҺӘМ ИСТӘЛЕКЛЕ КӨННӘР *

31 август – Гарәфә көне.

Мөбарәк вә фазыйләтле 10 кичәнең ахыргы кичәсе.

Гарәфә кыяме яки хаҗиларның Гарәфә тавы тирә-юнендә торып гамәл-гыйбадәт башкару көне. Һәр фарыз намаздан соң Тәшрикъ тәкбирләре әйтеләчәк, иншәАллаһ.

1 сентябрь – Мөбарәк Гыйд әл-Әзъхә яки Корбан гаете.

Җөмлә әһле Исламга мөбарәк, Гает корбанлыклары кабул булсын! Һәр фарыз намаздан соң Тәшрикъ тәкбирләре әйтеләчәк, иншәАллаһ. 2, 3, 4 сентябрь – Тәшрикъ көннәре.

21 сентябрь – Һиҗри Яңа ел. 1439 Һиҗри елның вә Мөхәррәм әл-Хәрам аеның беренче көне.

Яңа елыбызда дөнья вә ахыйрәт бәхет-сәгадәтенә алып бара, Аллаһы Тәгаләнең ризалыгына ирештерә торган гамәлләр кылырга насыйп булсын! Бу көнне Аллаһының ризалыгы өчен догалар, изге эш-гамәлләр кылып, хәер-садака биреп үткәрергә кирәк.

30 сентябрь – мөбарәк Гашура кичәсе көне. Мөхәррәм әл-Хәрам аеның 10 нчы көнендә Гашура бәйрәме билгеләп үтелә. Бу көннең фазыйләтләре һәм хикмәтләре бихисап. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) болай дигән: «Ибраһим галәйһис-сәлам Гашура көнендә тугандыр. Аллаһы Тәгалә аны Нәмрудның утыннан Гашура көнне коткаргандыр, юлның тугрысын да Гашура көнендә күрсәткәндер».

21 октябрь – һиҗри тәкъвим буенча елның икенче ае яки Сәфәр әл-Хәер ае башлана. Изге вә бәрәкәтле ай булуын Аллаһы Тәгалә насыйп итсен!

30 ноябрь – Мәүлед-шәриф кичәсе

1 декабрь – Мәүлед бәйрәме – пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) туган көн. Ул мөселман дөньясында зурлап билгеләп үтелә.

Төзүче-мөхәррир –
хаҗи ***Абдулла Дубин****.*

Ахыры. Башы журналының 2017 елгы 2 нче санында.

ЯДКӘРЛӘРГӘ – БЕР ГАСЫР

Татарстан Республикасы Дәүләт архивы фондыннан

1917 елның 6 августы

«РАБОЧИЙ ГАЗЕТАСЫНДА БАСЫЛГАН ХРОНИКА

Безгә Посадская урамындагы 35 нче икмәк сату лавкасында һәртөрле тәртипсезлекләр кылынуы турындагы хәбәрләр килеп иреште. Лавканың приказчигы В., бик тупас кеше сатып алучыларга карата күп кенә ярамаган гамәлләр кыла. Еш эчә, исерек һәм 16 июльдә бөтенләй эшкә килми. Чиратта торган халык төркеменең моңа бик нык ачуы чыга һәм милициянең ярдәме белән үз араларыннан кешеләр сайлап, алар ипи сата башлыйлар. Моңа игътибар бирү зыян итмәс иде.

ТР ҮДА ТСД, газеталар тупланмасы, №366а.

1917 елның 15 августы

КАЗАН ХӘРБИ ОКРУГЫ ГАСКӘРЛӘРЕНЕҢ ВАКЫТЛЫ КОМАНДУЮЩИЕ, ГЕНЕРАЛЬ ШТАБ ПОЛКОВНИГЫ КАРАУЛОВ КАРАРЫННАН



ОБЯЗАТЕЛЬНОЕ ПОСТАНОВЛЕНІЕ

ПО ГОРОДУ КАЗАНИ И ПРИЛЕГАЮЩИМЪ КЪ НЕМУ СЛОБОДАМЪ, СОСТОЯЩИХЪ НА ВОЕННОМЪ ПОЛОЖЕНІИ

15-го августа 1917 года.

Вслѣдствіе исключительныхъ обстоятельствъ, создавшихся пожаромъ въ Казанскомъ пороховомъ заводѣ, на основаніи п. 2 приложенія къ статьѣ 23 тома 2 Св. Зак., я объявилъ городъ Казань и прилегающія къ нему слободы на военномъ положеніи.

А потому, для поддержанія общественнаго порядка и спокойствія, для безпрепятственнаго труда обывателей отъ покушенія и нападенія преступныхъ злодѣевъ объявляю во всеобщее свѣдѣніе слѣдующее:

1) Въ силу сего положенія мнѣ представляется право воспретить отдѣльнымъ лицамъ пребываніе въ мѣстностяхъ, объявленныхъ на военномъ положеніи, и высылать отдѣльныхъ лицъ во внутреннія губерніи государства для учрежденія за ними надзора милиціи на время продолженія военнаго положенія, а иностранцевъ высылать и заграницу. Мѣра эта можетъ быть примѣнена ко всѣмъ лицамъ, не смотря на чинъ и званіе и къ какому бы вѣдомству и сословію они не принадлежали.

2) Не принадлежащія къ арміи лица гражданскаго вѣдомства въ мѣстностяхъ, объявленныхъ на военномъ положеніи, подлежатъ военному суду и наказанію по закону военнаго времени какъ за преступленія, предусмотрѣнныя ст.ст. 17 и 20 (прил. къ ст. 23 т. II Св. Зак.), такъ и ст. 279 Воин. Уст. о наказ.—за умышленное убійство, разбой, грабежъ и умышленное зажиганіе или потопленіе чужого имущества.

3) Кромѣ того, въ силу 6 п. ст. 19 прил. 1 къ ст. 23 т. II Св. Зак. мнѣ предоставлено право передавать для сужденія военнымъ судомъ всѣ вообще дѣла, предусмотрѣнныя общеуголовными законами, по моему усмотрѣнію.

Настоящимъ постановленіемъ:

1) **Воспрещается** всякаго рода собранія и митинги.

2) **Воспрещается** распространеніе въ предѣлахъ города Казани и слободъ всякихъ прокламацій, воззваній, листовъ, брошюръ и телеграммъ, возбуждающихъ къ забастовкамъ, насиліямъ и всякаго рода волненіямъ.

3) **Воспрещается** распространеніе ложныхъ слуховъ, возбуждающихъ въ населеніи тревогу или же опасеніе за личную ихъ имущественную безопасность.

4) **Воспрещается** всякій сборъ денегъ и пожертвованій.

5) **Воспрещается** постороннимъ лицамъ входить въ казармы и вообще въ помѣщенія, занятыя войсковыми командами.

6) **Воспрещается** учиненіе препятствій къ вывѣшиванію объявленій, изданныхъ законной властью, срываніе и порча таковыхъ, уничтоженіе обязательныхъ постановленій и другихъ распоряженій начальствующихъ.

7) **Воспрещается** расклеивать объявленія, воззванія и прочее безъ разрѣшенія милиціи.

8) **Воспрещается** всякое вмѣшательство въ дѣйствія и распоряженія чиновъ милиціи и войскъ охраны, при исполненіи ими обязанностей, а также неоказаніе имъ содѣйствія при исполненіи ими обязанностей по предупрежденію и пресѣченію преступленій.

Вмѣстѣ съ симъ нахожу необходимымъ обратить къ административному разрѣшенію дѣла о слѣдующихъ проступкахъ, предусмотрѣнныхъ Уставомъ о наказаніяхъ налагаемыхъ мировыми судьями:

1) Неисполненіе законныхъ распоряженій, требованій или постановленій правительственныхъ властей (ст. 29 Уст. о Нак. нал. мир. суд.).

2) Ослушаніе милиціи (ст. 30)

3) Оскорбленіе милиціи при отправленіи ими должности (ст. 31).

4) Порча или истребленіе выставленныхъ по распоряженію законныхъ властей объявленій (ст. 38).

5) Распространеніе ложныхъ слуховъ (ст. 37).

6) Нарушеніе общественной тишины (ст. 38).

7) Нарушеніе порядка въ публичныхъ собраніяхъ (ст. 39).

8) Необъявленіе милиціи въ срокъ о прибывшихъ въ домъ и выбывшихъ (ст. 59).

9) Укрывательство лицъ, присужденныхъ къ аресту или къ заключенію въ тюрьмѣ (ст. 64).

10) Неосторожное поврежденіе принадлежностей телеграфовъ (ст. 101).

11) Храненіе или ношеніе запрещеннаго оружія и стрѣльба (ст.ст. 117, 118).

12) Пріемъ въ закладъ отъ солдатъ казеннаго оружія, казеннаго платья или аммуничныхъ вещей (ст. 180 ч. 1).

Виновные въ нарушеніи сего обязательнаго постановленія мною будутъ подвергаться въ административномъ порядкѣ тюремному заключенію до 3 мѣсяцевъ или денежнымъ штрафамъ до 3 тысячъ рублей.

Вр. командующій войсками Казанскаго Военнаго округа, генеральнаго штаба полковникъ *Карауловъ*.

Типо-литографія Окружнаго Штаба.

Казан дары заводындагы янгын тудырган гадәттән тыш шартлар сәбәпле... мин Казан шәһәрендә һәм аңа тоташкан бистәләрдә хәрби хәл игълан иттем...

Бу карар белән:

1) Һәртөрле җыелышлар һәм митинглар тыела.

2) Казан шәһәрендә һәм бистәләрдә забастовкаларга, көч куллануга һәм һәртөрле чуалышларга чакырган төрле прокламацияләр, өндәмәләр, кәгазьләр, брошюралар һәм телеграммалар тарату тыла.

Документлар урыс теленнән тәрҗемә ителеп бирелә.

Безнең мирас №8 август 2017

3) Халыкта шомлану яки шәхси тормышлары һәм милекләре өчен курку тудырган ялган хәбәрләр тарату тыела.

4) һәртөрле акча һәм иганә җыю тыела.

Бу мәҗбүри карарны бозучылар минем тарафтан административ тәртиптә 3 айга кадәр төрмәгә ябылачак яки аларга 34 мең сумга кадәр штраф салыначак.

ТР ҮДА ТСД, ф.1246, тас.1, э.139,5б.

1917 елның 25 августы

«САБАХ» ҖӘМГЫЯТЕ НӘШРИЯТЫ ҺӘМ ЯЗУ-СЫЗУ ӘЙБЕРЛӘРЕ КИБЕТЕНЕҢ ЧИСТАЙ ӨЯЗ ЗЕМСТВО УПРАВАСЫНА ХАТЫ

Безгә билгеле булганча, Сез безнең империянең надан халкы арасында белем таратуга бүгенге көнгә кадәр бөтен көчегезне куеп килдегез һәм, билгеле, бу күркәм максатыгызга күп энергия тотып һәм авыр сынаулар аша ирешелә. Хәерхаһлы карашыгызның Россия мөселманнарын да читләтеп үтмичә, алар арасында туган телләрендә һәркемгә аңлаешлы файдалы китаплар таратуыгыз бигрәк тә сөендерә. Әмма бу өлкәдә эш алып бару Сезнең өчен бик авыр булуын истә тотып һәм Сезгә бу мәсьәләне җиңеләйтергә теләп, күп кенә земстволарны тәэмин итеп торучы буларак, һәркемгә дә аңлаешлы һәм әдәби, һәм фәнни эчтәлекле файдалы китапларны Сез ачкан башлангыч мәктәпләр һәм китапханәләргә җибәреп торырга тәкъдим итүне үзебез өчен дәрәҗә саныйбыз. Шулай ук дәреслекләр һәм уку ярдәмлекләрен иң файдалы шартларда зур сайлап алу мөмкинлеге дә бар.



326

Книгоиздательство
— и —
писчебумажный
магазинъ
Т-ва „САБАХЪ"
Электро-Типо-Литографія
подъ фирмою
„УМИДЪ"
Переплетная мастерская
производство
конторскихъ книгъ
А.-В. Ахмадуллина и Ко
въ Казани.
Отдѣленіе въ Уфѣ.
Телефонъ № 10-12.

Казань, Августа 21 дня 191_ г.

34

Въ ... Земскую Управу.

М. Г.!

Какъ намъ извѣстно, Вы прилагали до сего времени всѣ усилія къ распространенію знаній среди темнаго населенія нашей Имперіи, и, конечно, эта благородная цѣль Ваша достигается съ большой затратой энергіи и при тяжелыхъ испытаніяхъ. Это явленіе тѣмъ болѣе отрадно, что Вы не преминули своимъ благосклоннымъ взоромъ и россійскихъ мусульманъ, распространяя среди нихъ полезныя общедоступныя книги на родномъ языкѣ. Но имѣя въ виду, что работа на этомъ поприщѣ для Васъ очень тяжела, и, желая облегчить Вамъ эту трудную задачу, имѣемъ честь предложить свои услуги, какъ поставщики многихъ Земствъ, по поставкѣ полезныхъ общедоступныхъ книгъ для открываемыхъ Вами начальныхъ школъ и библіотекъ, какъ литературнаго, такъ и научнаго содержанія, а также большой выборъ учебниковъ и пособій, на самыхъ выгодныхъ условіяхъ.

При семъ прилагаемъ списокъ учебниковъ и пособій, принятыхъ повсемѣстно въ начальныхъ школахъ и одобренныхъ педагогами.

Въ ожиданіи Вашего заказа
съ совершеннымъ почтеніемъ:

Бөтен җирдәге башлангыч мәктәпләрдә кабул ителгән һәм педагоглар тарафыннан хупланган дәреслекләр һәм уку ярдәмлекләре исемлеген куябыз.

Сезнең заказыгызны көтеп,
тирән ихтирам белән:
имза

ТР ҮДА ТСД, ф.36, тас.1, э.147, 32 б.

Документларны басмага ТР Дәүләт архивы секторы мөдире ***Римма Садыйкова*** *әзерләде.* ■

E-mail: prm.archive@tatar.ru
www.arhiv.tatarstan.ru

ИСКЕ МӘҢГӘР

Иске Мәңгәр авылы, Әтнә районында, Олы Әтнә авылыннан 6 км көнчыгыштарак, Симет елгасы буенда урнашкан. 2008 елда 251 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле – игенчелек, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, мәчет бар. Бу авыл Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 18 йөз – 19 йөзнең 1 нче яртысыннан халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, киндер сугу белән шөгыльләнә. 20 йөз башында Иске Мәңгәрдә мәчет, мәктәп, 2 су тегермәне, «китайка» тукымасы җитештерү фабрикасы эшли. Бу

Безнең мирас №8 август 2017

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәисе Фәрит Хәйрулла улы Мөхәммәтшин авыл аксакалына киңәшләрен бирә

чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1050,4 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Казан өязе Олы Әтнә волостена, 1920 елдан ТАССРның Арча кантонына керә. 1930 елның 10 августыннан – Тукай, 1938нең 25 мартыннан – Әтнә, 1959 елның 12 октябреннән – Тукай, 1963нең 1 февраленнән – Арча, 1990ның 25 октябреннән Әтнә районына карый. Халык саны: 1782 елда – 66 ир-ат; 1859да – 521, 1897дә – 641, 1908дә – 749, 1920дә – 568, 1926да – 649, 1938дә – 645, 1949да – 453, 1958дә – 325, 1970тә – 328, 1979да – 290, 1989да – 241, 2002дә – 259 кеше.

Иске Мәңгәр авылы белән янәшәдә борынгы татар зираты бар. Анда гарәп язулы урта гасыр кабер ташларын күрергә мөмкин. 2015 елда бу зиратның биләмәсе генераль директоры Лотфулла Нурислам улы Шәфигуллин җитәкчелегендәге «Таттелеком» ААҖ һәм башка иганәчеләр көче белән төзекләндерелде. ■

Лотфулла Нурислам улы Шәфигуллин (сулдан беренче)

«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1917 елның август ае

Сәхифәне басмага Ленар Гобәйдуллин әзерләде.

Олуг һәлакәт

14 август, көндез Казанның Пороховой бистәсе якынындагы порох һәм туп төялгән йирләрдә ут чыгып, берәр сәгать үтәр-үтмәс порох һәм туплар шартлау белән, янгын тәмам бер җәһәннәм хәленә килгән. Сәгать 3-4 тирәсендә бөтен шәһәр урамы бер гарасат мәйданына әйләнде. Бөтен халык шәһәрнең тышына таба йөгерергә тотынды. Урамдагы тыгызлык вә тәртипсезлектән аналар – балаларын, балалар ата-аналарын югалттылар. Шәһәр өстен бер еглаш, сыхташ каплап алды.

Пороховой заводта эшли торган эшчеләрдән һәлак булганнар арасында мөселманнар да күп булыр, дип уйлана. Пороховой һәм Бишбалта бистләләрендә бик зур зарар күргән йортлар арасында мөселманнарныкы да бик күп.

Мәдрәсәи «Мәрҗания» идарәсеннән

Бу ел Мәхкәмәи шәргыя хозурында булган голәмә вә мөдәррисләр һәйәте тарафыннан вә Казанда булып үткән беренче голәмә нәдвәсе [съезды] тарафыннан кабул кылынмыш программа буенча, мәдрәсәи «Мәрҗания»не урта мәктәпләр челтәренә кертеп ачарга карар бирелде һәм кирәк кадәр мөгаллимнәр дә әзерләнде. Әстерхани Габдерахман хәзрәт Гомәровны да дәрес әйтү өчен дәгъвәт ителде. Шәкертләр, һич кичекмичә, сентябрь 21 еннән башлап кабул ителә башланадыр.

Кояш. – 1917. – № 1152. – 18 август.

Зур һәлакәттән

Һәлакәт Казан әтрафының һичбер йирен өлешсез калдырмаган булса да, Казанның уртасында булганда күбесенчә ватылып, чыпта яки такта кадакланган тәрәзәләрдән, җимерелгән ишек, каерылган вывескалардан гына белеп була. Ничек Пороховойга таба юнәлдек, барган саен, күз алларын капларлык һәлакәтләрнең дәһшәтен күрәсең. Бишбалтага җиткәч, төрле җимерелгән каралтылар, һичбер тәрәзә вә ишекләре калмаган биналар чыннан сугыш астында калганнар, дип уйланырлык. Тәмам эштән чыгарылган завод вә кибетләр исеңне ничек бер кат китерсә, чат саен берничә ат йөкләре генә булырлык снаряд ватыкларының өемнәре тагын бер кат хәйран калдырырлык.

Пороховой завод тирәсендәге бистәләрдән иң күп зарарланучылар, әлбәттә, Бишбалта булыр. Бишбалтаның Казанка кырыендагы биналарының күбесе көлгә әверелде, 2-3 этажлы өйләрнең, завод морҗалары кеби, тау башында һәлакәт шаһиде булып калган, ишелмәгән мичләрен генә күрәсең.

Кеше һәлакәте куркынычлы рәвештә. Ул баш-аягын әллә кайларга очырган кеше гәүдәләре, ул төтендә тончыгып, иске мунча ташы кебек булган кара гәүдәләр – бар да завод кәлисәсе [чиркәве] янындагы кабергә (братская могила) китереләләр. Ул

Даталар иске стиль белән бирелә.

Заводта 1917 елгы янгын

100 елдан соң, 2017 елгы янгын

хайван, ат, сыгыр вә башкалар һәлакәте, ул баласыз калган ата-ана һәм ата-анасыз калган бала-чага... Истанбул урамындагы иске заманның этләре төсле кайдан бер кабымлык икмәк ыргытырлар икән, дип торалар... Моннан берничә көнгә элек кешедән икмәк сорарга кул сузуны хәтерләренә дә китермәгән балалар, икмәк сорарга кайчан вакыт җитәр икән, дип, ач бүреләр төсле, икмәк амбарлары ачылганны көтеп яталар. Ничә меңләп кеше эшсез вә ничә меңләп кеше ашсыз калдылар. Эшләр харап, Алла түземлек бирсен! Ягодный һәм Игумный бистәләрендә зарар күп. Зарар, әлбәттә, йөз миллионнарча булды, ләкин ким түгел...

Мөселман һөнәрмәндләре бюросы

Пороховой заводта булган янгыннан зыянланучыларга ярдәм өчен, Казан мөселман һөнәрмәндләр бюросы иганә дәфтәре ачты. Бюро һөнәрмәндләрдән кулдан килгән кадәр ярдәм итүләрен үтенә. Иганә кабул ителә: көндез сәгать 1 дән 2гә кадәр, кич сәгать 6дан 8гә кадәр. Бюро «Сарай» мосафирханәсендә, 6 нчы номерда.

Кояш. – 1917. – №1154. – 22 август.

Мәдрәсәләрне берләштерү комитетыннан

1917 сәнә август 26сында мәдрәсәләрне берләштерү хакында Казан укытучыларының җыелышы булды. Бу хактагы доклад тыңланып, җыелышта беравыздан мәдрәсәләрне берләштерергә карар бирелде. Комиссия үзенең беренче җыелышында дини мәдрәсәләрдә укырга теләүчеләр дикъкатенә түбәндәге игъланны чыгарырга тиеш күрде: «Революция елы булса да, мәдрәсәләрдә дә беренче октябрьләрдән калмый укулар башланачак. Укучылар җыелып бетүгә кадәр, мәдрәсәләрне берләштерү эшен тәмам юлга салу өчен, Казан мәдрәсәләренә килергә теләүчеләрнең сентябрь 15енә кадәр, теләгән мәдрәсәләренең идарәләренә килүләрен һәм кайсы сыйныфка керергә теләүләрен белдерүләре тиеш. Казан мәдрәсәләре белән таныш булмаганнар үзләренең теләкләрен укытучылар җәмгыятенең идарәсенә йибәрсәләр дә ярый. Мәдрәсәләрне берләштерү комиссиясе.

Иҗтимагый фәннәр курсы

Мөселман социалистлар комитеты тарафыннан тиз көндә Казанда иҗтимагый фәннәр курсы ачылачак. Курсларның дәвам мөддәте алты ай. Лекция һәр атнага 3 тапкыр.

Кояш. – 1917. – №1158. – 31 август. ■

АВГУСТ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында

● 1 июльдә, Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең зур уку залында күренекле татар тарихчысы, язучы һәм тәнкыйтьче Газиз Гобәйдуллинның тууына 130 ел тулуга багышлап, «Беренче татар профессоры» дип аталган китап күргәзмәсе эшли башлады.

● 1 июльдә «Кукмара киез итек комбинаты»ның генераль директоры Шамил Михәйдәр улы Әхмәтшин вафат булды. Мәрхүмне мәңгелек йортка озату мәрәсимендә Татарстан Конституция суды рәисе Фәрхәт Хөснетдинов, Кукмара һәм Саба муниципаль районы хакимияте башлыклары Сергей Димитриев һәм Рәис Миңнеханов, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон катнашты һәм чыгыш ясады.

● 3 июльдә Татарстан Дәүләт архивы Бөтендөнья татар конгрессының 25 еллыгына багышлап күргәзмә әзерләде.

● 4 июльдә Беларусьның Витебск өлкәсендәге Дубровно шәһәрендә мәшһүр татар композиторы Фәрит Яруллинга һәйкәл ачылды. Әлеге тантаналы чарада Татарстан мәдәният министры Айрат Сибагатуллин җитәкчелегендәге делегация катнашты.

● 14 июльдә Мамадыш районының Җөри авылында «Питрау-2017» керәшен мәдәнияте республика фестивале булып үтте. Матур традициягә әверелгән әлеге күркәм чарада «Идел», «Ялкын» һәм «Сабантуй» журналларының баш мөхәррирләре Радик Сабиров һәм Илназ Фазуллин, «Безнең мирас» журналы хезмәткәрләре Рәдиф Сәгъди һәм Ләйсән Данилова катнашты.

● 17 июльдә тәрҗемәче Фатих Кутлу, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон һәм басманың тарих бүлеге редакторы Ленар Гобәйдуллин, Чуашстанның атаклы Шыгырдан авылында булып, төбәкне өйрәнүче, «Шыгырдан» китабы авторы Памир Мөдир улы Салихов, мәрхүм галим һәм язучы Мөнир Нигъмәтулловның якын кардәшләре – бертуган абыйсы Дамир һәм Рифкать абыйлар, шулай ук «Безнең мирас» журналының быелгы 7 нче санында басылган

«Шыгырдан төене» мәкаләсендәге (авторы – Фатих Кутлу) фотосурәткә нисбәтле Сания, Сәгадәтбану, Таһирә һәм Камәрия апалар белән очрашты.

● 20 июльдә « Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон, басманың тарих бүлеге редакторы Ленар Гобәйдуллин Ульяновск өлкәсендәге Иске Кулаткыда булып, район хакимияте башлыгы Эдуард Әнвәр улы Ганиев белән очрашты.

● 21 июльдә «Безнең мирас» журналы хезмәткәрләре Ләбиб Лерон һәм Ленар Гобәйдуллин мәшһүребез Гадел Кутуйның туган ягында – Пенза өлкәсенең Күзнәй (Кузнецк) районы Татар Кынадысы авылында булып, әдипнең нәсел дәвамчылары белән очрашты. Алар шулай ук авыл мәчетендә һәм мәктәптә дә булдылар.

● 21 июльдә Туймазыда (Башкортстан) Бөтенроссия татар авыллары ассоциациясе рәисе Фанир Галимов инициативасы белән беренче мәртәбә Ык елгасы буендагы авылларның гомуми Сабан туе уздырылды.

● 22 июльдә Пенза өлкәсендәге Урта Әләзән авылында Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнеханов катнашында YIII Бөтенроссия авыл Сабан туе булып узды. Россиянең төрле төбәкләреннән килгән күпсанлы кунаклар арасында РФ Дәүләт Думасы депутаты Илдар Гыйльметдинов, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров, Татарстан Республикасы мәдәният министры Айрат Сибагатуллин, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин, Кукмара муниципаль район хакимияте башлыгы Сергей Димитриев, «Мәдәни җомга» газетасы белән «Безнең мирас» журналы баш мөхәррирләре Вахит Имамов, Ләбиб Лерон, язучы Фәүзия Бәйрәмова һәм Ленар Гобәйдуллин да бар иде.



Кытай Халык Республикасындагы Шенҗаң-Уйгыр автоном районының (Шәркый Төркестан) татарлар тупланып яшәгән Чишмә (Давчән) авылы мәчете. Узган гасырның сиксәненче еллары.

«Безнең мирас»
елъязмасы / август

● 780 ел элек (1237)

Монгол гаскәре Рязань, Мәскәү һәм Владимир кенәзлекләрен басып ала.

● 755 ел элек (1262)

Борынгы Үкәк каласына (хәзерге Сарытау (Саратов) шәһәре тирәсе) нигез салына. Бу заманда Алтын Урда дәүләте белән Бату (Батый) хан идарә итә.

● 405 ел элек (1612)

Лейпцигта татарча беренче басма китап дөнья күрә.

● 125 ел элек (1892)

Күренекле этнолог Мәрьям Салих кызы Гобәйдуллина (1892-1933) дөньяга килә.

● 95 ел элек (1922)

Төмән шәһәрендә татарча «Юксыллар чаткысы» исемле газета чыга башлый.

● 90 ел элек (1927)

3 августта Татарстан Үзәк Башкарма Комитеты һәм Халык Комиссарлары Советы «Татар язуында латин (яңа төрек) шрифты (хәрефе) кулланушы кертү турында» карар кабул итә.

● 75 ел элек (1942)

1 августта күренекле драматург Фәтхи Бурнаш (1898-1942) Куйбышев (хәзерге Самара) шәһәрендә НКВД хезмәткәрләре тарафыннан атып үтерелә. Кабере хәзергә кадәр табылмаган.

30 августта «Кызыл Татарстан» газетасында Фатих Кәримнең «Пионерка Гөлчәчәккә хат» исемле шигыре басыла.

● 55 ел элек (1962)

«Совет әдәбияты» журналында Гариф Ахуновның «Хәзинә» романы басыла башлый.

● 50 ел элек (1967)

Хельсинки университеты профессоры Гомәр Таһир чакыруы буенча, галимнәр Мөхәммәт Гайнуллин, Хатип Госман һәм Резеда Ганиева Финляндиядә булып кайта. Алар Хельсинки университетында, яңа оештырылган Г.Тукай җәмгыятендә хәзерге татар әдәбияты һәм мәдәнияте турында чыгышлар ясый.

Журналга ***Марат Закир*** *әзерләде.* ■

Мирасворд

Самат Шакир туган авыл

... Гәрәй хан

1906-1910 елларда Оренбургта татарча чыккан журнал

Дәвер, заман

... Зөлкарнәй

Ел (иск.)

Лаос акчасы

Гарәп хәрефе

XX йөз башында Франциядә барлыкка килгән сәнгать стиле

Китап басу ысулы

Төрле төстәге

Язучы Фаил ...

Әмирхан Еники повесте

Алтын Урда шәһәре

Махсус җайланма ярдәмендә өслеккә төшерелгән сурәт

Әдәби әсәрнең тәмамланган бер кисәге

Теркәгеч

Гөман, фараз

Ике яки өч мачталы җилкәнле судно

Иллюзионист Эмиль ...

Пәйгамбәр

... Колый

Габдерәхим Утыз ...

Мостафа ... (Төркиянең Эгей университеты профессоры)

Кривой ...

Кубрат хан улы

Шагыйрь Рәдиф ...

Яхшы, әйбәт (диал.)

Алтын Урда ханы

Композитор Мәсгут ...

Шагыйрь ... Нәҗми

Мәдхия

Язучы ... Шабай

Өндәү, чакыру авазы (иск.)

... Геллер



Кытайдагы тарихи шәһәр, XVIII йөздә Хубилай ханның җәйге мәркәзе

Сузнең аерым һава этәреше белән әйтелә торган кисәге

Себер шаманы

Япон курчак театры

Борынгы Идел

Рәис Габдулла төзеде.

7 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:

Сулдан уңга: Ногман, Госман, таң, «Шомбай», игәр, Мишә, Гата, Кубрат, фирка, әзи, аймак, янычар, лур, Исәнбәт, «Мцыри», Урсу, изен, бәк, еш, скетч, репс.
Өстән аска: ятим, шигрин, цинк, ошак, «Ыргыз», Нигъмәти, чу, Решт, Афзал, инеч, стан, Мамай, Ус, «Аң», зурат, нан, нукәр, Гәрәй, Өбрә, Азак, әсбап, рети, Уту.



СОДЕРЖАНИЕ. АВГУСТ 2017

Историческое наследие: «Опасные и тревожные годы». И. Тагиров;

Всемирному конгрессу татар 25 лет!: «Заботясь о будущем нации». Р.Закиров; «Цель одна – национальная независимость». Ф.Байрамова; «Прислушиваясь к зову предков». К.Юсупов; «Татары Красноярска: история и современность». В.Файзуллин; «Мы не имеем права забывать». Т.Биктимерова; «Цель – сохранение нации». Р.Сафин; «Конгресс – это целая эпоха». Ф.Сафиуллина.

Педагогическое наследие: «Наставники». М.Ахметзянов; «Жизнь, посвященная образованию». Р.Низамова; «Урок, длиною в жизнь». С.Заляева.

Религиозное наследие: «Исламский мир». Г.Ибрагимов.

Татарский мир: Дамир Исхаков: «Надо расширить горизонты».

Литературное наследие: «Элегия Хади Такташа Фатиху Амирхану». Р.Мухамматша; «Он был для нас мертвым». Х.Такташ; «Милосердие, впитанное с молоком матери...» З.Ярмаки; «На острове юности поэта». И.Нигмати; «Памяти таинственного друга-поэта». Ф.Зиятдинов.

Художественное наследие: «Американский ученый и татарская гармонь». Э.Каюмова.

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

CONTENT. AUGUST 2017

Historical heritage: «Dangerous and troubling years» by I.Tagirov; The **Tatar Congress is 25!:** «Caring about the future of the nation» by R.Zakirov; «The goal is one, the national independence» by F.Bayramova; «Listening to call of the wild» by K.Yusupov; «Tatars of Krasnoyarsk: history and modern age» by V.Fayzullin; «We have no right to forget» by T.Biktimerova; «The goal is to preserve the nation» by R.Safin; «Congress is a whole era» by F.Safiullina.

Pedagogical heritage: «Mentors» by M.Akhmetzyanov; «Life dedicated to education» by R.Nizamova; «Lifetime lesson» by S.Zalyaeva.

Religious heritage: «The Islamic world» by G.Ibrahimov;

Tatar world: Damir Iskhakov: «We need to broaden the horizons».

Literary heritage: «Elegy by Hadi Taktash to Fatih Amirkhan» by R.Muhammatsha; «He was dead to us» by I. Taktash; «Charity absorbed with mother's milk....» by Z.Yarmaki; «On the poet's youth island» by I.Nigmati; «In memory of a mysterious friend-poet» by F.Ziyatdinov.

Artistic heritage: «American scientist and Tatar harmonica» by E.Kayumova

The magazine constantly brings to light all the most important events of our nation life.

РУШАНИЯ ЯКУПОВА

Рушания Мостафа кызы Якупова 1929 елның 3 февралендә Оренбург өлкәсендәге Кызыл Мәчет авылында дөньяга килә. 1953 елда Казан сәнгать училищесын тәмамлый.

Ул - Татарстан Республикасының Рәссамнар берлеге әгъзасы (1994), Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (2000).

«Пионнар». Киндер, майлы буяу. 1994 ел

«Яңа самавыр». Киндер, майлы буяу.

АЛДАГЫ САННАРДА УКЫГЫЗ:

Айрат Галимҗанов. Төрки һәм япон кабиләләренең диннәре
Клара Тукаева-Насыйри. Йөрәкләрдә Имай Насыйри
Энҗе Гайнетдинова, Лилия Закирова. Казиле мәчете һәм мәдрәсәсе
Айдар Казаков, Ландыш Хәйруллина. Әй кырылды адәмнәр...
(1921 елдагы ачлык турында истәлекләр)
Фатих Кутлу. «Шыгырдан төене»н чишкәндә...
Рүзәл Юсупов. Тәрбияле кеше туган телен бозмый
Камил Саттаров. Тукайның фатихасын алган остаз (Касыйм Шамил)

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – 54132 (П-2343)
РОССИЯДӘ – 70275
www.beznenmiras.ru

«БЕЗНЕҢ МИРАС» журналына башкача язылу:
- *www.uslugi.tatarstan.ru сайты ярдәмендә*
- *редакциядә*
- *www.tatpodpiska.ru сайты ярдәмендә электрон версия*

4 612750 670172

*«**БЕЗНЕҢ МИРАС**» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» (Бауман ур., 19; 29/11) кибетеннән, «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.*